# Равил Сәйфетдиновның “Мулла Иле моңнары”, “Бәхетем үзәне”, “Аксакал язмалары” китапларыннан алынган әсәрләре (шигырьләр, поэмалар, хикәяләр, хикәятләр)

*****

Кояш батты, офык кызарды,
Ә бераздан төште караңгы.
Караңгылык качты яңадан –
Ай елмаеп җиргә карады.

Көмешләнде елга, яктырды,
Дулкыннары кочты нурларны;
Яңгырады шулчак якында
Кыңгыраулы гармонь моңнары.

1955

*****

Кичке күктә кызыл шәфәкъ яна,
Елга өсләренә ут капкан.
Тын табигать таллар-тирәкләрне
Әкрен генә назлап йоклаткан.
Яшь көтүче, әйтче, нигә болай
Тынып калдың елга ярында.
Әйтмәсәң дә, барыбер беленә бит
Син уйлыйсың аның турында.
Әле генә ул бит монда иде,
Сыерлар сауды синең янында.
Ә син көн буенча җыйган чәчәкләрне
Бирәлмәдең бүген тагын да.
Йөрдең шунда ыгы-зыгы килеп,
Уңай сүзне борып кирегә.
Нигә кирәк иде ерак китеп,
Су керергә, җырлап йөрергә.
1955

*****

Авылда да, әни, марттыр инде,
Түбән очка суга барганда

Кар бетәрен хәбәр итә-итә
Иң беренче тамчы тамганда,
Урамдагы гөр-гөр күгәрченнәр
Караганда сиңа борылып,
Кояш белән аралашкан җилләр
Сыйпыйлардыр, әни, мин булып.
Зәңгәдер бит инде, зәңгәрдер бит
Кар өстенә төшкән күләгәң.
Ләкин менә кемдер анда сиңа
Минем хакта гайбәт сөйләгән.
Студент ул, имеш, үз әнисен
Алмаштыра җансыз китапка.
Юк-бар нәрсә белән баш катыра,
Ә әнисен бирми уйлап та.
Юк, ышанма, әни, гайбәт диң дә
Каршыла син соңгы почтаны.
Чыкмый калмам хатлар арасыннан,
Булып сине сөю очкыны.
Студент ул, әни, бал корты бит,
Фән ширбәтен эчеп көн күрә.
Имтиханнар җитсә йокламыйча
Китап укый-укый төш күрә.
1956

*****

Көн буена җил улады.
Елады ул, сызгырды.
Урамнардан йөгереп узды,
Кар тауларын туздырды.
Тик караңгы төшкәч кенә
Качты ерак-еракка.
Килде назлы тын бер мизгел
Иркәләнеп кунакка.
Бизәр өчен зәңгәр кичне
Түм-түгәрәк ай чыкты,
Күз кысышып, җем-җем килеп,

Меңмең йолдыз калыкты.
Авыл шундый матурланды
Ай нурлары астында.
Көмеш таулар пәйда булды
Ап-ак йортлар каршында.
1956

## Күпер өстендә

Кар сулары ага ташып
Авыл тирәли.
Яз, канатын җилпи-җилпи,
Безне иркәли.
Билдән суга кергән таллар
Тирбәлеп уйный.
Йөрәк парәм миңа карап
Елмаеп туймый.
Күктә айның колагына
Җиткән авызы.
Күңелләрне җилкендерә
Ташкын тавышы.
Көмеш көзге безне үрти
Аста – түбәндә:
Шәүләләр дә үбешәләр
“Сөям” дигәндә.
1957

## Студентлар җыры

Фән йомгагын сүтә-сүтә
Безнең көннәр йөгереп үтә,
Вакыт тими артка карарга.
Кабынырга тора йөрәк,
Бөтенесен белү кирәк,
Бөтенесен кирәк аңларга.

Без даулыйбыз фәннәр күген,
Хезмәт бездә кунак түгел,
Аермыйбыз эштән укуны.
Яратабыз хәрәкәтне,
Илгә багышлыйбыз дәртне,
Дөрли бездә яшьлек ялкыны.

Алда көрәш белән тулы
Көч сынаучы тормыш юлы
Безне көтә, безне чакыра.
Алда мәңге тау чәчәкле
Без ашкынган киләчәкнең
Таңы туа, таңы яктыра.

Адымыбыз куанычлы,
Карашыбыз ышанычлы,
Бер теләктә яна барыбыз.
Сайламыйча җылы урын,
Яңгыратып хезмәт җырын,
Кайда авыр, шунда барырбыз.
1957

**Этюд**

Язгы иртә.
Беренче кат
Болынга көтү килде.
Көтүче егет быргысын
Уйнатып сигнал бирде.
Яңгырады ерακларга
Күптән көтелгән моңнар.
Тыңлады һәм кабатлады
Ул моңнарны киң кырлар.
Тау өстендә кояш көлде,
Күктә тургай сайрады,

Йомшак җилләр исеп үтте,

Тәмле исләр тарлды.

1957

**Далада туган хисләр**

*Чирәм җирләрдә кызу урак өсте иде. Павлодар өлкәсенең “Казан” совхозына килеп төштем. Биредә Казан университеты студентлары эшлиләр иде. Ындыр табагына юнәлдем. Минем күземә ике яшүсмер чалынды. Түгәрәк алсу йөзле, чем-кара чәчле, калкурак гәүдәле егет аеруча кызу эшли. Мин аның Равил Сәйфетдинов икәнен белдем.*

*Равил казах далаларында фидакарь хезмәт күрсәтте. Туган илебез аны “Чирәм җирләрне үзләштерү өчен” медале белән бүләкләде. Ул чирәм җирләрдә туган хисләрен үзенең шигырьләрендә дә чагылдыра. Без бүген укучылар игътибарына Казан дәүләт университеты студенты, “Татарстан яшьләре” газетасы редакциясе янындагы әдәбият-иҗат түгәрәге члены Равил Сәйфетдиновның чирәм җирләрдә язылган шигырьләрен тәкъдим итәбез.*

*Мәхмүт Хөсәен*

**Яшьлек җырлый**

Яшьлек җырлый,

Яшьлек көчен сыный,

Ямьгә төреп дала күкрәген;

Яраттым мин бөтен җаным белән

Бу җирләрдә тормыш күкрәвен.

Буыннарым меңгә бөгелсә дә,

Арып-талу, йончу белмәдем;

Бу җирләрдә рухым корычланды,

Бодай төсен алды беләгем.

«Котырып бодай унган далаларда

Бөреләнә татлы уйларым;

Эш өстендә туган җырым белән

Яңгыратам Иртыш буйларын!

1958

*****

Сөял бассын кулны,
Тән каралсын,
Кызларыбыз чалбар кисеннәр...
Көлгән көлсен,
Шуны яхшы белсен:
Безгә алмаш буын телләрендә
Кабатланыр безнең исемнәр!
1958

**Дала юлында**

Дулкынлана зәңгәр күк астында
Алтын агым - бодай диңгезе;
Әнә совхоз – тиздән карталарда
Яктырачак шәһәр нигезе.
Чирәм җирләр!
Чорыбызга тиң сез,
Нинди киң сез,
Нинди матурлар!
Кабатлыйлар йөрәк тибешемне
Сезнең кырлардагы моторлар.
1958

*********

Палаткада дуслар йоклап беткән,
Ә мин, карап йолдыз-айларга,
Күзне йоммый ятам...
Ә уйларым
Сәфәр чыккан әллә кайларга.

Аһ, уйларым!..
Телдән-телгә күчеп,
Илдән-илгә очып йөриләр;
Сагынырлык дуслар булмасалар,
Мондый уйлар башка кермиләр.
1958

## Казах кызы

Комбайным йөзә дала буйлап,
Офыкларда рәшә тирбәлә;
Штурвалда – изге постта торам,
Күлмәк аша тозлы тир бәрә.
Дала, дала, дала...
Исми җилләр.
Эх, тамчы су килә йотасым!..
Чү, кем анда миңа чәйнек суза?
Тракторчым, бераз туктачы.
Шундый рәхәт булып китте, эчкәч,
Салкын кымыз – дала ширбәтен!
Күңелемә мин җыр итеп яздым
Казах кызының бу хөрмәтен.
1958

## Җырла, Галия

Айлы кичтә көмеш Иртышның
Син җырлыйсың басып ярына.
Йөрәгеңнең бөтен ярсуын
Әйтеп бирә кебек җыр гына.

Хуш ис тулы дымсу далада,
Бодай сабакларын аралап,
Язда искән назлы җил булып,
Яшьлегеңнең моңы тарала.

Чал Иртыш та сиңа кушыла,

Һәр авазың сөеп кабатлый.

Чирәм җирдә сихри тылсымың

Кемне генә үзенә каратмый.

Җыр көенә уйный дулкыннар,

Таңга калып таллар баш ия...

Талпынучы горур кош кебек,

Җырла, дустым, җырла, Галия.

Сине үзенә чакырып алган җир

Киң күкрәген тутырып суласын.

Яшь йөрәгем алтын диңгездә

Тальян гармун булып чыңласын.

Туган илең сөенеп тыңласын.

1958

**Егерменче язым**

Егерменче язым – чәчәк чагым!

Күңелем көр, китек төше юк.

Күкрәгемдә яна вулканга тиң,

Сүрелмәскә туган көчле ут.

Егерменче язым – чәчәк чагым!

Йөрәк җырлый дәртле көйләргә.

Мин туганмын таза тормыш шавын

Фәрһат гыйшкы белән сөяргә.

Егерменче язым – чәчәк чагым!

Җитмеш кенә түгел һөнәрем.
Комсомолның корыч ташкынына
Кушылып ага керсез көннәрем.

Егерменче язым – чәчәк чагым!
Һаман шулай булып калсамчы!
Чәчләремә карлар яуганда да
Яшьлегемне саклый алсамчы.
1958

*****

Идел кебек җырлый, давыллана,
Кипкән елга түгел күңелем.
Ак җәймәле керсез көннәремдә
Алдан хезмәт тора күренеп.
Көнләштерә мине очар кошлар,
Тиңләшәсем килә шуларга.
Түзә алмый йөрәк ярсуыма
Сикереп төшәм агым суларга.
1958

*****

Янымдагы кайбер чибәрләргә
Күзем белән гашыйк булсам да,
Ә йөрәгем белән сине сөям,
Сине сөям ерак калсаң да.
Син көт мине, аяз күңелеңне
Шикле уйлар бутап йөрмәсен.
Син кабызган ялкын миндә сүнми,
Минем ялкын синдә дөрләсен.

1958

## Яшьлек җырлый

Яшьлек җырлый.
Яшьлек көчен сыный,
Ямьгә төреп дала күкрәген;
Ярattым мин бөтен җаным белән
Бу җирләрдә тормыш күкрәвен.
Буыннарым меңгә бөгелсә дә,
Арып-талу, йончу белмәдем;
Бу җирләрдә рухым корычланды,
Бодай төсен алды беләгем.
“Котырып” бодай уңган далаларда
Бөреләнә татлы уйларым;
Эш өстендә туган җырым белән
Яңгыратам Иртыш буйларын!
1958

## Казах кызы

Комбайным йөзә дала буйлап,
Офыкларда рәшә тирбәлә.
Штурвалда – изге постта торам,
Күлмәк аша тозлы тир бәрә.
Дала, дала, дала...
Исми җилләр,
Их, тамчы су килә йотасым!..
Чү, кем анда миңа чәйнек суза?
Тракторчым, бераз туктачы.
Шундый рәхәт булып китте, эчкәч,
Салкын кымыз – дала ширбәтен!
Күңелемә мин җыр итеп яздым
Казах кызының бу хөрмәтен.
1958

*****

Син янасың тиңсез йолдыз булып,
Җырланмаган җырым иясе.
Килә минем гомрем соңынача
Син бер генәм минем диясем.
Ул син – хыялымны татлы иткән,
Ул син – башы очсыз уемның.
Әйтче, нигә керсез йөрәгемә
Бетмәс яра булып уелдың?
Белмәсәң дә күңелем диңгезенә
Һәр тамчының “син” дип тамуын,
Ә күрерсең тиздән ул диңгезнең
Ярларыннан ташып чыгуын.
Өй эчендә чөнки янгын купса,
Тышка чыкмый калмый ялкыны.
Кышын карлар тау-тау булып яуса,
Җәелеп ага апрель ташкыны.
Студент кыз – тиңсез якын йолдыз,
Син балкыйсың мине сихерләп.
Сине үбә зәңгәр күк кояшы,
Дала җиле сыйпый кадерләп.
Мин ышанам, тиздән давыл кубар,
Ике давыл бергә кушылыр.
Давылдан соң килгән ак бәхетем
Даладагы таңдай сызылыр.
Һәм мәкерле җаннар телләнмәсләр
Һәм урынсыз шикләр югалыр.
Һәм мәхәббәт биргән кыюлыктан
Бар киртәләр ватылып уалыр.
1958

**Йөрәктә яз**

Мин чакырам сине, кил син, кил
Ялгыз өйнең тын бакчасына.
Агач ботаклары әйләнгән
Анда карлар куна(к)часына.
Яз түгел бит, нишләп барыйм дип,
Икеләнеп килми калмачы.
Бик күбәйде сөйләр серләрем –
Йөрәктә яз - шуны аңлачы.

1958

**Ул син түгел**

Син матурсың:
Кыйгачланып тора
Сөрмә тарткан нечкә кашларың.
Күзләреңнән укыйм: мескен егет,
Әйләндерәм газиз башларың.
Юк, син тансык  ата кесәсеннән
Муенын сузган чуар җаннарга.
Мин теләмим
Эш киемен киеп
Карамаучы өчен янарга.
Елмайсаң да барыбер кызганыч син,
Син белмисең хезмәт шатлыгын,
Сокландырмый, җанны гына өшетә
Кулларыңның кардай аклыгы.
Син күрмәгән иген диңгезендә
Йөгерешкән дулкын тауларын.
Билдән печән үскән аланнарны,
Сандугачлар кунган талларны.

Кояш  нурын куып, тын бүлмәңдә
Хәрәкәтсез, җансыз көзгегә
Карыйсың да гамьсез хихайлыйсың
Мин-минлегең санап изгегә.

Безнең матур, гүзәл дигәнебез
Ни әйтсәң дә,
Ул бит син түгел.
Эшсезлектән хәлсезләнгән тәнне
Сыйдыралмый минем киң күңел.
Яшьлек мени әгәр үтеп китсә
Бер давылсыз,
эзсез,
тын гына.
Юк. Син матур түгел,
Матурлыкны
Мыскыллаучы мескен сын гына.
1958

### Сине усал һәм тәкәббер диләр...

Сине усал һәм тәкәббер диләр,
Артык горур диеп сөйлиләр.
Янып йөрмә юкка, ташла аны,
Башка берәр кызны сөй, диләр.

Юк, мин алай бөтен яктан килгән
Матурларны эзләп йөрмәдем.
Син тормышның үзе кебек чибәр.
Үзе кебек чуар, гүзәлем.

Мин яратам сине тулы килеш,
Вакланусыз, шиксез, шөбһәсез.
Үкенмичә сагынырлык булсын
Яшьлек аргамагы үткән эз.

Мин яратам сине тулы килеш,
Уй-хыялым түгел икеле.

Елмаюың ничек сокландырса,

Ачуың да шундый сөйкемле.

Сине усал һәм тәкәббер диләр,

Ышанычсыз, диләр,

Дисеннәр...

Таһир-Зөһрә кебек бер-берсеннән

Аерылмасын безнең исемнәр.

1959

**Яшьлек юләрлегем**

Зөя өстен аксыл томан сарыр,

Үзәннәрдә тартар кычкырыр.

Син килерсең балкып зәңгәрлектән

Мин чакырган җиргә кичкырын.

Сиздермәскә тырышып, карак кебек,

Күзләреңнән нурлар урласам,

Шатлыгымнан шашкын күңел белән

Йолдызларга кадәр үрләсәм,

Кайнар бармакларым күкрәгеңә

Төшкән чәчләреңә кагылса,

Син уйлама мине шүрәле дип,

Минем гадәт кызык тоелса,

Көл шаркылдап, синең көлүеңнән

Яңгырасын кичке үзәннәр.

Минем күңелем кебек үзәннәрдә

Дулкынланып алсын үләннәр.

1959

**Юк, мин беркайчан да яр табам дип...**

Юк, мин беркайчан да яр табам дип,
Яки мәхәббәтне яңартам дип,
Матур кызлар эзләп йөрмәдем.
Сайлап тормый сөю үзе килде,
Килде дә ул яңа канат бирде,
Синең уттан гына дөрләдем.
Үткәннәрне искә китергәндә,
Мин теләмим күңел хәтирәмдә
Синнән башкаларның булуын,
Һәм аларның миннән үч алуын,
Гыйшкый уен өчен яшь тамуын,
Адым саен вөҗдан бууын.

Син беләсең, безнең йөрәкләрне
Сабый чактан ук бит теләкләрнең
Вак ишесе били алмады.
Кирәк булды ерак сәфәр китү,
Сине күрдем шулчак юлдаш итеп,
Син бит мине сүзсез аңладың.

Далаларда чирәм күтәргәндә,
Таң сәгатен эшләп үткәргәндә,
Иң беренче юлны салганда,
Чатнап торган учак яннарында,
Ялап торган кояш асларында
Бозлы яңгырларда калганда,

Бетмәс куәт алдым карашыңнан,
Күзләреңнең җете карасыннан
(Сөю утын эчеп яшәдем).
Көчле сөю утын эчтем мин.
Ярсу Иртыш өстен дулкынлатып,
Матур исемең белән яңгыратып
Җырлар җырлап ишкәк иштем мин.

Ашкынуым үзенекен итте.

Мине вузга алып китте,

Далалардан, синнән аерды.

Ләкин аерым тору белән генә

Мәхәббәтнең зәңгәр күгенә

Балкып чыккан кояш баермы?

Кая барсам, нәрсә эшләсәм дә

Син атлыйсың кебек янәшәмдә

Әүвәлеге кебек серләшеп.

Я сабыйдай гамьсез шаярасың,

Я чәчәктәй балкып елмаясың,

Күзләреңнән якты нур чәчеп.

1959

## Мин тормышка гашыйк

Мин тормышка гашыйк.

Авырлыкка

Балачактан күңел күнеккән.

Юк, теләмим җирне читтән генә

Күзәтергә алсу күзлектән.

Яратам мин җирне.

Йөрәк аны

Атом бомбасына бирәлми.

Чөнки үзенә чиксез сөю даулап

Җир әйләнә аның тирәли.

Юк, мин мәми көткән сабый түгел,

Үз кулымда тормыш йөгәне.

Көтеп тормыйм бәхет үзе килеп

“Алмаларым пеште” дигәнен.

1959

## Унсигез яшь

Галиягә унсигез яшь,
Давыллы, җилле чагы;
Я, кем аңа оялмыйча
Кечкенә дияр тагы?
Ул да сайлауга катнаша
Зурлар белән беррәттән.
Алар белән дулкынлана
Ул да бөтен йөрәктән.
Ул да менә дөнья күрә -
Еракка китеп бара.
Әнкәй кала, поезд чаба,
Ераклаша гел ара.
Яшь күңелнең саф диңгезе
Эштә, сөюдә ташый.
Әй, тынгысыз яшьлек таңы –
Тормыш юлының башы!
Поезд чаба, чаба алга,
Алда Себер кочагы...
Я, кем генә Галиягә
Кечкенә дияр тагы?
1959

## Яз

Кәрван булып болыт агыла,
Күктән җиргә ширбәт сибелә.
Томан тора Идел өстендә
Тирбәлгән йомшак җил белән.

Тәүге бөре исен аңкыта
Агачларның яшерен сулавы,
Чак-чак кына кагыл каенга –

Чәчрәп чыгар кебек сулары.

Чур-чур килеп елга-күлләргә
Кар сулары йөгерә таулардан.
Кара күлмәк кигән каргалар
Яз концерты бирә талларда.

Әй бу язның ярсу айлары,
Тәлгәш-тәлгәш каен чуклары.
Уналтыга җиткән кызларның
Бер сәбәпсез көлгән чаклары.
1959

## Мәңгелек кыз

Урман-кырлар, үзән-таулар буйлап,
Мәңгелек кыз кайта яңадан.
Шаян кызый шаша, ярсый-ярсый,
Җиргә ятып уйный, кызык ясый:
Чыр-чыр килеп, куркып аңардан
Кар сулары йөгерә таулардан.

Канатларын җилпи мәңгелек кыз,
Хушбуй бөрки, сафлый һаваны.
Яшел шәлен бәйләп шаяра да,
Яланаяк чакырып чыгара да
Чәчен тарый сабый баланың
Һәм кытыклый күңелен ананың.

Ул кызыйга һәркем үлеп гашыйк,
Әллә ние белән сөйдерә.
Ул үзе дә барсын – яшен-картын
Коча-үбә, уйлап тормый шартын.
Чәчәк биреп китә - исертә,
Йөрәкләргә серле көч кертә.

Мәңгелек кыз әйдә киңлекләрне
Теләгәнчә бизәп атласын.
Булсын дөнья мәңге тыныч, якты,
Җиргә сугыш уты капмасын,
Җирне гөлләр генә капласын.
1959

*****

Син көзге көн кебек үзгәрүчән,
Аязып та җитми карашың,
Күмеп китә бик тиз салкын болыт,
Җан өшеткеч матур бер сын булып,
Буйсындырып катып торасың.
Онытырга иде күзләреңне –
Ачу йоткан зәңгәр диңгезне.
Сүндерергә иде сөю дәртен,
Булмый! Ярты юлда өзү читен
Бер башлаган җырның изгесен.
1959

**Лирик эстафета**

Син бит юри генә, болай гына
Кар йомарлап аткан идең.
Егет исә, бер сүз эндәшмичә,
Бүреген салып каккан иде.

Әй, син көлгән идең шырык-шырык
Шул хәзерге үз иреңнән...
Аннан бирле карлар күп эрегән,
Үзең төсле кыз өлгергән.

Бүген әнә тәрәзәдән кара

Кызың кемгә кар атканын:
Узган яшьлегеңне яңабаштан
Матур итеп кабатлавын.
1959

*****

Аязлыкны мактап зәңгәр төндә
Түгелгәндә көмеш ай суы,
Диңгез төбе кебек серле була,
Моңлы була колхоз басуы.

*********

Шундый төннәр була, гаҗәп төннәр,
Айдан чыңлап көмеш коела.
Шомырт карын килеп бер иснәсәң,
Таң атканчы йокы җуела.

*********

Кырлар чишенеп яткан йокларга,
Яшереп саклый аларны томан.
Яфрак кала көпчәк эзендә
Алтын көзнең мөһере сыман

1960

**Мәрмәр ташны үбә таң җиле**

Монда табигатьнең тын җире.
Кабер ташын укый таң җиле:
“Мең тугыз йөз –
Мең тугыз йөз унҗиде”.
Җил шомарткан, яңгыр юган таш,
Таш янында минем замандаш
Октябрьның уйлы таңында
Илем туып килгән чагында
Һәлак булган япь-яшь егеткә
Чәчәк бирә:

Мәңгелек дан диеп бөркеткә.
Идел-ана ага якында,
Көрәш эзен саклый ярлары.
Батыр яткан калку урынга
Ишетелә дәртле шаулары.
Бу урыннан, кабер ягыннан,
Күз иңләмәс җирләр күренә.
Әнә, йортлар белән ярышып,
Зур домналар күккә үрелә.
Ангараның ташкын суларын
Эшкә җигә яшьлек куллары,
Чәчәк атып галим уйлары
Якынайта космос юлларын.
Тыныч атом яра бозларны,
Тайгаларны ерып ток уза;
Тормыш җырын җырлый арыклар
Елга суын чүлгә агыза.
... Монда табигатнең тын җире,
Мәрмәр ташны үбә таң җиле:
“Мең тугыз йөз –
Мең тугыз йөз унҗиде”.
1960

**Бер көн**

Кеше өчен –
Минем өчен
Хезмәт белән
Шаулап-гөрләп,
Яңа йортлар,
Юллар салып,
Без ашкынган
Таңга үрләп,
Канатланган
Җыр шикелле

Үтте бер көн,

Гади бер көн.

Яшь күңелем

Һаман шулай

Илем кебек

Киң һәм иркен.

Ерак бабам,

Бәхет ди-ди

Хыялланып

Күп йөргәндер,

Әмма безнең

Гади көнне

Бәйрәмдә дә

Күрмәгәндер.

1960

**Аңлашудан соң**

Ярларыңнан ташыр төсле торган

Кичке күлдәй иде күзләрең.

Тынычлыгын бозмый бик сак кына

Мин алардан серләр эзләдем.

Алар шундый керсез елмайдылар,

(Шикне куып алар яшрен генә)

Нур сиптеләр гыйшкым язына.

Шушы җырым туйның буласына

Зур ышаныч белән языла.

Һич искерми торган энҗе булып,

Исемең минем каләм очыннан

Ак кәгазьгә төшә ишетелмәгән,

Җырланмаган матур җыр сыман.

1960

**Әнигә**

Урын табалмыйча җилләр тузды,

Түбә итәкләрен тарады.

Авыраеп аккан ак болытлар

Кара чырай белән карады.

Тын авылга сугыш кырларыннан

Кайгы төяп килде почталар.

Ап-ак карлар – кышкы ромашкалар –

Берни булмагандай очтылар.

Хәтеремә кереп тамыр җәйгән

Сабый чакның шушы бер көне.

- Әткәң үлде, - диеп пышылдадың,

Күз яшьләрең чыкты бөркелеп.

Күкрәгеңә кысып кочакладың,

Битләреңә карлар сырышты.

Юатырга мине тырыштың.

Артта калды алар, авыр еллар,

Күтәрелдек яңа үрләргә.

Син өйрәндең, әни, күз яшьләрен

Йөрәгеңә бикләп көләргә.

И түземле әни!

Тормыш буйлап

Сыктап түгел,

Дөрләп атлыйсың.

Ә кайгыны...

Чал чәчеңә яшереп саклыйсың.

1960

*********

*(Хәсән Туфанга)*

Балачакта миңа кешеләр

Шундый тирән, уйчан, ярсулы,

Шифа бирә торган саф сулы

Елга бар дип сөйли иделәр.

Күрсәтегез дигәч, миңа алар
Бозын гына күрсәтә иде,
Боз астында көчле агым дип,
Алар мине кисәтә иде.
Ник кузгалмый һаман боз дигәч,
Алар эчтән тыналар иде,
Күрәсең юк синең барыбер дип,
Сүзсез генә торалар иде.
Үтте еллар, яңа яз килде,
Боз кузгалды, елга елмайды.
Көзгесенә күк зәңгәрлеген,
Кояш алсулыгын ул алды.
Менә бүген
Ак җәймәле көннәр түрендә
Шундый тирән, уйчан, ярсулы,
Шифа бирә торган саф сулы
Елга шаулый минем илемдә.
Шаулап ага гомер елгасы,
Юк гомер дә аның тынасы.
1960

## Мәхәббәт

Кушса миңа туган илем
Шундый сынау ясарга,
Ялгыз ракетага утырып,
Җирдән күккә ашарга,
Кире кайтмаслык булса да.
Мин карышмам, очармын.
Иң-иң ерак планетаның
Яшерен серен ачармын.
Юк, юк! Һәйкәл өчен түгел!
Данга сусамый йөрәк.
Илгә булган мәхәббәтем
Барысыннан да көчлерәк.

Әгәр җирдә, әйтик, менә
Шундый гаҗәп көч булса.
Һәм ул шушы мәхәббәтне
Йөрәктән йолкып алса,
Яраланган юлбарыстай
Дәһшәтле ярсыр идем,
Мин бит чөнки мәңгелеккә
Кояшсыз калыр идем.
Көзге чәчәк кебек сулып
Яшәүдән туктар идем.
Ул чакта мин кирәксез бер
Таш булып катар идем.
Ләкин җирдә андый көч юк,
Бу мәхәббәт алдында
Көчсезләнеп кала вәхши
Кулындагы атом да.
Мин барысын да эшләргә риза
Бу мәхәббәт хакына.
Шунда барам, туган илем
Кая мине чакыра.
1960

*****

Гаҗәп иде бүген күк сәхнәсе!
Артистлардан кояш берүзе
Роль башкарды зәңгәр биеклектә,
Кич кул чапты аңа җир йөзе.
Кояш киткәч, офык иңнәренә
Төште кызыл шәфәкъ пәрдәсе.
Чыкты минем, чыкты алтын аем –
Яшьлегемнең чукрак сердәше.
Бик кадерле миңа аяз көннәр,
Кыйммәт - аяз төннәр көмеше.

Шуңаргадыр, ахры, артык сөйдем
Ачык һавадагы кыр эшен.
1960

*****

Кичеп чыккан чакта елганы
Купты давыл, екты көймәмне.
Үлем белән янап, бугазлап,
Кара упкын тартты гәүдәмне,
Кичеп чыккан чакта елганы.

Акылыннан шашты табигать,
Котырып көлде минем язмыштан,
Яшәү белән авыр хушлашу.
Аерырга теләп тормыштан
Акылыннын шашты табигать.

Көтмәгәндә кеше кул сузды,
Мине сөйрәп ярга чыгарды,
Тик бер минут карап торды да
Әллә кая китеп югалды.
Көтмәгәндә кеше кул сузды.

Кем булдың син, кеше-узгынчы?
Исемең, эшең, туган якларың?
Зур бурычта калдым мин сиңа,
Эзләсәм дә барыбер тапмадым.
Кем булдың син, кеше-узгынчы?
1960

## Кулларың

Мин кулларны беләм: ап-ак алар,
Гөл сабыдай нечкә бармаклар,

Өф-өф итеп кенә үстерелгән
Озын-озын кызыл тырнаклар.
Мин кайчандыр менә шул кулларга
Чын нәфислек диеп сокландым.
Ләкин
          теләсәм дә күрәлмәдем
Мин аларның эштә чакларын.
Эшкә кушсаң алар,
Энҗе бизәк кебек,
Уылып төшәр кебек күренде.
Алмагачның буш чәчәген түгел,
Җимешлесен күрү күңелле.

Ул куллардан бизде күз карашым,
Чын нәфислек күреп алдандым.
Гөл тамучы синең кулларыңа
Чын ихтирам белән карадым.

Алар түгел энҗе, коелмыйлар,
Алардан бит куәт, көч балкый.
Я сөт сава зәңгәр күк астында,
Я бер бозлы суда кер чайкый.

Без кайчакта менә шул кулларны
Тупас диеп узып китәбез.
Җил тиде исә шиңеп төшә торган
Ак кулларны мактап үтәбез.

Хөрмәт белән ихтирамны шулай
Лаексызга биреп йөрибез.
Безнең өчен
                   керләр чайкап, сыерлар сауган
Пакь кулларны гына күрмибез.
1960

*****

Гаҗәп иде бүген күк сәхнәсе!
Артистлардан кояш берүзе
Роль башкарды зәңгәр биеклектә,
Кич кул чапты аңа җир йөзе.
Кояш киткәч, офык иңнәренә
Төште кызыл шәфәкъ пәрдәсе.
Чыкты минем, чыкты алтын аем –
Яшьлегемнең чукрак сердәше.
А бу аяз көннәр, аяз төннәр!
Бик кадерле миңа аяз көннәр,
Кыйммәт - аяз төннәр көмеше.
Шуңаргадыр, ахры, артык сөйдем
Ачык һавадагы кыр эшен.
1960

**Эштән кайтканда**

Безне хезмәт үзе табыштырып,
Үзе кавыштырган,
Без бергә.
Фермадан гел менә, хәзергедәй,
Бергә кайтсак икән гомергә.

Ап-ак карлар – кышкы ромашкалар
Ничек явып тора бу төндә!
Әй, уйный бит, уйный шат елмаю
Алсуланып янган битендә.

Мөмкин булса, хәзер бу дөньяны
Кочып алыр идең берьюлы.
Күзләреңдә - җирнең мең шагыйре,
Әйтеп бетергесез сер тулы.

Мин бәхетне күрәм, тоям: ул – син,
Ул – син, минем җанлы карбикәм.
Эш артыннан туган шатлыктан да
Татлырак хис тагын бар микән?!
1960

**Күл буенда**

Күл буенда шук Оркыя
Ташка басып кер уа.
Күлдә йөзгән ак казларны
Бер чакыра, бер куа.

Аллы-гөлле тавышына
Усал казлар буйсына.
Су көзгесе кызны үрти:
Бер күрсәтә, бер сына.

Оркыяның карашыннан
Язгы нурлар бөркелә.
Көннең генә көйсез чагы:
Бер елый да, бер көлә.

Көн еласа, имәнлеккә
Кереп кача Оркыя.
Имән зонтигыннан яңгыр
Бер тама да, бер коя.

Көн көлдеме – кояш шары
Күлгә төшеп ватыла.
Күлгә баккан кара күзләр
Бер кысыла, бер тула.

Мамык җепләр – бәйләнчекләр,
Очып килеп бер читтән,

Үч иткәндәй сарып ала
Бер чәчләрдән, бер биттән.

Мыштым усак егетләре
Үчеклиләр яшь кызны:
Ак керләргә яфрак ташлый
Я тегесе, я монсы.

Өй казлары гамьсез уйный,
Әлегә бит көн җылы.
Кыр казлары гына күктә
Бер үкси дә, бер елый.
1960

### Студент кызга

Ап-ак карлар тиздән китәр инде,
Ак ромашка килер алмашка,
Имтиханнар җитәр,
Кайнар бәхәс
Ташкыннарын тыңлар тын бакча.
Әлегә март,
Әле кар җәймәсе
Чакрып ала сине бүлмәдән.
Тау сыртыннан коштай очып төшә
Калфак кигән зәңгәр күләгәң.
Кояш белән аралашкан җилләр
Үбеп ала алсу битеңнән.
Җанлы әкият булып калкып чыктың
Мин яраткан роман битеннән...
Сиңа бүген җырлар бирәм,
Котлап сигезенче март белән.
Тормыш юлын синең белән үтү –
Менә, дустым, минем бар теләк.
Әйди мине, әйди биеклеккә

Күзләреңнең якты карашы.
Шуңа да бит миңа икеләтә
Матур булып күренә яз башы.
1961

**Есениннан**

Шаһәнем син минем, Шаһәнем!
Булган өчен әллә төньяктан
Сөйләр идем кырны мин яттан.
Айга арыш башын игәнен.
Шаһәнем син минем, Шаһәнем.

Булган өчен әллә төньяктан
Ай зуррак анда йөз тапкыр.
Булса да бит Шираз бик матур,
Ул Рязаньга җитми барыбер,
Булган өчен әллә төньяктан.

Сөйлим сиңа кырны мин яттан.
Бу чәчләрне алдым арыштан,
Бармагыңа чорна – яратсаң.
Мин авырту сизмим берчак та.
Сөйлим сиңа кырны мин яттан.

Арыш айга башын игәнен
Чәчләремә карап фараз ит.
Елмай, җаным, мине син шаярт,
Тик кузгатма миндә төннәрен
Арыш айга башын игәнен.

Шаһәнем син минем, Шаһәнем!
Шундый кыз бар анда, төньякта.
Шундый охшаш сиңа һәрьяктан.
Шәт уйлыйдыр хәзер ул мине...

Шаһәнем син минем, Шаһәнем.
1961

## Егерменче гасыр, мин синеке

Егерменче гасыр, мин синеке,
Нинди яхшы!
Шуның өчен дә
Чиксез яну, чиксез илһам белән
Кыю атлыйм җирнең өстендә.
Күккә карыйм:
Күктә космик юллар,
Ул бит, гасырым, синең юлларың.
Йолдызлар да,
Ай да
Беравыздан
Сәламлиләр илем улларын.
Җиргә карыйм:
Җирне кояш үбә,
Төннәрендә түгелә ай нуры.
Ил кырында бөек симфония –
Тыныч хезмәтләрнең шау-шуы.
Үзенең шатлык-кайгылары белән
Җир әйләнә йөрәк тирәли.
Кайгылары мине тирән борчый,
Шатлыклары чиксез иркәли.
Сугыш...
Бу нәрсәне гомрем таңында ук
Тойды минем нәни йөрәгем.
Ул әтине миңа күрсәтмәде
Һәм әнинең йотты терәген.
Күңел ихтыярсыз барсын саклый,
Тыныч җилләрдә дә таратмый.
Элек өндә баштан кичкәннәрне
Йөрәк бүген төштә кабатлый.

Тәнне ярган корыч ярчыгыннан
Кешеләр бик еш тетрәп уяна.
Уяна да
Төннең шундый рәхәт тынлыгында
Бүгенгебез белән куана...
Бүгенгебез инде һәр таң саен
Яктылыгын күбрәк арттыра.
Китаплардан, хыяллардан күчеп,
Хәрәкәткә кереп яктыра.
Шуңа да бит
Түгелгән көч, талган тир тамчысы
Ару түгел, ә дәрт кабыза.
Сафка кертеп яңа гигантларны,
Күтәренке җырдай көн уза.
1961

*****

Тын кич. Күбәләкләр бер-бер артлы
Кундылар да зәңгәр гөмбәзгә
Елмаешып миңа күз кыстылар...
Юк, кирәкми, бәгърем, көнләшмә.
1961

**Иң яхшы чак**

Яхшы чакка таба ашкынганда
Очрадым мин кинәт кызыкка:
Кемдер, яхшы чагың күптән җиткән
Инде, диде, бара узып та.

Күптәнмени әле, үзсүзләнеп,
Ашыга- ашыга төштем бишектән,
Тәрәз аша дөнья аз күренгәч,
Үрелдем мин тизрәк ишеккә.

Йөгерделәр көннәр борылмалы
Сукмаклардан мине җитәкләп.
Тизрәк үс, дип, мине кояш үпте,
Әле яңгыр яуды чиләкләп.

Хыялларның берсе чынга ашса,
Икенчесе калды иртәгә,
Иртәгесен инде өченчесен
Ашкындым мин куып җитәргә.

Артка карамыйча бара торгач,
Очрадым мин кинәт кызыкка:
Яхшы чагым җиткән генә түгел,
Бара икән инде узып та...

Күптәнмени әле үзсүзләнеп
Ашыга-ашыга төштем бишектән.
Тәрәз аша дөнья аз күренгәч,
Үрелдем мин тизрәк ишеккә.

Инде
Яшьлегемнең янар чәчәкләре
Берәм-берәм җиргә коела...
Тик шулай да
Иң яхшы чак әле җитмәгәндер,
Алдарактыр кебек тоела.
1961

**Больницадан чыккач…**

Мин яңадан сабый.
Мин яңадан
Дөнья йөзен күреп елмаям.
Юеш ирене белән йомшак кына

Юеш карлар үбә маңгайдан.

Яңа сауган сөттәй шифа һава,
Ак йолдызлар ява ишелеп.
Ява алар, ап-ак халат кигән
Врачларны искә төшереп.

Бушлай яуган көмеш тәңкәләрнең
Мин сафлыгын җыйныйм йөрәккә.
Саулык, миннән мәңге аерылма,
Илт син мине, илт син еракка.
1961

**Әлегә март**

Ап-ак карлар тиздән җитәр инде,
Ак шомыртлар килер алмашка.
Ак кыңгырау тагын ландыш кайтыр,
Ак керфеген сирпер ромашка.

Әлегә март,
Әле кар диңгезе
Чакырып ала сине бүлмәңнән.
Тау сыртыннан коштай очып төшә
Калфак кигән зәңгәр күләгәң.

Яз сулышы булып искән җилләр
Үбеп ала алсу битеңнән.
Яшерен утта янган егет кебек
Кояш карый офык читеннән.
1961

**Бураннан соң**

Көн буена җил улады,
Елады ул, сызгырды;
Урамнардан йөгереп узды,

Кар тауларын туздырды.
Тик караңгы төшкәч кенә
Качты ерак-еракка.
Килде назлы тын бер мизгел
Иркәләнеп кунакка.
Бизәр өчен зәңгәр кичне
Түп-түгәрәк ай чыкты,
Күз кысышып, җем-җем килеп
Мең-мең йолдыз калыкты.
Авыл шундый матурланды
Ай нурлары астында.
Көмеш таулар җемелдәшә
Ап-ак йортлар каршында.
1961

**Ишекләр зары**

“Мәктәбеннән
Көн дә Гата
Икелеләр
Алып кайта.
Шуның өчен
Ала үчен
Гата бездән:
Гаеп сездә,
Дигән кебек
Ача тибеп, -
Дип ишекләр
Сөйләшәләр,
Бергәләшеп
Киңәшәләр, -
Бу гадәтен
Ташламаса,
Яхшы укый
Башламаса,
Без туктыйбыз

Ачылудан.

Җитәр, туйдык

Ачынудан!”

1961

**Ай нигә үрти?**

Тимер шарчык тапты Басыйр,

Җепкә бәйләде;

Кулындагы шарчык

Зыр-зыр әйләнде.

Шар ычкынып тәлинкәне

Ярып та атты.

Әни күрмәсен дип Басыйр

Чыгып та чапты.

Күктә Ай белгән! Басыйрны

Үртәде көлеп,

Яртысы ватылып төшкән

Тәлинкә кебек.

1961

**Төшеним дисәң сөю серенә...**

Буйга җиткән кыздай тулган ай,
Ярсыз йөргән кыздай боек ай,
Әйтче, нигә туган ягымда
Чит җирләрне сагынам мин болай?

Ай, ул җирләр, Иртыш буйлары,
Мәхәббәтем шыткан җир икән,
Сөйгән ярың калган чит җирләр
Туган җиреһ белән бер икән.

Ул еракtан тагын матуррак,
Акыллырак булып күренә.
Ераккарак китеп тор икән
Төшеним дисәң сөю серенә.
1961

*********

Ап-ак карлар – кышкы ромашкалар
Явып торган тыныч бу төндә.
Әй, уйный бит, уйный шат елмаю
Алсуланып янган битеңдә.

Мөмкин булса хәзер бар дөньяны
Кочып алыр идең берьюлы.
Күзләреңдә җирнең мең шагыйре
Әйтеп бетергесез сер тулы.
1961

**Беренче мәхәббәт**

Кичә генә әле синең
Җилбәзәк чагың иде.
Һәр очраган  матур егет
Хыялый ярың иде.

Театрга баргач, сине
Яшь артист гашыйк итте,
Күзе ялгыш сиңа төшсә.
Йөрәгең дөрләп китте.

Урамнарда очрап куйса
Чем кара мыеклылар,
Күзкәйләрең нурлар чәчеп
Шуларга юлыктылар.

Техникумның залларында
Биюләр вакытында
Чак-чак янып бетми калдың
Мәхәббәт ялкынында.

Һәр биегән өч егетнең
Берсенә гашыйк булдың,
Өйгә кайтыр вакыт җиткәч,
Әллә ник ялгыз калдың.

Лекцияләр тыңлаганда
Тәрәзгә карый идең,
Сөяр өчен чираттагы
Егетне сайлый идең.

Белмәдең тик янәшәңдә
Утырган Рахманкулның
Урындыгы синең янда
Булуга шатлануын.

Сиңа туры карый алмый
Оялып йөргәнлеген,
Йөрәгенә исемеңнең
Җыр булып кергәнлеген.

Шул Рахманкул белән бер кич
Эңгер-меңгер чагында
Син кинога барган идең,
Болай дусларча гына.

Әллә нәрсә буды бу кич:
Шул кино юлларында.
Сихерләндең шул егетнең
Күзләре нурларында.

Шул Рахманкул сүзсез генә
Бүләк итте сиреньнәр
Бик мөлаем тибрәнешеп
Куйды синең иреннәр.

Син карадың йолдызларга,
Беренче күргән кебек,
Шул йолдызлы күкнең серен
Син генә белгән кебек.

Җилбәзәклек очып китте,
Ул кире кайтмас инде.
Яндырырга, көйдерергә
Сиңа мәхәббәт килде.
1962

**Төн**

Каен толымнарын аралап,

Ай яктысы кергән бүлмәгә.
Ак мендәрдә яткан яшь кызның
Маңгаена төшкән күләгә.
Йокы алмый уйчан күзләрен –
Йомыла да тагын ачыла.
Таңда кызны озын юл көтә,
Тынгы белми, йөрәк борчыла.
Үзе – туган йортта булса да,
Сәфәр чыккан инде уйлары.
Ишетелә кебек колакка
Ерактагы тайга шаулары.
1962

*****

Мин чәчәкләр бирдем. Син алдың.
Елмаюың миңа зур бүләк,
Шуннан артык миңа ни кирәк.
Хуш ис тулы тыныч май төне.
Кошлар йоклый изрәп талларда.
Күз кысыша күктә йолдызлар,
Нур яңгыры ява алардан.
Таралганнар яшьләр өйләргә,
Эреп беткән гармонь моңнары.
Тирән тынлык сарган дөньяны,
Тын йокыда авыл таллары.
1962

*****

Хатын, шатлан, сөенеч!
Тәмәкедән биздем ич.
Инде тузып йөрмәссең,
Төтен затын күрмәссең.
Тәүфикланыр көн килде,
Я бер, җаным, көл инде.

Менә шулай!
Ә хәзер
Үзең дә беләсеңдер:
Сөенечтән, алтыным,
Алып кайт бер яртыны.
1962

**Яз**

Кәрван булып болыт агыла,
Күктән җиргә ширбәт сибелә.
Томан тора Идел өстендә
Тирбәлгәләп йомшак җил белән.
Тагын кояш карый елмаеп,
Тагын дөнья нурга күмелә.

Тәүге бөре исе аңкыта
Агачларның яшерен сулавы.
Чак-чак кына кагыл каенга –
Чәчрәп чыгар кебек сулары.
Умырзая башын калкыта.
Бер дә исе китми салкынга.

Сикерә-сикерә елга-күлләргә
Кар сулары йөгерә таулардан.
Моторларны эшкә чакырып,
Үлән исе җәелә кырларга.
Әй, яз килә, дуслар, яз килә
Тиңдәш булып безнең җырларга.

Килә яңа яшеллек алып
Табигатьнең иң матур кызы.
Килә шаулап, килә гөрелдәп
Ватанымның үзедәй язы.
1962

*****

Миңа һаман да син усал кара,
Әгәр җылы, назлы карасаң,
Минем күңел канатланып китә,
Туган кебек була яңадан.
Бул шәфкатьсез, таш бул миңа, зинһар,
Миңа карап алай елмайма,
Ул үзе дә сөя икән дигән
Алдануга миңа юл куйма.
Миңа бул шәфкатьсез, усал бул син,
Сүндер миндә янган бу утны.
Җиткер миңа сине уйламыйча
Башка белән кавышыр минутны.
1963

*********

Син кабыздың миндә мәңгелек ут,
Гомер буе дөрләп янарга.
Мәҗбүр иттең бөтен матурлыкка
Синең төсең итеп карарга.
Таңның алсулыгын күреп син дим,
Көннең аязлыгын күрәм дә
Җылы кояш нурын син дип тагын,
Чәчел, сибел минем тирәмдә.
Чәчләреңнең сихри сибелүе
Күләгәле мәрмәр маңгаен.
Күзләреңдә тулган очкыннар ул –
Сөю билгеседер, мөгаен.
1963

**Яңгырсыз болыт**

Офыклардан күк йөзенә

Килеп чыкты бер болыт

Һәм мактанды менә хәзер

Явам дип яңгыр булып.

Дөрес, тамды җир өстенә

Өч-дүрт бөртек тамчысы.

Моннан нинди файда күрсен

Үләннәрнең кайсысы?

Галим дә бит шул болыттай,

Хезмәтләре булмаса,

Дәрәҗәле исем алгач,

Эзләнүен ташласа.

1963

*****

Кичке күктә кызыл шәфәкъ яна,

Үзе яна, үзе җылытмый.

Бик якын син, бәгърем, ләкин салкын,

Тик шулай да

Күңел сине бер дә онытмый.

*****

Күзләреңдә тулы очкыннар.

Күзләреңнән тулып ташсыннар.

Йөрәгемә минем үтәләр,

Анда янгын ясап китәләр.

*****

Кайт, кайт инде. Сагынудан
Сабырлыгын җуя башлаган
Еллар буе килгән авырлыкның
Авырлыгын тоя башлаган
Йөрәгемне дәваларга кайт, кайт инде.

*****

Мин дулкын, син кыя,
Бер шашам, бер тынам.
Син һаман җавапсыз,
Мин дулкын, син кыя.

*****

Кар сулары вак-вак көзге,
Кар сулары туңмаган.
Кар сулары, карак кебек,
Ай нурларын урлаган.

*****

Күк, куяндай, төсен алыштыра,
Сорылыкны куа зәңгәрлек.
Урам гашыйкларны кавыштыра,
Тәннәр белән уйный тәңгәллек.

*********

Син ирештең изге максатыңа:
Барып чыктың мода чигенә.
Безнең кебек модасызлар инде
Хәзер синнән өркеп чигенә.

*********

Ерак җирдә кабердәшләр булып,
Егылганнар безнең әткәйләр.
Бу хәбәрне чал чәчләргә яшереп,
Саклаганнар безнең әнкәйләр.

**Бер үзеңдә**

Күзләмим мин һәр очраган йолдызны;
Күрәм синең бер үзеңдә йөз кызны.

*****

Син үзең дә шулай, минем кебек,
Һаман читтә, һаман еракта.
Кеше туйларында булган чакта
Нәрсә икән синең йөрәктә.

**Тиң булмаганда**

Йөзләреңдә синең ай нурлары,
Йөрәгеңдә - горур очыну.
Сиңа карап туа ләззәтләнү,
Ә үземә карап – очыну.

*****

Расмы, әйтче. Күзләреңдә тулган
Очкыннарның сөю булуы?
Зиһенемне ала йөзләреңнең
Алма кебек балкып тулуы.
1964

*****

Син урнаштың миндә.
Хәзер инде
Күңелемдә синең сурәтең.
Минем уйлар тулы синең белән,
Сине уйлап үтә ялгыз төн.
Син урнаштың миндә мәңгелеккә,
Күңелемдә тоташ яз гына.
Бу җырларым үзең төсле булып,
Ал чәчәкле булып языла.
Син урнаштың миндә күңелемне
Ал моңсулык белән тутырып.
Син урнаштың миндә бик ягымлы
Түгәрәк ай кебек яктырып.
Син кабыздың миндә мәңгелек ут
Гомер буе дөрләп янарга.
Мәҗбүр иттең бөтен матурлыкка
Синең төсең итеп карарга.
Таңның алсулыгын күреп син дим,
Көннең аязлыгын күрәм дә
Җылы кояш нурын син дим тагын
Чәчел, сибел минем тирәмдә.
Чәчләреңнең сихри сибелүе,
Күзләреңнең уйчан карашы,
Йөзләреңнең тулы елмаюы –
Алар минем йөрәк ярасы.
Чәчләреңнең сихри сибелүе
Күләгәли мәрмәр маңгаең.
Илаһи бер якты нурлар белән

Балкыйсың син, нурлы җан аем.
Чәчләреңнең сихри сибелүен,
Күзләреңдә бик-бик тирәндә
Мин аңламас булып яшеренгән
Адаштыргыч серләр күрәм дә,
Йөзләреңнең тулы елмаюын,
Синдәгедәй сафлык, пакьлекне,
Синдәгедәй сихри уйчанлыкны,
Синдәгедәй нурлы шатлыкны
Алмаштыра торган башка берәү
Минем өчен җирдә табылмас;
Беркемгә дә минем җан җырларым
Йөрәк каным белән язылмас.
Наз патшасы!
Бөтен гәүдәң синең
Җылы наздан, яздан гыйбарәт.
Мин адаштым синең урманыңда,
Синең урманыңда мин карак.
1964

*****

Иркәлисе килә сыйпап чәчләреңнән
Үзең кебек матур сүзләр әйтеп кенә,
Һәм тотасы килә сине гел каршымда
Сабый чакта күргән төшем итеп кенә.

*****

Яшьлегемнең таңы күптән аткан,
Чәчәкләре яна кулымда.
Бул син миңа юлдаш, иптәш бул син,
Шатлыгым бул минем юлымда.
1964

*****

Ялгышыпмы, әллә шаярыпмы,

Бер елмаеп көлгән булдың да,

Язда искән уйнак җил шикелле

Чак-чак кына кагылып алдың да,

Эзләреңә ияртеп уйларымны

Әллә кая китеп югалдың...

Һәр сыйпаган язгы җилләрне мин

Кайту хәбәрең дип юрадым.

1965

**Балалар**

Минем алда кырык ата баласы

Һәрберсенең

Килә яхшы исем белән аталасы,

Үз эшенә тиешлесен аласы,

Танылысы һәм, әлбәттә, макталасы.

Башта мин берсен дә танымый идем.

Таныттылар.

Эш арттырдылар.

Башта мин арымый идем.

Ә арырга тели идем.

Арыттылар.

Аннан яраттылар.

Яраттырдылар.

Күнегүне эшләмичә килгәне дә,

Дәфтәр өйдә калган дигәне дә,

Үзе иҗат иткән кәгазь очырткычтан

Ләззәтләнеп башы күккә тигәне дә –

Кырыгы да җаны белән, күңеле белән

Тели яхшы исем белән аталырга,

Үз эшенә тиешлесен алырга,
Танылырга һәм, әлбәттә, макталырга.
1965

**Диалог**

- Гел авылда (үтте гомерең)... Җиттең кырыкка
Мәхрүм калып кырык кызыктан.
Шундый башың була торып та
Үтә гомерең сансыз тыкрыкта.

Безгә тигән алтын елларның
Рәхәтләрен җилгә очырдың.
Юләр син, күрмәгәч бу чорның
Могҗизалар тулы юлларын.

- Мин бер генә юлны сайладым,
Яңа юллар эзләп йөрмәдем.
Бу бердәнбер авылым эчендә
Бар илемне тойды йөрәгем.

Тыкрыктагы агач йортымнан
Үр башында торган мәктәпкә
Алып барган юлда йөргәндә
Коенам мин бәхет-рәхәткә.

Шушы юлда барлык юлларның
Бөтен бизәкләрен табалам.
Ә балалар белән мин бөтен
Ил кырына тарала алам.
1966

**Кайт инде**

Сагынудан
Сабырлыгын жуя башлаган,

Еллар буе килгән чыдамлыкның
Авырлыгын тоя башлаган
Йөрәгемне дәваларга кайт инде, кайт.

Зәңгәр күлнең айлы төндә
Икебезнең пар шәүләсен
Тирбәтәсе килә.
“Икәү икән!” – дип
Тирәкләрнең әйтәсе килә.

Күзләреңнең диңгезенә
Табынуым, пакьлегем белән
Мәңгелеккә керәсем килә.
1966

**Бертуктаусыз җиһан үзгәрүдә**

Класс тәрәзәңнән карап торган
Ак каеннар һаман үзгәрә:
Кайчан гына әле яшел иде,
Хәзер күзгә сары төс бәрә.

Бертуктаусыз җиһан үзгәрүдә.
Әнә юлда бара машина.
Шофёр егет карап үтеп китте
Үзе укыган класс каршыннан.

Мин хәтерлим: ул утыра иде
Әнә шунда – арткы партада,
Кул күтәрми сорау бирә иде
Һәм өйрәнгән иде тартырга.

Бертуктаусыз җиһан үзгәрүдә:
Ул партада инде башка бер
Яшькелт күзле малай – мут, хәйләкәр –

Минем өчен тудыра яңа сер.

Күнегүне мин кушканча түгел,
Ул эшләгән тагын үзенчә;
Тагын качып кызык китап укый,
Кисәткән бар инде берничә.

Бертуктаусыз җиһан үзгәрүдә,
Әле яшел, әле сары төс.
Үзем генә үзгәрмәгән кебек,
Миңа мәңге килмәс кебек көз.

1966

**Яшәү турында уйлану**

Тормыш нинди генә яхшы булып,
Яшәү ничек рәхәт булса да,
Һәм докторлар гомер озайтуда
Яңа юллар ачып торса да,
Илем!
Барыбер, барыбер синең кебек
Җир өстендә мәңге торалмам,
Синең чиксез гомер белән ярышып
Ерак гасырларга баралмам.
Бөек еллар куе чәчләремне
Сиздермичә генә кояр да,
Алма кебек шома йөзләремә
Бетми торган сырлар уяр да,
Картаермын.
Ләкин барыбер, илем,
Йөз еллыгың бәйрәм итәрмен.
Бабайларча салмак адым белән
Кырларыңнан атлап үтәрмен.
Син йөз елга яшәргән булырсың
Коммунизм күге астында.
Көче ташып торган егет кебек

Елмаерсың минем каршымда.
Мин күрермен синең шат йөзеңдә
Гомеремнең үлмәс бизәген.
Кырларыңда калыр мәңгелеккә
Хезмәт белән үткән эзләрем.
Килер буын мине,
елъязмадан түгел,
Кырларыңа карап белә алса,
Минем хакта:”Илен яшәртү өчен
Картайган ул, үлгән,” – диялсә
Кирәк булмас миңа башка бәхет,
Шул юатыр минем күңелне.
Урын биреп яңа туганнарга
Тыныч каршылармын үлемне.
1967

**Урак өсте**

Авыл тып-тын. Игенчеләр кырда,
Уңыш яулый күмелеп алтын нурга.
Офыкларда очынып бии рәшә,
Башакларга сыенып җил серләшә.
Ак болытлар иркәлиләр җирне,
Күләгәләр йөри арлы-бирле.
Дөнья тулы тәмле башак исе,
Хозур монда янып эш эшлисе.
Җиде җирдә, җиде штурвалда,
Җиде ирнең алтын кулы анда.
Нәкъ үзләре кебек батырланып
Эшли комбайннар моторлары.
Ике Сәлим, ике Гомәр әнә,
Госман, Рәхим, Искәндәрләр янә
Зур көрәштә ярышалар кызып,
Центнерларда берсен-берсе узып.
“Сүнмәс дәрт”не суза шофёр Заһир,

Җитмеш төрле һөнәргә ул маһир.
Яшь Сәлимгә әнә йөкче Роза
Кара керфекләрен сирпеп уза.
Эштән соң карт Сәлим шаярткалый:
Бункерында ничә тонна гыйшык бар, ди.
1967

**Сентябрьнең тәүге иртәсе**

Мине котлагандай, тәрәзәдән
Сузды кояш нурлар көлтәсен.
Сәлам сиңа, аяз булып туган
Сентябрьнең тәүге иртәсе.
Күптән инде, сигез яшьтән башлап,
Шушы иртә җитте түгелме –
Дулкынланам бәйрәм көндәгедәй,
Җылы хисләр күмә күңелне.
Бүген дә мин яшел урамнардан
Ашыга-ашыга барам мәктәпкә.
Бакчаларда соңгы гөлләр көлә,
Ак каеннар талган рәхәткә.
Укучы да түгел, студент та...
Укытучы булып атлыймын.
Ал галстук таккан балаларда
Куанычым минем, шатлыгым.
Пионерлар миңа чәчәк бирә,
Чәчәк белән тула кочагым.
Мин бүгеннән зур тормышка керәм,
Артта кала гамьсез яшь чагым.
Пионерлар минем балачакны
Бөтен шарты белән кабатлар.
Гизәр әле галәм киңлекләрен
Алар йөрткән космик кораблар.
Их, аларны тормыш кырларына
Көчле итеп килә илтәсе...
Теләгемне хуплап балкып тора

Сентябрьнең тәүге иртәсе.
1968

**Күрше**

Минем башка кайгы килсә,
Рәхмәт инде, күрше керә.
Уртаклашып хәсрәтемне
Сүздән дару ясап бирә.
Шатлык килсә, каһәр суксын,
Күршем шундук бозылып китә.
Керү түгел, очраганда
Сәламен дә бирми үтә.
Шатлыкны мин гүя аның
Йөрәгеннән алган урлап.
Йөри иркенлеген җуйган
Читлектәге коштай пырлап.
Елмайсам да яратмый ул,
Биесәм дә ошатмый ул,
Җырласам да, уйнасам да,
Барыбер эчен бушатмый ул.
Ә еласам, башны иеп,
Ул яныма шундук килә.
Хәсрәтемне уртаклаша,
“Хафаланма” ди дә... көлә.
1968

**Утыз яшь**

Миңа, утыз тапкыр чәчәк атып,
Чәчәкләре җирнең елмайды.
Утызынчы тапкыр беренче кар
Аягымнан үбеп җырлады.
Үтте язым. Ярсу ташудан
Шифалы ләм калды басуда.
Килеп җиттем сиңа, җәй башы,

Төпле акыл булсын юлдашым.
Бер югалып, тагын күренеп,
Ак бөртекләр уйный чәчемдә
Мин китергән шатлык эчендә
Улым көлә, нурга күмелеп.
1968

**Укытучыма**

Менә шушы олы бәйрәмеңдә,
Гомереңнең иң зур яшендә
Сиңа булган иң зур хөрмәтне мин
Ничек әйтим шигырь телендә?
Елларга син күп көчеңне бирдең,
Ә үзеңә еллар ни бирде?
Алар сиңа халык йөрәгенең
Мәхәббәтен алып китерде.
Шатлыклары-кайгылары белән
Күпме көннәр үткән йөгереп.
Һәм меңләгән дәфтәр битләренә
Күз нурларың калган түгелеп.
Туган илнең иркен кочагында
Күпме якты, олы юллар бар.
Шул юлларда синнән белем алып,
Сине сагынып йөргән уллар бар.
Менә шушы олы бәйрәмеңдә
Син лаеклы иң зур рәхмәткә.
Бөтен сәләтеңне, акылыңны
Кызганмыйча бирдең мәктәпкә.
1968

**Печән өсте**

Без, биш егет, печән күтәрдек,
Ә син тордың кибән башында.
Маңгаеңнан шыткан тамчылар

Көмешләнде кыйгач кашыңда.

Без, биш егет, печән күтәрдек,
Синең куллар җитез өлгерде.
Күкне болыт басты, яшен аты
Дөбер-шатыр килеп йөгерде.

Син елмайдың өстән түбәнгә,
Тешләреңнән ап-ак нур атып.
Матурлыкка куйган һәйкәлдәй
Биш егетне үзеңә каратып.

Син елмайдың өстән түбәнгә,
Дулкынланды калку күкрәгең.
Салют биргән кебек хезмәткә,
Баш очында күкләр күкрәде.

1968

## Синсез калган урамда

Ничәнче кат кайтам яшьлегемә,
Һаман  шулай шаулый бу урам.
Синсез калган йортның каршысында
Күпмегәчә болай мин торам.

Монда кичләр күзләреңдәй зәңгәр,
Өрәңгеләр күксел эңгердә.
Йөгереп чыгарсың да җитәкләшеп
Йөрербез күк тагын без бергә.

Монда төннәр чәчләреңдәй җылы,
Без вәгъдәләр биргән чатларда.
Мәңгелек сер булып юкәләрдә
Безнең хатирәләр саклана.

Монда таңнар йөзләреңдәй алсу
Таң җилләре синдәй ягымлы
Синең кебек балкып кояш чыга,
Дәваларга теләп җанымны.
1968

**Урын биреп яңа туганнарга...**

Тормыш ничек кенә кызык булып,
Яшәү ничек татлы булса да,
Һәм докторлар гомер озайтуда
Яңа юллар ачып торса да,

Татарстан, барыбер җир йөзендә
Синең кебек озак торалмам,
Синең озын гомрең белән ярышып
Ерак гасырларга баралмам.

Шаулы еллар ефәк чәчләремне
Сиздермичә генә кояр да,
Җилгә каршы барган йөзләремә
Бетми торган сырлар уяр да,

Картаермын. Гомеремнең кичен
Мин үземчә бәйрәм итәрмен.
Бабайларга салмак адым белән
Кырларыңнан атлап үтәрмен.

Син яшәргән булырсың йөз яшькә
Мөстәкыйльлек күге астында,
Көче ташып торган егет кебек
Елмаерсың минем каршымда.

Мин күрермен синең шат йөзеңдә
Гомеремнең үлмәс бизәген:

Кырларыңда мәңгелеккә калган
Гади хезмәтемнең эзләрен.

Яшьләр мине елъязмадан түгел,
Кырларыңа карап беләлсә,
Минем хакта: “Илен яшәртү өчен
Картайган ул шулай”, - диялсә,

Кирәк булмас миңа башка бәхет,
Шул юатыр минем күңелне.
Урын биреп яңа туганнарга,
Тыныч каршылармын үлемне.
1968

### Туган кырларым

Әй кырларым,
Таңнар аткан саен
Мине сөеп каршы аласыз.
Яшьлегемә тәңгәл килә торган
Чәчәкләр дә эш тә табасыз.

Бик-бик яшьләй сезнең киңлекләдә
Кулларымның көчен сынадым.
Сандугачлар моңы белән катыш
Тракторлар җырын тыңладым.

Бик-бик яшьләй күңел ияләште
Иртән битен юган гөлләргә,
Йомшак кына канат җилпи-җилпи
Баштан сыйпап искән җилләргә.

Яраттым мин айның тын Зөягә
Таллар белән суга керүен,
Төннәр буе көмеш тарак белән

Арышларны тарап йөрүен.

Яңгыр килә ди-ди баш очында
Очкан карлыгачлар көтүен,
Сыерлар холкын яттан белгән кызның
Җәйләүләргә эшкә китүен...
(Ул кыз миңа көлеп бакса да,
Гыйшкы булган икән башкада)

И кырларым,
Ташлый алмыйм сезне,
Сез бит минем өчен тиңдәшсез.
Канатымны тулы җаяр өчен
Иркен дә сез, зур да, киң дә сез.
1968

**Ялган шөһрәт белән түгел**
**(Эшең – эзең)**

*И мөкатдәс нәрсә - эш*
*Г.Тукай*

Ялган шөһрәт, даннар белән түгел,
Эшең белән калдыр эзеңне.
Эзләп тапсын кеше мәхәббәте
Тормыш эчләреңнән үзеңне.

Хурлык – юньле нәрсәң булмый торып
Кеше телендә йөрсәң макталып.
Гомерең буе тырышып эшләү булсын
Тормышыңның бөтен максаты.

Син яңгырсыз болыт кебек булма,
Атаклы зат булып кыланма.
Күренергә теләп яхшы атлы,
Биек җиргә таба юлланма.

Дөнья бик киң,
Бик күп гали затлар, -
Менә шушы бик-бик күпләрнең
Кечкенә бер өлеше булып кына
Яулап була биек үрләрне.

Матур сүзең, ыспай гәүдәң түгел,
Данга кумәр сине хезмәтең.
Сандугачны тыңла, - күренми дә, -
Җыры белән ничек хөрмәтле.

1969

**Гыйлем генә нурлый бәндәне**

Аллаһының нигъмәтләре чиксез:
Протоннар, галактикалар...
Иң-иң хикмәтлесе – тик кешеләр,
Аң-акылга ия тик алар.

Җиргә кеше итеп тудырганга
Көн-төн рәхмәт укы Раббыңа.
Яшисең син ап-ак күңел белән,
Хакның сүзен әйтеп халкыңа.

Тынмый арттырасың гыйлемеңне,
Хак дин белән бәйләп фәннәрне.
Гыйлем генә ача хакыйкатьне,
Гыйлем генә нурлый бәндәне.

1969

**Алтын көзем**

Яфрак оча, яфрак оча
Яфракларны тоҗым коча,
Җил исә дә кочагыннан
Барсы җиргә төшеп кача.

Барсы җиргә төшеп кача,

Кыштыр-кыштыр итә бакча.
Шул бакчада канат җилпеп
Сөйгән Көзем күңел ача.

Сөйгән Көзем күңел ача.
Бер кайгысыз шук малайча,
Аңа дөнья тик алтыннан,
Бизи җирне ул яңача.

Бизи җирне ул яңача,
Карашыннан бәхет таша.
Белми әле кыш килерен –
Бер дә гамьсез күңел ача.
1969

**Гадәттән тыш күл**

Сугышларда һәлак булган
Уллары өчен
Аналарның еллар буе
Түккән күз яшен
Бергә җыйсаң,
тозлы, әче
Күл булыр иде.
Ул үч, нәфрәт давылыннан
Чайкалыр иде.
Бер җәллад та бу дәһшәттән
Котылмас иде,
Барысын упкынга йотмыйча
Күл тынмас иде.
1969

**Кешелек акылына**

Һәрбер елдан үзеңә өлеш алып
Үттең мең-мең еллар арасын.
Бар нәрсәдән якты нурлы булып,
Мәңгелеккә таба барасың.

Көчең белән безгә якыная
Күктә янган ерак җисемнәр.
Синең белән мәңгелеккә үтә
Үлемсезлек алган исемнәр.

Хәзинәңдә күпме байлык тулы,
Тормыш өчен алар барсы да.
Акылсызлар ләкин байлыгыңнан
Бомба ясап чыга каршыңа.

Үт син, акыл, яңа киңлекләргә,
Җиргә сугыш уты капмасын.
Хиросима көйде,
ләкин башка инде
Акылсызлар урын тапмасын.
1969

**Кеше**

Дүрт аяклы ат та абына дип,
Көрәшләрдә күңел юатсаң,
Әтәч тә бит көнли дип, әтәчтән
Үрнәк алып, акыл югалтсаң,

Йөзең тоташ елмаюда булып,
Йөрәгеңдә бүре уласа,
Я күршеңә кайгы килгән чакта,
Җаным тыныч диеп суласаң,

Күпне белгән тиз картая диеп,
Гамьсезлектән пәрдә ябынсаң,
Мин кеше дип күкрәк кыйнама син,
Урынсызга алып булмый сан.
(Кешеме син?
Кеше бөек була,

Фәкать анда гүзәл җан булса.-)

Кеше – бөек.
Ул – чәчәктән нәфис,
Тимердән нык, таштан катырак.
Вулканнардан көчле, җилдән җитез,
Кояш-йолдызлардан яктырак.

Кеше җирнең бөтен матурлыгын
Үзенә җыйган бөек баласы.
Ул – тән генә, матди генә түгел,
Шуңа кыен кеше буласы.
1969 июль

**Гомергә ян, уңышлар көт**

Җитмеш тулган икән – тулсын,
Артка түгел, алга кара.
Ясалган дип күп хаталар
Йөрәгеңә алма яра.

Ул хаталар - яшькә сабак,
Ул шулардан гыйбрәт ала,
Хаталарын урап узып,
Ялгышмыйча алга бара.

Үкенмә син бу дөньяны
Алмадым дип шаккаттыра.
Гадилегең яшьләр өчен
Үрнәк булып балкып тора.
1970

*********

Үтте урак өсте. Көн сүрелде.
Кырлар чишенеп ятты йокларга.
Җыелдык без хезмәт туена
Батырларын эшнең котларга.

Бүләк арты бүләк. Тулы зал
Яңгырап кыны тора алкыштан.
Ә син, күрше, шундый бәйрәмдә
Башың идең нинди сагыштан.

Күзләреңдә сәер ут яна,
Карыйсың тик кашың җыерып,
Утырасың теләр-теләмәс,
Кара болыт кебек куерып.

Әгәр сине мактап үтсәләр,
Башкаларны тотып сүксәләр,
Елмаерга әзер торасың.
Газаплый бит сине көнләшү –
Бабаңнарның яман йоласы.

Бар бит әле синең кебекләр:
Бәйрәмнәрдә төсен бозалар.
Дусларының көләч йөзенә
Ачу белән карап узалар.

Аерым бәхет көт син, кайгырма,
Аерым кояш чыксын өстеңә,
Бәлки, шулай булыр.
Шул чакта
Аерым бәйрәм яса үзеңә.

1970

## Шагыйрьгә

Сандугачтан, шагыйрь, үрнәк ал:
Эзләмә син биек урынны,
Күрмәсә дә халык үзеңне –
Буй-сыныңны, төс һәм йөзеңне,
Ишетсен ул, белсен җырыңны.
Сандугачтан, шагыйрь, үрнәк ал.
1970

**Зарлану**

Горурлану хисен югалткан
Кешеләргә кыза минем кан:
Торсалар да яхшы йортларда,
Менә дигән әйбәт шартларда
Ләгънәт укый алар тормышка,
Зарланалар батып сагышка.
Йөри алар лозунг* таратып,
Чынбарлыкны бары каралтып.

“Заманалар калды авырга,
Ничек болай алга барырга?!
Хатыныма кирәк ак төймә, -
Һәр кибеткә кердем – юк төймә.

Кайда мәкле күмәч? Юк шул, юк,
Юк сатуда күркә шулай ук.
Артачак, ди, тозның бәясе, -
Безнең башка килер бәласе.

Кирәкмәгән нәрсә ручканың
Күтәрәләр нигә соң хакын?

Менә, малай, анда АКШта
Яшиләр ди гаҗәп тормышта:
Анда һәрбер җанның башына
Туры килә диләр машина.

Ун костюмы бар ди һәркемнең,
Яңа күлмәк кия һәркөнне.

Ит табында иллә дә мәгәр
Күпме кирәк – аша шулкадәр”.

Шулай диләр дәү-дәү абыйлар,
Гүя мәми көткән сабыйлар.

Күктәнмени төшсен ул муллык,
Хуҗа булгач сиңа ялкаулык?!

1970

*Шигарь - лозунг

**Әкиятләргә ышанам мин**

Балачакта нәрсә, тик хыяллан,
Тамак та тук, мич тә ягылган...
Мин ышана идем әкиятләргә.
Ләкин алар безнең авылдан
Ерактадыр кебек тоела иде.
Камыр батыр кебек әгәр дә
Чыгып китсәң ерак сәфәргә.
Барып чыгармын күк иде
Князь Гвидон торган шәһәргә,
Тавык аяклары өстендәге
Ишек-тәрәзәсез йортка да...
Һәм нинди шәп:
Яшәрткеч су алып кайтып бирсәң,

Авылдагы һәрбер картка да.
Галәү абзый кабат егет булса,
Мәйдан тотса минем аркада.
Мин ышана идем әкиятләргә.
Рәхмәт сиңа, зәңгәр романтика!
Тулыр-тулмас вакыт унҗиде,
Туган җирдән, әниемнән аерып,
Алып китте мине таң җиле.
Еламадым, елмайдым гына.
Әни күз яшьләре аркылы
Уйлагандыр: каты бәгырьле дип,
Туган җирен онытыр ахыры.
Бәхет эзләп, данга сусап түгел,
Бары Камыр батыр шикелле.
Дөнья күрү теләге тик мине
Калын тайгаларга,
Ярсу елгаларга,
Шәрә далаларга
Һәм аларда туган калаларга
Гади эшче итеп китерде.
Җирнең киңлегенә,
Һәр киңлектә
Туган могҗизага шатланып,
Дуслар белән бергә зур юллардан
Хезмәт итә-итә атладым.
Малайларча үзсүзлелек мине
Һаман алга, һаман яңага
Әйди торды, чөнки һәр яңалык
Яңа утлар бирде янарга.
Дөнья күргән саен яшәвемнең
Башлангычы – туган авылны,
Авыл белән бергә әниемне
Күбрәк сөеп, күбрәк сагындым.
Дөнья күргән саен әкиятләргә
Мин тагын да күбрәк ышандым.

Күбрәк күрдем чынга ашуларын
Һәм үзем дә күбрәк көч алдым.
1970

**Эштән кайтканда**

Безне хезмәт үзе табыштырып,
Үзе кавыштырган.
Без бергә.
Фермадан гел менә хәзергедәй
Бергә кайтсак икән гомергә.
Их.
Ап-ак карлар – кышкы ромашкалар
Явып торган кышкы бу төндә
Әй уйный бит, шат елмаю
Алсуланып янган битеңдә.
Мөмкин булса хәзер бар дөньяны
Кочып алыр идең берьюлы.
Күзләреңдә җирнең мең шагыйре
Әйтеп бетергесез сер тулы.
Мин бәхетне күрәм, тоям: ул – син,
Ул син минем җанлы Карбикәм.
Эш артыннан туган шатлыктан да
Татлырак хис тагын бар микән.
1970

**Тынлык сөяр булсаң**

Тынлык сөяр булсаң, хуш мәңгегә,
Кирәксенмим андый юлдашны.
Барыр юлым чөнки тапталмаган,
Үтәсе бар бик күп тау-ташны.

Бер абынып, тагын күтәрелеп,
Бер ялгышып, тагын төзәлеп,
Янар йөрәкләргә кулны биреп,

Җанлы курчакларга кизәнеп,
Үтәсем бар бик күп тау-ташны.

Егетләр бар: тел-теш тидергесез,
Курчак кебек матур, ваемсыз.
Тирләми дә алар, тиргәлми дә,
Телләрендә һәрчак ай-йолдыз.

Юлның уртасына җиткәч түгел,
Мин кисәтәм сине алдан ук:
Минем хакка тынарсың ла бер дип
Чыкма юлга ялгыш алданып.

Йөрәгемдә мәңге күкләр күкрәр,
Күзләремдә чагылыр яшеннәр.
Ничек соң син, юлдаш, дус булырсың
Миннән куркып йөзең яшерсәң.

Сирәк булыр тузган чәчләремнең
Майлап шомартылган чаклары.
Мөмкин түгел юлда чалбарны да
Үтүкләнгән килеш саклавы.

Януларым минем яшәү өчен,
Ирешер өчен түгел зур данга.
Тынлык сөяр булсаң, хуш мәңгегә,
Тынарымны көтеп алданма.
1970

**Әтигә**

Без тиңләштек, әти, яшь ягыннан,
Икебез дә чәчәк кебекләр,
Чыгып басыйк әни каршысына,
Без – егерме яшьлек бөркетләр.

Егерме яшь!
Язгы Идел кебек
Шаулап аккан чагы гомернең.
Үтеләсе еллар алда, ди-ди,
Канатланган чагы күңелнең.

Алда, бер-берсеннән якты булып,
Алмашыныр бик күп иртәләр;
Еллар мине, бәлки, картайтырлар,
Чал сакаллы бабай итәрләр.

Ә син, әти,
Буйсынмассың еллар агышына,
Гел егерме яшьтә калырсың.
Минем аша,
Оныкларың аша
Киләчәккә атлап барырсың.

Син, картаймас өчен,
Үлмәс өчен,
Саклар өчен яшьлек чагыңны,
Туган илнең газиз туфрагына
Агызгансың соңгы каныңны.
1970

*****

Рәхмәт сиңа, Җирем, эш кешесе
Басып үткән һәрбер төшеңдә
Үреләләр гөлләр күккә, янә
Йортлар калка синең өстеңдә.
Рәхмәт сиңа, Җирем, эш кешесе
Кулы тигән һрбер почмагың
Кеше өчен, кеше бәхете өчен

Тулы ача үзенең кочагын.

Рәхмәт сиңа, Җирем, эш кешесе

Тире тамган синң туфрагың

Агач кәүсәләрен торгыза да

Елмайдыра мең-мең яфрагын.

1970

*****

Юлга чыксам, һич тә йөреп туймыйм,

Гел барасым килә, барасым.

Биегәндәй җиңел атлап узам

Хисапсыз күп чакрым арасын.

Чәчәкләргә баксам, күзем туймый,

Гел карыйсым килә, карыйсым.

Сулар сибеп, өф-өф итеп кенә

Иркәләргә телим барысын.

Түзә алмый йөрәк ярсуыма

Сикреп төшсәм агым суларга,

Дулкыннардан күчсәм дулкыннарга,

Ару сизмим һич тә кулларда.

Чалгы алсам, чалгым җырлый башлый,

Печән җитми чабып туярга

Гармонь тотсам, күңелем һаман саен

Гел уйнарга куша, уйнарга.

1970

**Такташка**

Егерменче еллар дәвамында

Өлгермәдем җиргә туарга.

Мин соңардым,

Ә син инде ашыгып,

Чыгып киткән идең юлларга.

Күрми калдым,

Киләчәккә таба

Өмет белән киттем артыңнан

Җирнең күкрәгендә синең эзләр
Шигъриятең белән яктырган.
Шигъри чәчәкләрне бик мул итеп
Олы мәхәббәтең хакына
Чын күңелдән чиксез юмартланып
Сибеп калдыргансың халкыңа.
“Чабаталы даһи, усал бунтарь”
Җырлап үткән шушы юлларда
Ул чәчәкләр яна, көчле яна –
Йөрәк ялкыннарым аларда.
Мин соңгардым.
Күрми калдым сине.
Син ашыгып китеп баргансың.
Сине эзләп киләчәккә барам,
Беләм, очрамыйча калмассың.
1970

**Бик еш кайтып киләм үткәннәргә**

Кырык биштә
Шинельләрне салып,
Шәһәрләрне күтәргән чакта,
Яшьлек хыялыбыз канатланып
Оча иде киләчәк якка.
Ничек булыр тормыш дия идек,
Ун, егерме, утыз елдан соң.
Тынлык безне чиксез сөендерде
Сугышып үткән озын юлдан соң.
Киләчәкне мәңге гөлчәчәкле
Бакча белән тиңләп җырладык.
Ерак иде андый бакчалардан
Җәрәхәтле, авыр чынбарлык.
Без җырладык!
Чөнки нык ышандык
Җиңәсенә безнең максатның.

Кабат мәңге купмасын дип салдык
Фундаментын Волгоградның.
Кизәнделәр безгә атом белән,
Киләчәккә булган өметне,
Сүндерергә теләп,
Ләкин
Безнең иңнәр
Бер-берсенә ныграк беректе.
Һәм без әйттек:
Җиргә сугыш уты
капмас, юк!
Хиросима көйде,
Ләкин бүтән
Акылсызлар урын тапмас, юк!
Юк! - дидек без.
Гүзәл җиребезне
Атом бомбасына бирмибез.
Без сугыштан кайткан,
Без сугышны
Тыныч хезмәт белән җирлибез!
Кореяда сугыш чукмарлары
Кешеләрне тереләй күмгәндә,
Йөрәк каныбыз белән набат суктык:
- Тиеш түгел сугыш үрләргә.
Вьетнам күгәрчене канга батып
Егылганда –
көчле чаң суктык.
Сугышлардан туйган бит кешелек,
Елгалар күк инде кан акты.
Вьетнам җире – Вьетнам халкына дип,
Эшләдек без гел уяу булып,
Илбасарлар артын ялтыратканда
Типте йөрәк шатлыкка тулып.
Бик еш кайтып киләм үткәннәргә,
Хәзер үзебез торган үрләргә

Кырык биштән карыйм.
Нинди көчкә
Иреште бит илем, күр әнә.
Без ашкынган киләчәкләр килә:
Уны килде - чирәм җирләрнең
Ашлыклары белән,
Ныклыгына
Гимн укып батыр ирләрнең
Егермесе килде – Братскилардан
Илгә яңа гүзәллек иңде.
Егерме ел буе нур җиһанда –
Галибәнә тынычлык җиңде.
Утыз килде,
КамАЗ, БАМнар булып,
Космостагы яңа «Союз»лар булып,
Егерменче гасырым, соңгы чиреген
Башлап китте бәхеткә тулып.
Кизәнәләр безгә сугыш белән,
Безнең ныклык, безнең хаклыкны
сындырырга теләп,
Мөмкин түгел
Буйсындыру безнең халыкны!
Хаклык бездә,
Гүзәл җиребезне
Атом бомбасына бирмибез.
Без сугышта җиңгән.
Без сугышны
Тыныч хезмәт белән җирлибез.
Без ашкынган киләчәкләр килер,
Без күрергә теләгән кебек.
Яңа киләчәкләр алды балкыр,
Хак эшебез нурына төренеп.

Хыялларым китә киләчәккә,
Ике меңгә барып тоташа.

Киләчәкнең тулы гармонияле
Гүзәл кешесе белән очраша.
1970

**Игүчеләргә**

Җир-туфракка гашыйк кешеләр –
игүчеләр, үстерүчеләр,
гали затлар, нурлы җиһанга
тормыш китерүчеләр,
художникка җаны теләгән
буяу-төсләр үрчетүчеләр,
үләннәрнең шифа үзлеген
даруларга күчерүчеләр!

Көн дә-көн дә сезнең хезмәтнең
без күрәбез сыен, хөрмәтен.
Түгеп кайнар маңгай тирләрен,
яңартасыз туган җир ямен.

Таң йокысы – тәмле, бик рәхәт,
төшләре дә - татлы әкият,
ә сез, ташлап, кырга китәсез,
тудырырга илгә бәрәкәт.
Сез күрәсез кырда барын да:
карның тургай дулкыннарында
рәхәтләнеп ереп ятуын,
галибәнә таңнар атуын,
кичке шәфәкъ ялкынлануын,
башакларның алтынлануын...

Корылыктан җирләр чатнаса,
яргалана сезнең бәгырьләр,
яңгыр үбеп, җирләр елмайса,
юылып төшә сезнең кайгылар.

Кырлар тулып гөрли моторлар,
алар сезнең йөрәк тибешен
кабатлыйдыр кебек тоела.
Ләкин алар сезнең кул көчен
күпме генә җиңеләйтмәсен,
күңел җылысыннан, хистән тыш,
машиналар үле, җансызлар,
туфрак үксез-ятим чиктән тыш.
Сезнең йөрәкләрнең утыннан
җансыз машиналар җанлана,
сезнең йөрәкләрнең кодрәте
кара җирдән
                    ап-ак шикәр,
                    ап-ак күмәч,
                    ап-ак сөт ала.

Туфракта бар гаҗәп тылсым, -
ак бодайлар булып ул тулсын,
әверелсен хәтсез төсләргә,
әверелсен тәмле исләргә.
Күпме вәхшәтләрне җир белгән,
бомбалардан калып терелгән,
бомба түгел – җирне һәр заман
назлый-назлый сөрсен тик сабан.
Туфрак мохтаҗ назга-кадергә,
мөмкинлеге кеше кулында;
мөмкинлеге аның ачыла
игелекле хезмәт алдында.

Игүчеләр, сезгә мең рәхмәт,
сезнең аша килә бәрәкәт,
галим зиһене, атлет мускулы –
бары да сезнең иҗат аркылы

1971

**Идиллия**

Басып торам мин рәхәткә оеп
Ап-ак карлар уртасында.
Кырлар кебек мин дә рәхәт эрим
Нурлар тулы күк астында.

Баш очымда тоташ саф зәңгәрлек.
Көлә-көлә кояш тора.
Кая баксам бәллүр нур диңгезе
Күзне рәхәт камаштыра.

Шундый тынлык, хәтта ишетелә
Зәңгәр күләгәләр моңы...
Кинәт бөтен тәнем буйлап акты
Җанга тансык тургай чыңы.

Кыш белән яз арасында калган
Кырлар уртасында
Мин коенам тургай дулкынында
Зәңгәр күк астында.
1971

**Улым белән сөйләшү**

Син уяндың,
Яңа көнне котлап,
Күзләреңнән шатлык агыла.
Күзләреңдә минем киләчәгем,
Минем өметләрем чагыла.

Талпын шулай, очып китәр төсле.
Җилпе шулай нәни кулларың.
Дәү үс, улым, нәни кошым,
Елларга тиң ,ның бул, тулпарым.

Гөлләр йоклый җирнең куенында,
Бәкеләрдән тора пар чыгып.
Әле тышта кышның тантанасы.
Әле тышта салкын кар җыры.

Язлар җитәр, гөлләр уянырлар,
Көлә-көлә чәчәк җыярсың.
Яңа тешләр чыгар, яңа сүзләр,
- Бабам кайда? – диеп сорарсың.

Без әнием белән әтиләрнең
Кайдалыгын ничек әйтербез?
Алар йоклый дипме еракларда?
Сер йомгагын ничек сүтәрбез?

Кырык өчтә карлар башка төстә.
Күз яшедәй алар очтылар...
Һәм “Хәбәрсез югалдылар” дигән
Язу ташлап китте почталар.

Ә без көттек, кайтырлар дип көттек
Көнбатышка төбәп күзләрне...
Кайтмадылар.
Ләкин тере кебек
Әйдәделәр безне үзләре.

Без – аларның нурлы киләчәге.
Ә син, улым, безнең киләчәк.
Тышта карлар,
Тыныч карлар ява,
Һәр бөртеге – әкият,
Ак чәчәк.

1971

**Туй теләкләре**

Бүген кичләр нинди, нурлы, ямьле,

Нинди күркәм сезнең туегыз.
Туегызның ямен мәңге саклап.
Гел бәхеткә илтсен юлыгыз.

Утырасыз ак бәхеттән балкып.
Йөзегездә уйный ал шатлык.
Тәрбияләп, карап үстерелгән
Пар чәчәккә сезне ошаттык.

Бәхетегез гөле шау чәчәктә,
Кадерен генә яхшы белегез.
Икәү бергә файда китерсенгә
Үстерде бит сезне илебез.

Сез кабызган учак гомер буе
Якты янсын, дәртле дөрләсен.
Очкыннары, безне сөендереп,
Йолдызларга кадәр үрләсен.

Сез саклагыз иң-иң изге итеп
Йөрәкләрнең керсез сафлыгын;
Нур чәчегез җиргә пар йолдыздай.
Өләшегегез күңел шатлыгын.

Бүген кичләр нинди нурлы, ямьле,
Нинди күркәм сезнең туегыз.
Туегызның ямен мәңге саклап,
Гел бәхеткә илтсен юлыгыз.
1972

**Хатын-кызларга**

Нигә әкияттәге кебек матур
Булып истә кала балачак?
Әни дигән газиз җан иясе
Булганга дип бирәм мин җавап.

Нигә егет чакның юләрлеген
Сагынабыз әле бу тикле?
Чөнки йолдызлардай нурлы янган
Сөйгән ярлар безне тилертте.

Без, ир-атлар, сездән башка ятим,
Хатын-кызлар, бары сез генә
Ычкынырга торган ир-атларны
Тоталасыз изге тезгендә.

Без, ир-атлар , хөрлек яратабыз,
Тырышабыз күндәм булмаска.
Без ирлекне һаман күрсәтәбез,
Ә үзебез мохтаҗ юлдашка.

Ауганда да, юлдан язганда да
Ышанычлы юлдаш – хатын-кыз.
Мөмкин түгел яшәү хатын-кызсыз –
Гомер итеп була алтынсыз.

Хатын-кызга авыр кагылсалар,
Телгәләнеп китә йөрәгем.
Әйтерсең лә, сыкрап авып төшә
Таянып ял иткән тирәгем.

Акылымны җуеп тиле иткән,
Тилелектән иткән акыллы –
Ул сез, и ягымлы фәрештәләр,
Ул сез шушы тормыш ялкыны.

Чәчәк димим сезне, сез үзегез
Бу тормышны чәчәк ясыйсыз.
Унсигездә, утыз, siксәндә дә
Ир-атларның ямьле язы сез.

Без, ир-атлар, мәңге ирләр булыйк,
Сез хатын-кыз булып калыгыз.
Алышынсак, дөнья ямьсезләнер,
Дөнья күрке булсын хатын-кыз.
1972

**Авылым җәе**

*И авыл син, мең шәһәрдән*
*Мең кабат ямьле вә хуш*
*С.Рәмиев*

Яратам мин сине хезмәт белән
Дан казанган матур Мулилем.
Кырларыңда сине сөюемә
Җавап булып үсә мул иген.

Үрләр сузылып киткән офыкта,
Кояш чыга шулар артыннан.
Яшел Үзән – туган бишегем
Алсу нурлар белән манчылган.

Зөя ага – тулы, мул сулы,
Күк гөмбәзе чагыла йөзендә.
Ярларыннан уктай атылып,
Керәшәләр уйный өстендә.

Буйларында сихри болыннар,
Яшел таллар – нечкә билләре.
Камышларга сыенып тын гына
Күккә карап яткан күлләре.

Менә Комсу, Кухмар, Чиркәлше,
Томбый, Бучук, Бәчүр, Илмышык!
Төнбоеклар өчен бик рәхәт,
Сулар тонык, йошак һәм ышык.

Әрәмәләр аша борылып,
Тобаларны үтеп килә дә
Мыштым гына таллар эчендә
Әрә суы кушыла Зөягә.

Аланнардан күчәм аланга,
Үткәннәрне искә төшереп.
Бередә мин ничә җәемне
Кибәннәргә куйдым яшереп.

Туган якның гаҗәп моңнары
Гомер буйларына җитәрлек.
Минм балачакны сагынып
Моңсу кычкырып йөри тәкәрлек.

Ашлык диңгезендә дулкыннар
Офыкларга кадәр йөгерә.
Шул дулкыннар минем күңелгә
Чиксез яшәү дәртен күчерә.

Уртасында яшел үзәннең
Җәйрәп ята гүзәл Мулилем.
Кырларыңда үсә мул иген -
Мәхәббәтем яме шул минем;
1973

**Ир уртасы – җәй уртасы**

Җәй уртасы.
Инде күптән бугай
Елмаялар гөлләр болында.
Яшеллеккә иңә бер моңсулык,
Сагыш тоела кошлар җырында.
Җәй уртасы.
Юк, юк, җәйләр әле
Кичә генә башланды бугай.
Гөлләр әле озак елмаерлар.
Озак сайрар әле бу тургай.

2

Кайчак үземә тәмам карт тоелам.
Яшьлек узган, кими көчләр дә.
Калган, мәйтәм, яшьлек матурлыгын
Тик хыялда күреп яшәргә.

Кайчак үземә гаҗәп яшь тоелам.
Гүя яңа яши башлаган.
Бар кызыклар, хисләр, юллар алда,
Ал хыяллар миннән качмаган.
1973

**Мәдәният сараен ачканда**

Әгәр, дуслар, сезнең каршыда
Шушы йортка мактау яудырсам,
Бик күбегез миннән көләрсез,
Тапкан гаҗәп нәрсә, диярсез.

Ләкин бүген минем йөрәкне
Бер горурлык хисе тутыра.
Күңелләрдә менә шушы йорт
Гаҗәп сарай булып яктыра.

Каян килә миңа мондый хис?
Уйлап карыйм үткән чакларны –
Кычытканлы ашны азык итеп,
Кара икмәк көткән чакларны.

Күз алдымда: салам түбәләр.
Йортлар, иеп, җиргә чүгәләр.
Тол аналар ата чалбарын
Малайларга ямап бирәләр.

Тик күңелне барыбер шулчакта
Иртәгесе шатлык җылытты.
Гади хезмәт, дымлы җир исе
Күзгә килгән яшьне корытты.

Кайгы килми, кайгы кичерми
Аңлап буламыни бәхетне?!
Аңлап буламыни мәгънәсен
Бүген күрә торган рәхәтнең?!

Шушы йортка мактау яудырсам,
Бүген, дуслар, мине аңларсыз.
Шушы йортка
Турист күзе белән түгел,
Үз хуҗасы булып карагыз.

Безнең өчен авыл уртасында
Күтәрелгән шушы ак сарай
Киләчәктә күпне вәгъдә иткән
Бик-бик якын тансык баладай.

Һәр кич саен купшы киенеп,
Егет-кызлар монда юлласын.
Ләкин купшы күлмәк эчендә
Эчке бушлык кына булмасын.

Балкысын бу сарай нурланып
Көнләштереп Римне, Парижны.
Егет кызга калсын елмаеп,
Киләчәккә узып барышлый.
1974

**Диңгез**

Менә нинди икәнсең син, диңгез!
Гаҗәп җанлы, тере тамаша!
Бер торасың олы тынлык саклап,
Зәңгәрлектән күзләр камаша.

Бер көләсең шашып һәм шаркылдап,
Сихерлисең гүя дөньяны.
Бер җырлыйсың әллә нинди көйгә,
Ота алыр икән кем аны?

Бер буласың моңсу һәм сагышлы,
Бер ачулы, усал, ярсыган.
Һәм әйдисең мине, кунагыңны,
Зәңгәр дулкыннарың артыннан.
1975

**Нәрсә сөйли диңгез?**

Батуминың диңгез бульвары
Ерак-еракларга сузылган.
“Иран моңнары”на Есенин
Илһам алган менә шушында.

Күңелемдә чыңлый шул моңнар,
Шул аһәңнәр иңли шәһәрне,
Арасыннан көләч кызларның
Килеп чыгар төсле Шаһәне.

Нәрсә сөйли диңгез туктаусыз –
Гасырларның тере шаһите –
Я пышылдап зәңгәр тынлыкта,
Я бар киңлегенә шау итеп.

Шагыйрьләрнең әйтеп бетмәгән
Шигырьләрен әйтә сыман ул.
Ишетәм Пушкин саубуллашуын
Һәм Такташның ямансулавын.

Күпме еллар үткән булса да,
Такташ кайгылары диңгездә.
Хыянәттән сулган шагыйрьнең
Аһ-зарларын сөйли ул безгә.

“Ташлап кит син Кара диңгез буен
Һичбер вакытта да сагынма;
Зур югалту, авыр уйлар белән
Атаң йөрде аның ярында”. *
1975

*Искәрмә: Һ.Такташның нәни сабые Рафаэльгә багышланган шигыре. Шагыйрьнең беренче хатыны Кара диңгез буенда аңа хыянәт итә.

**Кояшлы давыл**

Офыклардан - әллә кайлардан –
Аумаклашып тәгәрәп килеп,
Ак күбеккә баткан дулкыннар:
- Исәнме яр, саумы җир! диеп,

Күтәрергә авыр сыртларын
Уфылдашып сала ярларга,

Шул ярларга бәрелеп чалара,
Якты кояш ватыла аларда.

Офыкларга кадәр сузылган
Ялтыравык хәйран тамаша.
Карталарда җансыз төсле дә,
Монда килгәч тере ләбаса.

Чуер ташлар белән шашынып
Уйный диңгез: яшелен алып
Күк төслесен ташлый китереп,
Һәм, кыядан җавап көткәндәй,
Куенына керә уалып.

Диңгез күпме торса да ярсып,
Күр, тегендә әнә бер кораб,
Борынын куеп дулкынга каршы,
Юлга чыккан офыкка карап.
1975

## Нәрсә кирәк?

Нәрсә кирәк, Сәйфи, сиңа тагын?
Кочагыңда Кара диңгез.
Тирбәләсең салмак дулкыннарда,
Бәхетләрең синең чиксез.

Нәрсә кирәк, Сәйфи, сиңа тагын?
Сукмагыңда кипарислар
Кипарислар арасыннан
Күз кысалар матур кызлар.

Нәрсә кирәк, Сәйфи, сиңа тагын?
Чәчәкләре ал таҗларын
Сирпеп сиңа матур елмая бит,

Юктыр монда мохтаҗларың.

Нәрсә кирәк, Сәйфи, сиңа тагын?
Карап диңгез дулкыннарына
Иделеңне өзелеп сагынасың,
Диңгезне дә хәтта тарсынасың,
Ашкынасың туган якның
Җанга җылы салкыннарына.
1975

**Әйдә, улым!**

Әйдә, улым, киттек мәктәпкә,
Хәерле юл, изге сәгатьтә!
Бар җиһанга кояш нур җәйгән,
Бүген шатлык тулы зур бәйрәм -
Әйдә, улым, киттек мәктәпкә!

Хәерле юл, изге сәгатьтә!
Әлифбаңны сакла, хөрмәтлә.
Ярат укытучы апаңны
Һәм сөендер данлы Ватанны,
Хәерле юл, изге сәгатьтә.

Күр, җиһанга кояш нур җәйгән,
Ак гөлләрдән торган бу бәйләм.
Мәктәбеңә булыр бүләгең –
Ак гөлләрдәй ап-ак теләгең.
Күр, җиһанга кояш нур җәйгән.

Бүген шатлык тулы зур бәйрәм,
Сентябрьгә ямьле җәйләрдән
Калган әле дөнья матурлык,
Һәр карыш җир – илһам алырлык.

Бүген шатлык тулы зур бәйрәм.

Әйдә, улым, киттек мәктәпкә -
Уку дигән олы хезмәткә!
Гомерең юлың, акылың нурлансын,
Синең белән ил горурлансын –
Әйдә, улым, киттек мәктәпкә!
1978

**Башлык булсаң...**

Башлык булсаң – башлы бул,
Җыерылмас кашлы бул.
Ачуыңны ат итсәң,
Тезгенең акыл булсын.
1978

**Кырык яшь**

Акыл белән йөрәк тигезләште,
Юк, түгелсең инде дәрт колы.
Тәҗрибәләр җимеш бирер чагың,
Зирәк камиллектә акылың.
1978

**Ага сулар, ага еллар**

***"Сиңа килдем әйтермен дип зур сүз"***

***Мостай Кәрим***

Шашкан чагым, бер күрергә
Тилмереп йөргән чагым.
Сөю сүзен әйтәлмичә
Тилереп йөргән чагым.

Килде бер кич – икәү калдык,

Бәхеттән шашкан идем.
Зөя сулары да – иләс,
Ярлардан ташкан иде.

Әйтәлмәдем сөюемне,
Сүзне бүтәнгә бордым:
“Күр Зөяне: тәмам шашкан,
Тилергән,” – дигән булдым.

Ә син көлдең шырык-шырык,
Су өстен яңгыратып,
Йөрәгемә күзәләреңнән
Исерткеч нурлар атып.

Үтте еллар, тормыш кордык,
Мин ир булдым, син – хатын.
Син дә, мин дә - башка белән
Йөрәктә шул ук ялкын.

Тагын туры килде очрак:
Икәү калдык.
Эчемдә
Әйтер сүзләр меңләп-меңләп,
Әйтәлмәдем берсен дә.

Әйтәлмәдем сагышымны,
Сүзне бүтәнгә бордым:
“Зөя тып-тын, ярсулары
Төптәдер,” – дигән булдым.

Син елмайдың тыныч кына,
Нәрсәдер өмет итеп.
Күз яшләрен күрмәсен дип,
Мин тизрәк бардым китеп.

Үтте еллар үкендереп,
Сагындырып, кичереп,
Үтте еллар чигәләргә
Ак кыраулар төшереп.

Килде тагын шундый бер чак:
Икәү калдык. Бу юлы
Барлык үкенечләремне
Әйтмәк булдым берьюлы.

Әйтәлмәдем тик берсен дә,
Сүзне бүтәнгә бордым:
"Күр, Зөядә яфрак йөзә,
Саргайган," - дигән булдым.

Синең караш җитди, уйчан
Яшьләр дә мөлдер-мөлдер.
Юк, үкенмик, сөю белән
Саф булып калсын күңел.
1978

*****

Күктә шат ай
Чалкан яткан,
Шук сабыйдай елмайган.
Шулчак, җанкай.
Бергә атлап,
Йөрдек көмеш юллардан.
Җырлады кар:
Без китәрбез,
Сез калырсыз монда, дип.
Булмадың яр,
Киттең әрсез,

Ай да калды моңаеп.
1980

**Бәхет үзәне**

Татар иленең киң кочагында
Санап бетергесез авыллар.
Шулар арасында әни кебек
Газиз булган туган авыл бар.

Бер ягында тезмә-тезмә таулар,
Шунда менеп түбән карыйм да
Бар күңелем китә иркенәеп,
Мин берьюлы күрәм барын да:

Шундый биек зәңгәр күк гөмбәзе.
Бик-бик ерак күксел офыклар.
Галәмәт киң иркен бу үзәндә
Мәңгелек ямь, бетмәс шатлык бар.

Ялтыр зәңгәрләнеп Зөя сузыла,
Әрә кушыла аңа тын гына.
Гомерләрем кебек тулып-тулып
Ага сулар Идел ягына.

Монда күлләр санап бетергесез –
Исемнәрен беләм барсының.
Ак төнбоек катыш камышларда
Яшеренгән йөрәк ярсуым.

Таулар итәгендә буйдан-буйга
Сузылып киткән зәңгәр урманнар.
Шунда яши минем әкиятләрем.
Шунда минем серле юллар бар.

Без утырткан нәни наратлардан
Шаулап үскән калын бу урман.
Урман үскән чакта гомерләрем
Үтүләре өчен кайгырмам.

Урманнардан ары – карт талларның
Кочагында гүзәл Мулилем.
Гомерлеккә яшәү көче биргән,
Илһам биргән җирем шул минем.
1980

### Синең белән яшим

Гомерем буе синең белән яшим,
Синең язмыш – минем язмышым.
Гаҗәп икән: үткән саен яшем
Тәмлеләнә бара арышың.

Нинди җиңел миңа синең белән,
Мең сорауга җавап бирәсең.
Җиде гасыр җыйган хәзинәңнән
Акыл энҗеләрен сибәсең.

Мин – синеке, борынгыдан килгән,
Береккәнмен изге туфракка.
Тамырларым минем тармакланып
Бик тирәнгә киткән еракка.

Бу җирләрнең изге туфрагында
Борынгылык йоклый – Болгарлык.
Зиратында ташлар бик күптәнге,
Гасырларны кичкән, чорларны.

Шул үрдәге ташка нәселемнең
Шәҗәрәсе уеп язылган.
Утызынчы бабаң Муллагол дип
Бикерактан сөйли гасырлар.

Нәселем минем эзле чал тарихта:
Туган җирнең яклап хөрлеген,
Читтән килеп ятлар ябырылганда
Күрсәткән ул егет-ирлеген.

Ничә тапкыр минем нәселемнән
Өчәү китеп, кайткан тик берәү.
Соңгысында барсы баш салганнар –
Имәннәр дә торган иңерәп.

Өч туганның тере җисеме мин –
Нәселемнең нигез иясе...
Иртүк торып көнчыгышка карыйм.
Гомеремнең гүя иртәсе.

1980

**Үзем булып калам**

Балачагым нинди ерак калган,
Яшьлегем дә томан артында.
Менә мин дә карт бер бабай хәзер,
Күпме калган, белмим, алдымда.

Еллар мине ләкин үзгәртмәде:
Балачакта шыткан хисләрем,
Гел беренчел сафлыгында калып,
Балкый алар бөтен төсләрен.

Мин дөньяны һаман яшь чагымда
Сөйгән кебек өзелеп яратам.

Башны кичен кара кайгы басса,
Шатлык белән тулып таң ата.

Хәсрәтләрне йөрәк үзе теләп,
Үзе барып ала каршыга.
Яраклаша белмим, шуңа күрә
Хаксызлыкка үчегеп ярсынам.

Яши белеп өйрән яшәргә дип
Әйтүчеләр булды юлымда,
Ул кызны дип сөймә, бу кызны сөй,
Әтисе бит нинди урында.

Ә мин исә шундый мөмкин булган
Дәрәҗәдән качып, рәхәттән
Үз юләрем белән китеп бардым
(Мин аларча тиле, әлбәттә).

Бер үзендә күрдем йөз кызны мин,
Ул гомергә булды фәрештә.
Әйтүчеләр булды: усал булма,
Сөю ярдәм итми бер эштә.

Күкрәгемдә бик еш күк күкрәде,
Күзләремдә яшен яшьнәде.
Әйтүчеләр булды: усал булма,
Үч алырлар коеп тешләреӊ.

Рәнҗетелгән кешеләргә барып
Булышканым өчен шатландым,
Әйтүчеләр булды: вакыт – акча,
Син алардан үзеңә ни алдың?

Ялгышларым-хаталарым булды,
Парә-парә телде вөжданым.

Әйтүчеләр булды: ялгышыңны
Кем дә белмәс, сакла үз җаның.

Ташкыннарда кеше баткан чакта
Мин ташландым башлап иң алдан.
Әйтүчеләр булды: гомер тик бер,
Үз башыңны сакла, алданма.

Башсыз башлык миңа җикеренгәндә,
Тордым тыныч, салкын һәм сабыр.
Әйтүчеләр булды: юаш булма,
Бугазына аның ябырыл.

Кешеләрдән изгелегем өчен
Алып кайткач бүләк – чын чәчәк,
Әйтүчеләр булды яла ягып:
Ришвәт алып кайтты бер кочак.

Адашкан бер яшь гүзәлне төнен
Мин җитәкләп чыктым яктыга.
Гайбәтчеләр тәмам азган итем
Чәйнәделәр минем хатынга.

Гел беренчел сафлыгында кала
Яшь чагымда туган хисләрем.
Бер дә үзгәрмәгән - яшьлегемдә
Иснәгәндәй шомырт исләре.

Үзем булып калам ахыргача,
Тик бер генә төсле булалам.
Малайларча үзсүзлелек белән
Агымнарга каршы юл алам.

1981

## Ай, ул май заводы!

Үзәнлеккә салынгандыр безнең авыл,
Бер “инеш” бар, якын безнең авылга ул.

Авылыбызның ямен-суын бозып ага,
Бер чара да күрүче юк бездә аңа.

Яз-җәй чебен мыжлап тора өсләрендә,
Былбыл качкан, сайраучы юк кичләрен дә.

Елга-күлләр агуланган – юктыр балык,
Терлекләрне эчерәләр ерак барып...

Истән чыкмый бу җирләрнең ямьле чагы,
Кем кайтарыр шул чакларны безгә тагы!?
1981

## 1981нче ел икмәге

Юкка гына тилмерешеп
Яңгыр көтте бодайлар.
Баш очында сагыш коеп
Сызып очты тургайлар.

Әлсерәүдән томшыкларын
Ачып сулады үрдәк.
Идел буенда корылык –
Мондый хәл була сирәк.

Мең сигез йөз туксан бердә
Мондый хәл булып үткән:
Ачлык сабый җаннарны да
Кабергә алып киткән.

Бу сиксән бер авыр булып
Басты безнең иңнәргә,
Күтәрелде батыр халкым
Корылыкны җиңәргә.

Рәхмәт сиңа, Татарстан,
Бәлаләргә тарганда
Мәгъруур көчең алып чыга
Безне якты таңнарга.

Идел суы йөгереп керде
Миллион торбаларга
Һәм ашыкты корылыктан
Чатнап яткан кырларга.

Фонтаннардан яңгыр яуды,
Хәл алды газиз туфрак.
Сөендереп күңелләрне,
Күккә үрләде сабак.

Әкият булып балкып торды
Салават күперләре,
Күктә кояш ялап торды,
Җирдә яшәү гөрләде.

И сиксән бер! Һәр башагың
Алтын-көмештән нурлы.
Һәр бөртегең күпме куәт,
Күпме көч куеп тулды.

Ипекәең нинди тәмле,
Гадәттән тыш кадерле.
Игенче даны җәелсен
Йолдызларга кадәрле.
1981

**Гомерем буе мин әтине эзлим**

Гомерем буе мин әтине эзлим
Барлык почмагыннан дөньяның.
Миллион-миллион кабер ташларыннан
Исемнәрен тапмыйм мин аның.

Мин әтине эзлим гомерем буе,
Табарыма шундый ышанып.
Син фанатик булма, диләр җилләр,
Өметең өз, диләр, кызганып.

Малайларча үзсүзлелек белән,
Юатуга-нигә карамый,
Мин әтине эзлим гомерем буе
Төзәтергә йөрәк ярамны.

Эзлим аны төпсез чоңгыллардан,
Арасыннан биек тауларның,
Урманнардан, куе камышлардан,
Куеныннан текә ярларның.

Мин әтине эзлим гомерем буе
Китаплардан, документлардан.
Эфирлардан, кинофильмнардан,
Хатирәләр тулы хатлардан.

Мин әтине эзлим гомерем буе
Ул хәбәрсез яуда югалган.
Көтте әбием, көтте һаман карап,
Көнбатышка илткән юлларга.

Гүрең якты булсын, өч балаңны
Яуда җуйган газиз әбием.

Зур кайгыңны йөрәгеңә бикләп,
Озак яшә, чыдам әнием.

Әтиемне күргән-белгән кеше!
Эндәш миңа, кайда торсаң да.
Мин тергезим әтиемнең сынын
Хыял дигән якты дөньямда.

2

Мин кайтканчы күпме үсәр диеп
Бастырган да тәрәз төбенә,
Мине, үлчәп, билге салып куйган
Ап-ак яңакларның беренә.

Кысып кочаклаган, суырып үпкән...
Шулай киткән әти сугышка.
Илен өзелеп сөйгән йөрәгендә
Ачы нәфрәт саклап фашистка.

Нык ышанып киткән кайтырына
Җиңү яулап сугыш кырыннан.
Соңгы хаты фашист танкларын
Гөрселдәткән көнне язылган.

3

Кайларда соң, кайсы туфракларда,
Йөрәгеңнең соңгы тибешен
Биреп, әти, ятып калдың икән
Минем өчен, туган ил өчен?

Газинурдай әллә гәүдәң белән
Капладыңмы дошман утын син?
Асларына кереп шартлаттыңмы

Үзең белән бергә танкысын?

Әллә язмыш сине атлаттымы
Батыр җәлилчеләр эзеннән?
Рәсемеңә карыйм... Какшамас рух
Бөркеп тора бөтен йөзеңнән.

4

Үз әтисен эзли хатыным да –
Икебез дә бер үк язмыштан.
Бабаларын эзли өч улыбыз,
Нәгъләт укый-укый сугышка.

Европаның туфрак катламнары,
Сугыш булып киткән урыннар
Күпме язмышларны яшереп саклый.
Эзтабарлар – яңа буыннар

Җир куеныннан серләр казып ала:
Солдатларның соңгы минутта
Гильза эзләренә язып тыккан
Исемнәре кайта халыкка.

Шулай бер көн кайтыр әтиебез,
Батырлык ул мәңге югалмый.
Әтиләрнең рухы мәңге яши,
Яктырта ул безнең юлларны.

5

Тәрәзәмдә кояш, алтын нурлар...
Яңагында билге һаман бар.
Хыялымнан әти калкып чыга –
Бергә күрешә менә заманнар.

Әти – солдат һаман егермедә,
Сагынган ул мине ничаклы,
Тыелгысыз күрешү шатлыгыннан
Кысып-кысып мине кочаклый.

- Без үлмибез, улым, без яшибез,
Һәр гасырдан яшәү даулыйбыз.
Без – “КамАЗ”лапр булып юл йөрибез,
Без башаклар булып шаулыйбыз.

Без берләшеп бергә бер гәүдәгә
Башкалабыз мәгърур Мәскүгә
Бер билгесез солдат булып кайттык,
Мәңге сезнең белән яшәргә.

Безнең батырлыкны дөнья белә.
Йолдызлардан килгән нурлардай
Буыннардан буыннарга таба
Килеп торыр бездән хәбәрләр.

6

Әти, әти! Сине хыялымда
Шундый җанлы итеп тергездем:
Син – комсомол секретаре менә,
Ныгытасың колхоз нигезен.

Ашлык амбарында мөдир булып.
Һәр бөртекнең белеп кыйммәтен.
Герләр түгел, намусың белән үлчәп,
Саклыйсың син халык икмәген.

Син гомергә минем белән бергә
Яшисең ич, әти, янәшә.

Киңәшләшәм, бәхәсләшәм, әти,
Синең белән бергә сөйләшәм.

Без тормышның олы сукмагыннан
Зур максатлар куеп атлыйбыз.
Безне беркем юлдан саташтырмас
Чыкмас безнең яман атыбыз.

Һәр таң саен, әти, минем белән
Каршылыйсың хезмәт иртәсен.
Син мәктәпкә барып минем белән
Балаларга дәрес бирәсең.

Безнең эшебез, әти, бик җаваплы.
Күпне сорый бездән киләчәк.
Безнең йөрәк килер буыннарның
Күкрәгендә әле тибәчәк.
1981

**Гомер аланыңда август ае**

Язың үткән, язың шаулап үткән,
Күке күптән киткән көньякка.
Гомер аланыңда - август ае,
Ә кышларың әле еракта.

Гомер алаңында – август ае,
Сабыр җылы бөрки кояшың.
Бүген беркайчан да булмаганча
Яшәү рәхәтлеген тоясың.

Август аең.Актан киенгәнсең
Һәм атлыйсың яшел юллардан.
Үзең шундый-шундый сөенгәнсең,

Чал чәчеңә чаклы елмайган.

И сабырлык, хаклык алиһәсе!
Гомеремнең якты җыры син.
Балачакны шау чәчәкле итте
Изге күңелеңнең җылысы.

Мин күпьеллык бер шаһитең синең,
Күрдем ничек тырышып йөрүең,
Һәр дәрескә керсез иман белән,
Авыр багаж белән керүең.

Мин яраттым синең олы юлда
Олы булып горур калуың,
Олы баштан кече кешеләргә
Кешелекле караш салуың.

Рәхмәт сиңа, рәхмәт укытучым,
Канат куеп мине очырдың.
Тормыш дигән гаҗәп орбитага,
Тиң кешесе итеп чорымның.

Кемнәр үлчәр синең хәзинәңдә
Тулып яткан акыл байлыгын?!
Диям бүген шуны саклар өчен
Күбрәк булсын иде саулыгың.

Яхшылыгым җирдә булган саен
Монда димен синең өлешең.
Аңлыйм, аңлыйм нидән торганлыгын
Чәчләреңә иңгән көмешнең.

И сабырлык, хаклык алиһәсе!
Гомеремнең якты җыры син.
Картлыгыңны шау чәчәкле итсен

Безнең – күңелләрнең җылысы.
1981

**Яшьлегем урамы**

Яшьлегмә тагын кире кайттым,
Һаман шулай шаулый бу урам.
Зәңгәр нурга чумган йорт каршында
Сихерләнгән сыман мин торам.

Монда кичләр күзләреңдәй зәңгәр.
Өрәңгеләр күксел җирдә
Йөгереп чыгарсың да
Җитәкләшеп
Йөрербез күп тоела без бергә.

Монда төннәр чәчләреңдәй җылы.
Икәү бергә йөргән чатларда
Күк күләгә булып юкәләрдә
Безнең хатирәләр саклана.

Монда таңнар йөзләреңдәй алсу,
Таң җилләре синдәй ягымлы.
Синең кебек балкып кояш чыга,
Дәваларга теләп җанымны.
1981

**Зеленодольск**

Күпме шәһәрләрне күрмәдем мин,
Күпме хәйран калып йөрмәдем,
Тик алардан
Шашкын сагыну белән
Сиңа алып кайтты йөрәгем.

Поездлардан сиңа төшү белән,
И, бердән-бер газиз җиркәем,
Өзелеп сагындым дип кочып ала
Иделемнең йомшак җилкәе.

Җилфер-җилфер килеп без менәбез
Саф һавалы яшел үрләргә.
Карт юкәләр, бала чактагыдай,
Тотыналар әкият сөйләргә.

Әнә аста, Идел кырыенда,
Кабачище әле хәзер дә
Зәңгәр яшьлегебез җыры булып
Шаулап тора безнең хәтердә.

Без яшәгән барак урынында
Инде тугыз катлы йорт тора.
Үсә шәһәр,
Еллар үткән саен
Матурлыгын күбрәк арттыра.

Көче ташып торган яшь шәһәрем
Горурланып карый Иделгә.
Алдан күреп якты киләчәкне
Зур галимнәр баккан бу җиргә.

Әнә затон.
Гигант корылмалар.
Өермәле, утлы елларда
Мәскәүләрдән килгән декрет белән
Салынгандыр нигез аларга.

Идел аша узган гигант күпер
Күпне күргән, күпне кичергән.
Аның аша узган эшелоннар

Фашистларга үлем китергән.

Таныш баскычлардан саф-саф булып
Кешеләр әнә эшкә ашыга.
Ашыга алар зәңгәрләнеп балкып,
Шаулап торган Идел каршына.

И, шәһәрем,
Иркен мәйданнарың,
Урамнарың нинди кояшлы!
Рәт-рәт булып баскан төз чыршылар
Иркәлиләр минем карашны.

Урманыңнан килә сагыз исе,
Моңнар тулы яшел шау килә.
Коляскада нәни гражданнар...
Күзләреннән бәхет бөркелә.

Күпме шәһәрләрне күрмәдем мин,
Күпме хәйран калып йөрмәдем.
Тик алардан
Шашкын сагыну белән
Сиңа алып кайтты йөрәгем.
1982

**Тәҗрибә уртаклашу**

Быел безнең “Якты таң”да
Балдан уңыш мулдан булды.
Һәм, тәҗрибә алырга дип,
Безгә күпме халык тулды.

Төрле яктан килде халык,
Мактадылар хәйран калып,
Башта балның тәмен татып,
Аннан савытларга алып.

Килде журнал корректоры,
Килде базар директоры,
Май заводы хисапчысы,
Хуҗаларның тән сакчысы.

Һәм килделәр ял йортыннан,
Йон әзерләү пунктыннан,
Килде депо вәкилләре,
Балык тоту артельләре.

Калмады балет авторы –
Бездә илһамын тапкыры,
Килде шагыйрь ялкынланып,
Шигырь әйтте дулкынланып...

Тик, егетләр, мин кәефсез
Шундый данлы шартларда да:
Тәҗрибәбез биреп бетте,
Калмады ул... кортларга да.
1982

**Беренче мәхәббәт**

Кичә генә әле синең
Җилбәзәк чагың иде.
Һәр очраган матур егет
Хыялый ярың иде.

Театрга баргач сине
Яшь артист гашыйк итте.

Күзе ялгыш сиңа төшсә,
Йөрәгең дөрләп китте.

Урамнарда очрап куйса,
Чем кара мыеклылар,
Күзкәйләрең нурлар чәчеп,
Шуларга юлыктылар.

Техникумның залларында
Биюләр вакытында
Чак-чак янып бетми калдың
Мәхәббәт ялкынында.

Биегән һәр өч егетнең
Берсенә гашыйк булдың.
Өйгә кайтыр вакыт җиткәч,
Әллә ник ялгыз калдың.

Лекцияләр тыңлаганда,
Тәрәзгә карый идең.
Сөяр өчен чираттагы
Егетне сайлый идең.

Белмәдең тик янәшәңдә
Утырган Рахианкулның
Урындыгы синең янда
Булганга шатлануын.

Сиңа туры карый алмый
Оялып йөргәнлеген,
Йөрәгенә исемеңнең
Җыр булып кергәнлеген.

Шул Рахманкул белән бер кич
Эңгер-меңгер чагында

Син киногa барган идең
Болай дусларча гына.

Әллә нәрсә булды бу кич
Шул кино юлларында.
Сихерләндең шул егетнең
Күзләре нурларында.

Шул Рахманкул сүзсез генә
Бүләк итте сиреньнәр.
Бик мөлаем тирбәнешеп
Куйды синең иреннәр.

Син карадың йолдызларга
Беренче күргән кебек.
Шул йолдызлы күкнең серен
Син генә белгән кебек.

Җилбәзәклек очты китте,
Ул кире кайтмас инде,
Яндырырга, көйдерергә
Сиңа мәхәббәт килде.
1982

**Рәхмәт сиңа**

Безнең дә бит язлар иләс иткән,
Мәҗнүн иткән чаклар бар иде.
Күңелләрнең ярсулары белән
Зөя ташулары пар иде.

Шул чак мине берәү табындырды,
Утларында дөрләп яндырды.
Я күкләргә кадәр ашырды ул,
Я рәхимсез телде җанымны.

Якты хисләремне көйгә салып,
Төннәр буе чишмә җырлады.
Моңсуланып зәңгәр сагышымнан
Тәкәрлекләр таңда елады.

Шаян күзләреннән нурлар сирпеп,
Ул кыз миңа көлеп бакса да,
Мин аңарга бер дус кына булган,
Гыйшкы булган икән башкада.

Рәхмәт сиңа, ихыялый ярым,
Парым булалмаган фәрештәм.
Яндырганың өчен мине шулай
Сөю дигән олы бер хистә.

Син өйрәттең мине могҗизага –
Чәчәкләрнең телен аңларга,
Мәхәббәткә чиксез байлык итеп,
Керсез сафлык белән карарга.
1983

**Егерменче язың**

Егерменче язың – чәчәк чагың!
Күңелең көр, китек төше юк.
Күкрәгеңдә яна вулканга тиң,
Сүрелмәскә туган көчле ут.

Егерменче язың – чәчәк чагың!
Йөрәк җырлый дәртле көйләргә.
Син тугансың таза тормыш шавын
Мәҗнүн гыйшкы белән сөяргә.

Егерменче язың – чәчәк чагың!
Җитмеш кенә түгел һөнәрең.

Комсомолның корыч ташкынына
Кушылып ага керсез көннәрең.

Егерменче язың – чәчәк чагың!
Һаман шулай булып калсаңчы!
Чәчләреңә карлар яуганда да
Яшьлегеңне саклый алсаңчы.
1983

## Май яме

Киләчәккә -
Гомерлеккә, мәңгелеккә
Җиргә тыныч яшәү ямен бүләк итеп,
Май кояшы
Балкый чиксез зәңгәрлектә,
Кешеләргә алтын керфекләрен сирпеп.
Тыелгысыз
Яшәү дәрте кайный җирдә,
Гөлләр гөрләп якты күккә үреләләр.
Тургай җырын
Тыңлый-тыңлый, йомшак җилдә
Яшел уҗым дулкыннары йөгерәләр.
Яфрак туе!
Яшеллек һәм яшьлек туе!
Тереклеккә көч бирүче тылсымлы ай.
Кыз-егетләр килеп йөри көннәр буе,
Туксан яшлекләр дә яшәрәләр бугай.
Бар күңелләр
Якты өмет белән тула,
Рухландыра алдагысы бөек эшләр.
Заманаы ышанычлы әйдәп бара
Сугышларны мәңге булдырмаслык көчләр.
1983

**Катгый кеше**

Чаба халык җан фәрманга –
Аргы башта чыккан пожар.
Бирге башта тыныч кына
Утын кисеп ята Иншар.

Утын кисеп ята Иншар –
Пожарниклар начальнигы.
Кычкырдылар: син пожарны
Күрмисеңме әллә тагы?

Шул белмәүче кешеләргә
Әйтә Иншар тыныч кына:
- Рәхәтләнеп барыр идем –
Мин бит әле отпускыда.

Яңа дәртләр белән Иншар
Отпускыдан эшкә килә.
Пожарниклар өчен шунда
Катгый карар язып элә:

“Моннан ары һәр пожарник
Үзенә шундый бурыч алсын:
Бер пожарга соңармасын,
Пожарга , ул башланганчы,
Унбиш минут алдан барсын”.
1983

**Күңелемдә язлар тулы**

Кояшларга таба якынлашып,
Кичеп чыккач озын кышларны.
Күңелем белән еракларга китеп,
Мин озатып кайтам кошларны.

Кошлар булып ашыгам адашмыйча,
Кошлар булып канат кагынам.
Илкәемне сагынып очып кайтам
Чит-ят кырлар, таулар артыннан.

Якынлашкан саен илкәемә
Ару-талуларым онытыла.
Газиз офыкларым күренүгә,
Күңел тугайларым яктыра.

И кырларым, иркен киңлекләрем,
Җәйрәп кенә яткан күлләрем.
Гөлҗимеш һәм балан куакларым,
Сезне күреп туймый күзләрем.

Мин каргалар булып авылымның
Талларына кайтып сыенам.
Бар нәрсәдән йомшак кар суында
Мин аккошлар булып коенам.

Тургай булып яшел тугайларда
Моңнар сибеп йөрим югартын.
Сыерчык булып сайрыйм урамнарда,
Әби-бабайларны юатып.

Күңелемдә җылы язлар шаулый,
Идел кебек ташый хисләрем.
Әниләрнең битләреннән сыйпап,
Йомшак җилләр булып исәмен.

Авылымда язлар нинди матур!
Нинди зәңгәр монда һавалар.
Ак күңелемнең ап-ак каеннары
Шаулый-шаулый яфрак яралар.

1983

**Яңа елны каршылау**

Җидегән йолдыз җем-җем яна
Җиде төн уртасында.
Яңа елны каршылыйбыз
Ай-йолдызлар астында.

Урам гүя мәр-мәр елга,
Йортлары – зәңгәр ярлар.
Без узганда табаннарда
Җырлашып кала карлар.

Купшы каен толымнары
Тәлгәш-тәлгәш бәсләнгән.
Бәхет нурлары сибелә
Яп-якты тәрәзләрдән.

Аллы-гөлле утлар балкый
Бүлмәдәге чыршыда.
Табындашлар нинди гүзәл,
Гөлләр кебек барсы да.

Алар – хезмәт батырлары,
Ел буена һәр эштә
Биек үрләр яулап алды
Җиңү өчен ярышта.

Үкенечле түгел шуңа
Иске елны озату.
Сөенеч ул – үткән эшкә
Рәхәтләнеп күз ату.

Җиде төннең нәкъ уртасы

Иң кадерле минутлар.
Ашкындырып йөрәкләрне
Суга изге курантлар.

Хуш киләсең, и, Яңа ел,
Тыныч көннәрең белән.
Иркәләп җирне йоклаткан
Айлы төннәрең белән.

Хуш киләсең, и, Яңа ел,
Ап-ак бәхеткә тулып.
Безнең ап-ак өметләрнең
Чынга ашуы булып.
1984

**Кош – синең кулда**

Безнең авылда шундый бабай бар:
Бөтен сорауның җавабын табар.
Кош тотып кулга, һич көтмәгәндә
Килгән, ди, аңа бер явыз бәндә,
Оятлы итеп аннан көләргә,
Кәкре каенга картны терәргә.
Кош тоткан кулын яшереп артка,
Мәкерле сорау биргән, ди, картка.
“Бу кош үлгәнме, юкмы?” – дигән, ди.
Шундый кара уй уйлап килгән, ди:
Үле дип әйтсә - кошны очырачак,
Тере дип әйтсә - муенын борачак.
Бабай хәйләне тиз аңлап шунда
Әйткән, ди, өч сүз:”Кош – синең кулда”.
1984

**Мөһим карар**

*(мәсәл)*

Тычканнар
Җыелыш ачканнар.
Мәсьәлә шундый мөһим
Һәм олы:
“Явыз мәчедән саклану юлы”.

Берсен берсе арттырып
Һәм шаккаттырып
Сөйләгәч озак,
Килделәр карарга:
- Мәченең муенына
Кыңгырау тагарга!
Кул чабып хупланды карар.
Ярар!
Мәче хәзер килеп карар!
Килгәнлеген бер чакрымнан
Ишетер алар!..

Сорау биреп куйды шунда
Арткы рәттән берсе генә:
- Ә мәченең муенына
Кыңгырауны кем элә?
Мондый “пүчтәк”, вак нәрсәгә
Илтифат бирми бер дә.
Әйттеләр: “Анысын карарбыз
Эш тәртибендә”.
1984

**Яңа язлар шаулый**

Яңа язлар шаулый, яңа язлар,
Яңа казлар уйный сазларда.
Яшьлегемне күрәм Мәҗнүн белән
Ләйлә булган егет-кызларда.

Безнең дә бит язлар иләс иткән,
Мәҗнүн иткән чаклар бар иде.
Күңелләрнең ярсулары белән
Зөя ташулары пар иде.

Шул чак мине бер кыз табындырды,
Утларында дөрләп яндырды.
Я күкләргә кадәр ашырды ул,
Я рәхимсез телде җанымны.

Якты хисләремне көйгә салып,
Төннәр буе чишмә җырлады.
Моңсуланып зәңгәр сагышымнан,
Тәкәрлекләр таңда елады.

Шаян күзләремнән нурлар сирпеп,
Ул кыз миңа көлеп бакса да,
Мин аңарга бер дус кына булган,
Гыйшкы булган икән башкада.

Рәхмәт сиңа, и хыялый ярым,
Парым булалмаган фәрештәм.
Яндырганың өчен мине шулай
Сөю дигән олы бер хистә.

Син өйрәттең мине могҗизага –
Чәчәкләрнең телен аңларга,
Мәхәббәткә чиксез байлык итеп,
Керсез сафлык белән карарга.

Яңа язлар шаулый, яңа назлар.
Яңа казлар уйный сазларда.
Язлар шифа булсын Мәҗнүн белән
Ләйлә булган егет-кызларга.

1984

**Мулилем**

(Җыр, композитор Риф Гатауллин музыкасы)

Агымсулар арасында
Иң матуры – Зөядер,
Бездә ярлар үз парларын
Гомерлеккә сөядер.

Кушымта:
Авылым, Мулилем,
Үстерәсең мул иген.
Мул игеннәр үскән җирем,
Гомерлегем бул минем.

Зөя суы ышанычлы –
Алып чыга Иделгә.
Мәхәббәтнең олы юлы
Илтсен безне гел бергә.

Зөя тавы артларында
Төн якты Казан барга.
Нәрсә җитә дөньяларда
Яратып сөйгән ярга.

Томаннарга төренеп пешә
Шомыртым, баланнарым.
Сиңа булсын, туган җирем,
Дәртләрем, дәрманнарым.

Үзәннәрем, үрләрем лә,
Яратып туялмадым.
Гел алдагы заманнарга
Йөгерә хыялларым.

1985

**Шикаятьче (анонимчы) Гата**

Көн дә койма ярыгыннан
Күршеләрен күзли Гата:
Күрше Галләм әле печән,
Утын я җим алып кайта.

Сыер сава, мичкә яга,
Каз ашата – шат елмая.
Гата җанын корт кимерә,
Күзли-күзли хәлдән тая.

Шартлар чиккә җитә Гата,
Казаннарга төн утырып,
“Галләм – карак!” – дип хат яза,
Нәкъ унике бит тутырып.

Иртәгесен күршесенә
Көлә-көлә Гата керә.
Белмәсен дип язганымны,
Сөйли тәмле сүзләр генә.

Ә эчендә агу кайный,
Зәхмәт яна күзләрендә…
Тагын ни бу: нәкъ бер кочак
Чәчәк Галләм өстәлендә!

Төн утырды тагын Гата:
“Галләм эштә ришвәт ала,
Чәчәк биргән булып аңа
Фәлән эченә акча сала”.

Районга да, Казанга да,

Мәскәүгә дә оча хатлар.
Гата язган икәнлеген
Беркем белмәс – ходай саклар.

Килсә бәхет килә икән –
Тәрәзәдән күрде Гата:
Дөм исерек көпә-көндез
Галләм җирдә аунап ята.

Килде шунда начальнигы,
Машинага салып китте –
Әһә, болар әшнә икән –
Болай булгач, Галләм бетте.

Ишетә Гата: килгәннәр, ди,
Тикшерәләр, ди, Галләмне.
Сөенүдән Галләмгә ул
Бик зурлап бирде сәламне.

Ишетә Гата: печәнне, ди,
Галләм үзе чапкан икән,
Каз җимен дә колхоз биргән,
Утынны да үзе кискән.

Ә чәчәкне җыелышта
Бүләк иткәннәр икән,
Каһәр генә төшкән икән –
Күпме хезмәт бушка киткән.

Исереклек болай булган:
Урам буйлап кайткан чакта
Галләмнең нәкъ баш түбәсен
Чәнчеп-чәнчеп кортлар чаккан.

Хәле бетеп Галләм ауган,

Начальнигы очрап шунда
Больницага алып барган…
Һәм врачлар шаһит шуңа.

Күзли Гата – кара көя,
Яши Галләм һәм елмая.
Кояш аңа нурын коя.
Көнләшүдән Гата көя.

Кешене генә түгел, хәтта
Кояш хәтле кояшны да
Язар иде Гата хатка –
Язар җир юк дөньясында.
1986

**Сөюеңне белгәч**

Ярларыннан ташыр төсле торган
Кичке күлдәй иде күзләрең.
Тынычлыгын бозмый, бик сак кына
Мин алардан серләр эзләдем.
Алар шундый керсез елмайдылар,
Нур сиптеләр гыйшкым язына.
Шушы җырым туйның буласына
Зур ышаныч белән языла.
Һич искерми торган энҗе булып
Исемең минем каләм очыннан
Ак кәгазьгә төшә ишетелмәгән.
Җырланмаган матур җыр сыман.

1986

**Хәерле юл, яңа мәктәп!**

И авылым, чал тарихлы яшь авылым!
Гел нурлана, хозурлана яшәү юлың.
Менә тагын бер хыялың ашты чынга:
Яңа мәктәп басты кояш каршысына.

Сабыйларың – синең нурлы киләчәгең,
Мул җимешләр өмет итәр ал чәчәгең –
Үссен әйдә заманага лаек булып,
Илгә бәхет китерерлек белем алып.

Хәерле юл, мәктәп – киләчәккә карап,
Шатлык төяп сәфәр чыккан кораб!
Бар яктырып яңа гүзәл заманнарга
Һәм бездән дә сәлам тапшыр син аларга.
1986

*****

***...Чынлык белән көчле кешеләр.***
***М. Җәлил***

Кара эчле берәр бәндә
Әгәр сиңа яла якса,
Ул ирешеп теләгенә,
Начар дигән атың чыкса,

Һәм дус булып йөргән кешең
Кырт үзгәртсә сиңа йөзен:
Буялудан коты очып,
Йөрсә синнән ерак качып,

Икейөзле бер танышың
Сиңа кызганып сүз катса,
Ә күзеннән сөенү белән

Теш ыржайтып шайтан бакса,

Гайбәтчеләр чаттан-чатка
Сүз куертса синең хакта, -
Син каушама, горур атла,
Керсез рухың кыю сакла.

Дөреслегең ул яланы
Ярып атар, итәр тар-мар.
Кара эчле үз ялганы
Чоңгылында җәза табар.
1986

**Үкенү**

Үкенмәгән бармы дөньяда?
Үкенү ул – йөрәк дәвасы.
Үткәннәрне кайтарып булмый,
Киләчәккә сабак аласың.

**Бабаң утырткан талларда**

Бабаң утырткан талларда
Йорт корган каргаларга
Нигә атасың?
Бәрәңге бакчаң саклап,
Күләгәдә ятасың.

**Фани дөнья...**

Фани дөнья мине мең алдады,
Янды җанда дөрләп мең көенеч.
Үзем, шөкер, бер кат алдамадым, -
Барсын каплый шушы бер сөенеч.

**1944. Сугыш**

Яу кырыннан кара хәбәр килде,
Ничек итеп моңа чыдыйсы?
Безнекеләр өчесе дә үлгән –
Әти... һәм дә ике абыйсы.

**1945. җиңү бәйрәме**

Бу кайгыдан сукырайган әби
Күрмәс булды Җиңү кояшын,
Әни колхоз җирен көрәкләде,
Агыза-агыза канлы күз яшен.

**1946. Ачлык**

Карлы судан “липушкилар” җыйдым,
Җәен башак уып ашадым,
Рәис тотып бүдә белән ярды,
Көзен бердә укый башладым.

**1947. Тәүге китап**

Тәүге тапкыр китап укып чыктым –
“Әниләре өйдә юкта”ны:
Мирсәй Әмир язган малайларның
Әтиләре яудан кайтканны.

**1948. Көнкүреш**

Тирес өеменнән кирпич суктым
Черки өермәсе астында.
Шул кирпечне чи тал белән бергә
Мичкә яктык кышын салкында.

**1949. Сталинга дан**

Сталинның җитмеш еллыгында
Юлбашчыга даннар җырладык.
Рәхмәт, дидек, рәхәт тормыш өчен,
Киресенчә иде чынбарлык.

**1950. Математика**

Без исәпне налоглардан белдек,
Бармы-юкмы, түлә - рәхим ит.
Өч йөз күкәй һәм сөт өч йөз литр,
Ярты пот йон, кырык кило ит.

**1951. Әле манара бар иде**

“Уфалла”ны сөйрәп кайткан чакта
Афәт алды җанны өшетеп,
Мәчет манарасын җимерделәр,
Әби җиргә ауды һуш китеп.

**1954. Беренче мәхәббәт**

Фәрештәгә әйләнде дә куйды
Бергә укып йөргән гади кыз.
Күтәрелеп карый алмый йөрим
Януларым белән бер ялгыз.

**1955. Ындырга ат белән көлтә ташу**

И кырларым, таңнар аткан саен
Мине сөеп каршы аласыз.

Яшьлегемә тәңгәл килә торган
Чәчәкләр дә, эш тә табасыз.

**1956. Университет**

И Ватаным, Бөек Законыңның
Гаделлеген күреп куанам.
Киң вузыңда үсә канатларым,
Фәннәр кояшыннан нур алам.

**1957. Чирәм җирләрдә**
Төн. Салават күперләре агыла,
Моннан гаҗәп тагын нәрсә бар?
Монда сөрелеп килгән чечен карты
Серне ачты: “Атом сыныйлар”.

**1961. 12нче апрель**

Тулай торак. Гасыр ачышы кебек
Бәреп кереп безнең бүлмәгә,
Ярды Әнвәр: “Космонах очкан!”
Һәм кушамат туды шул мәлдә.

**1961. Самара өлкәсе. Гали авылы**

Менә кайда икән чын татарлар!
Бер авылда эшли өч мәчет.
Мөгаллим дип мине зурладылар,
Монда эшләү җәннәт, чын бәхет.

**1962. Самарада**

Самарада – татар фестивале,
Йөз авылдан килгән татарлар.
Юк, бер генә түгел Татарстан,

Өлкә саен бер ил татар бар.

**1970нче ел. Ленин**

Йөз ел тулган көнгә аның барлык
Китапларын укып бетердем.
Тик медален миңа бирмәделәр –
Шуңа калды шактый хәтерем.

**1971. Директор**

Мин бүгеннән мәктәп директоры,
Торсам иде хаклык сагында.
Мөһеремне басып, кешеләрне
Нахаклардан саклар чагында.

**1972. Корылык**

Майдан алып яңгыр көтә-көтә
Сентябрьнең җитте уртасы.
Салам эзләп колхоз читкә китте,
Кысыр кырлар елап озатты.

**1974. Тәвәккәллек**

Ике катлы чалыш карт мәктәпне
Сүтеп атып кордык бер җәйдә!
Әкиятләр шулай чынга ашты –
Ап-ак бәсләр кунды чигәгә.

**1975. Кавказ**

Чал диңгездән күк тауларга бактым,

Таудан упкыннарга карадым.
Авылымның үзәннәрен сагынып,
Кочмак булдым бөдрә талларын.

**1976. Казанда соңгы татар мәктәбе**

“Милләт чәчәк атып бетте”, - дидең,
Хәзинәңне миңа төядең,
Сүнде елап соңгы милли йолдыз,
Кара күмер булды йөрәгең.

**Уйлап кара**

Дошманыңның дусты белән
Чүкердәшкәнен күрсәң –
Уйлап кара яңа баштан:
Кайсы – дус, кайсы – дошман.

**Китапханә**

Монда тынлык, монда вакыт туктаган,
Монда бар заманнар бергә тупланган.
Картаймыйча шул яшьләрендә һаман
Яши бергә Кол Гали, Тукай, Туфан.

**Гасыр арты гасыр**

Ике мең чиген узып барабыз,
Узып барудан кызык табабыз.
Күпме үзгәреп торса да заман,
Ә җир әйләнә искечә һаман.

**Әрә белән Зөя**

Монда, аулак кыргый әрәмәдә,

Мәңгелекнең шушы төшендә,

Әрә белән Зөя кавыша бергә,

Яшеренеп кеше күзеннән.

1988

**Мин авылның карт бер мөгаллиме**

Мин авылның карт бер мөгаллиме,

Карт мәҗнүне нурлы мәктәпнең.

Кырык еллап эшләп ни күрсәттем,

Кайда эзе минем хезмәтнең?

Торды гомер тоташ сабырлыктан,

Тоташ уйда булды һәр көнем.

Тоташ түздем, бәгырь кыйналса да,

Калдырмадым кеше хәтерен.

Кем дә әйтмәс: “Бер бәхетсез булып,

Иргә түгел, миргә эшләдең.

Шәкертләрең сәлам бирәләрме –

Бигрәк тыйнак, фәкыйрь өстәлең”.

Әйтерсең, мин – авыл читендәге

Япа-ялгыз иске тегермән.

Кимсенмичә һаман тарта бирәм,

Үземә сүз илдән тидермәм.

Үз җиреннән купмас имән кебек,

Түзеп бөтен газап-михнәткә,

Тамырларым туган җиргә берегеп,

Бөтен гомерем үтте мәктәптә.

Кичтем кырык елны бертоташтан,

Офыкларга зарыгып карадым.

Күндәм бурлак кебек җигелеп тарттым

Мәктәп дигән заман корабын.

1988

**Ялгышу**

Мин кайчандыр ерак яшьлегемдә
Илле яшькә җиткән кешене
Картка санап ничек ялгышканмын –
Шуңа менә хәзер төшендем.

Илле яшь ул безнең гомерләрнең
Шаулап аккан чагы икән лә.
Йөзәм әле ярсу яшьлегемдә
Үзем корган шул ук җилкәндә.

Яшьлек сине ташлап китми икән,
Яши икән качып йөрәктә.
Дөнья һаман шулай карый икән
Яшь чагымда күргән сурәттә.

Картлык ул, мөгаен, җитмештәдер,
Җитәрбез дим әле ничек тә.
Насыйп булсын тагын ялгышырга,
Мондый ялгышуга ни җитә?

1988

**Саубуллашу**

Җылы төннәр, гаҗәп таңнарым
Артта калды. Бөдрә талларны
Ак томаннанр күмә кичләрен,
Матурлатып кеше хисләрен.
Миләш яна, оча ак таҗым,
Башын төртә шәмәхә уҗым.
Күтәрелгән төсле офыклар,
Җирдә чуар келәм – яфраклар,
Мыштым гына шиңә чәчәкләр,
Моңсуланып йөри бөҗәкләр,

Киткән якка озак күз атып,

Торналарны калам озатып.

Тукта... Гүя тагын яз башы:

Тузганагым сузган ич башын.

Бу – җәйнең тик бер алдашуы.

Безнең белән саубуллашуы,

Томан пәрдәләре тартылыр,

Күк иләге сибәр вак яңгыр.

1988

**Сандугачны тыңла**

Ялган шөһрәт, даннар белән түгел,

Эшең белән калдыр эзеңне.

Эзләп тапсын кеше мәхәббәте

Тормыш эчләреннән үзеңне.

Хурлык – юньле нәрсәң булмый торып,

Кеше телендә йөрсәң макталып.

Гомерең буе тырышып эшләү булсын

Тормышыңның бөтен максаты.

Син яңгырсыз болыт кебек булма,

Атаклы зат булып кыланма.

Күренергә теләп яхшы атлы,

Биек җиргә таба юлланма.

Дөнья бик киң,

Бик күп гали затлар, -

Менә шушы бик күп-күпләрнең

Кечкенә бер өлеше булып кына

Яулап була бөек үрләрне.

Матур сүзең, ыспай гәүдәң түгел,

Данга күмәр бары хезмәтең.

Сандугачны тыңла, - күренми дә -

Җыры белән ничек хөрмәтле.
1990

**Сине сөюем**

Рәхмәт сиңа, сөюемне белгәч,
Күзгә карап әйттең дөресен:
“Дуслар булып кына калыйк, - дидең, -
Миңа булган гыйшкың сүрелсен”.

Ә мин сине сөйми булдыралмыйм,
Мәҗбүр итә алмыйм үземне.
Син дә әле миңа карарсың бер,
Ала алмас булып күзеңне.

Сөюеңне сорап алларыңда
Мескенләнеп мәңге ялвармам.
Мин ярышка чыгам синең белән
Матурлыкка илткән юлларга.

Мине сихерләгән матурлыгың
Сиңа күктән төшеп иңмәгән,
Үзең булдыргансың зур тормышта,
Саклый-саклый хәтәр җилләрдән.

Мин ашкынам сиңа тиңләшергә,
Сине сөю миңа көч бирә,
Якты газап тулы йөрәгемдә
Ышанычлы хисләр үстерә.

Юк, мин сине сөйми булдыралмыйм,
Мәҗбүр итә алмыйм үземне.
Син дә миңа әле карарсың бер,
Ала алмас булып күзеңне.
1990

**Иң гади хикмәт**

Ферма яны – тирес тавы.
Башында баскан маллар.
Кырга карап, күз талдырып,
Азык көтәләр алар.

Ә хуҗалар идарәдә,
Зарлана азык юкка.
Безнең кырлар безнең башны
Калдыра дип хурлыкка.

Эшләсәләр икән алар –
Кырларга күчәр таулар –
Маллар күзләрен иркәләп,
Мул иген кырда шаулар,
Азыклы булыр маллар.
1990

*****

Мин дә шактый нәрсә булдыралам:
Кулларыңны кысмый торалам.
Утларында көн-төн яна алам,
Гайбәтеңә каршы баралам.

Ләкин сине сөйми булдыралмыйм,
Мәҗбүр итә алмыйм үземне.
Син дә, димен, миңа карарсың бер
Ала алмас булып күзеңне.
1990

**Укытучым әйтә торган иде**

Сугыш елы арышларын ашап,
Яткангадыр качып куакта,
Укытучым әйтә торган иде:
Бик кыю да син, дип, куркак та.

Кара төндә өйдән печән урлап
Ашаттым мин колхоз атларын.
Мин коммунист булдым динле килеш,
Икесен дә ләкин сатмадым.

Гомерем буе ике төрле будым,
Тик монафыйк юлга басмадым.
Кыюлыгым мине куркак итте,
Куркаклыгым кыю ясады.
1990

**Укытучым әйтә торган иде**

Сугыш елы арышларын ашап,
Яткангадыр качып куакта,
Укытучым әйтә торган иде:
Бик кыю да син, дип, куркак та.

Кара төндә өйдән печән урлап
Ашаттым мин колхоз атларын.
Мин коммунист булдым динле килеш,
Икесен дә ләкин сатмадым.

Гомерем буе ике төрле будым,
Тик монафыйк юлга басмадым.
Кыюлыгым мине куркак итте,
Куркаклыгым кыю ясады.

1990

**Кораб**

*Ил корабын җил сөрә*

*Дәрдмәнд*

Шаулый диңгез...
Ил корабын
Җил куа яңа ярга.
Төн вә көндез мин барамын,
Чайкалып дулкыннарда.
Мин ышанам
Саф җилләргә,
Өермәле булса да.
Ми бушана
Ят чирләрдән,
Давылда тән туңса да.
Һәр тарафта
Дулкын-таулар...
Ил корабын җил сөрә.
Безне тарта яңа ярлар,
Корбан түгел, җыр сорап.
И капитан,
Юлың дөрес,
Җилкәнеңне ташлама.
Төрле яктан гөрес-гөрес
Таш яуса да, каушама.
Яман ярдан
Яңа ярга,
Упкыннарны аралап,
Ялганнардан,
Ялалардан
Хаклыкка бара кораб.
1991

**Ике арада**

Үткәнне ник тоташ каһәрләргә?
Шомлы ачлык яный шәһәрләргә,
Сәер аптырау иңгән авылларга.
Юлбасарлар чыккан зур юлларга,
Үткәнне ник тоташ каһәрләргә?

Шомлы ачлык яный шәһәрләргә,
Берәүләрне төреп ак мәрмәргә,
Башны иеп юкка зурладыкмы,
Берәүләрне хаксыз хурладыкмы –
Шомлы ачлык яный шәһәрләргә.

Сәер аптырау иңгән авылларга,
Ташланырга кайсы агымнарга:
Бергә-бергә тормыш итәргәме,
Аерым-аерым булып китәргәме –
Сәер аптырау иңгән авылларга.

Юлбасарлар чыккан зур юлларга,
Хөкем кайда? Әллә соң алар да
Чагылышымы үткәннәрнең,
Истәлегеме киткәннәрнең?
Юлбасарлар чыккан зур юлларга.

Үткәнне ник тоташ каһәрләргә?
Киләчәккә барган сәфәрләргә,
Үрнәк алыйк үткән уңышлардан.
Сабак алыйк үткән ялгышлардан,
Үткәнне ник тоташ каһәрләргә?
1991

*****

Кемдер ачлык юрый, кемдер сугыш,
Күрәзәче тулды дөньяга.
Берсенә дә исе китми генә
Ишелеп-ишелеп тыныч кар ява.

Әйбер хакын күтәрергә даулап,
Сөзешәләр галим-тәкәләр.
Берсенә дә исе китми генә,
Бушлай ява көмеш тәңкәләр.
1991

**Татарстан**

Халкым минем таллар кебек,
Бар җиргә таралышкан.
Шул таралган татарымның
Мәркәзе – Татарстан.

Ничә баба рухы сеңгән
Борынгы бу туфракта.
Тамырларым тармакланып
Киткәннәр бик еракка.

Мин канәгать бу язмыштан:
Тарихым - олы дастан.
Җире - җәннәт, суы - ширбәт,
Бу - минем Татарстан.

Татар һич тә тартар түгел,
Тар дими, тарсынмый ул.
Бар милләтләр тату яшәп
Шат тормыш корсын ди ул.

Дуслар дуска баш булмасын,
Иш булсын дуслар дуска.
Башкага да гыйбрәт булып,
Чәчәк ат, Татарстан.

Җир-су - уртак, хәзинәбез
Булсын гел бер тырыстан.
Татулыкта, иминлектә
Мең яшә, Татарстан.

Без - тарихта тапсыз көзге,
Сәбәбе - күндәмлектә.
Гаугалы җир - һәлакәт ул,
Бәрәкәт - бердәмлектә.
1992

## Коммунизм

Ах, кызганыч алсу хыялларның
Гомер узып чынга ашмавы,
Тарих үзе иҗат иткәннәрне
Заман үзе сызып ташлавы!

Кешеләр ник тигез була алмый –
Ходай үзе шулай кушканмы?
Теләгәнен җирдә булдыралмый –
Кеше үзенә үзе дошманмы?

О, хыяллар, нинди гүзәл иде,
Нинди татлы иде киләчәк!
Җимерелде челпәрәмә килеп –
Таптап үтте язмыш – күрәчәк.

Һәркемгә дә, димәк, бирелмәгән

Намус дигән бөек көч – кодрәт.
Алдакчылар, димәк, мәңге яши,
Мәңгелеккә килгән үч-нәфрәт.

Әүлияләр гадел була алмый –
Нәрсәдә соң моның сәбәбе?
Ник алайса кеше үзен үзе
Якты киләчәккә әйдәде?

Туганлыкка җитеп булмыймыни,
Бүрелекме тормыш законы?
Сәләтсезме үзен үзгәртергә
Кешелекнең җыйган акылы?

Мең-мең китапларда ятып калды
Без ашкынган гүзәл замана.
Барысы ялган! – диләр.
Бәгырьләрдә
Чатный-чатный сәер ут яна.

Барысы ялган! – диләр.
Тик шулай да
Нинди якын миңа бу ялган!
Чыны кайда?
Мең ел кайный базар –
Нинди генә башлар югала,
Берсе алдый, берсе алдана.

Мең-мең китап яна. Буталышып,
Бергә яна ялган белән чын.
Үзем белән үзем бәхәсләшәм,
Үз-үземә җавап булганчы.
1992

**Мизгел һәм мәңгелек**

Без – дибез без, “без” – ул тора
Үз дөньясы булган “мин”нәрдән.
Бер – бөек көч, чөнки меңнәр –
Була ала бары берләрдән.

Туган вакытымнан теге якка –
Миллион еллар артка йөгердем –
Барып җиталмадым – кире кайттым
Дәресемә чак-чак өлгердем.

Шушы көннәремнән алгы якка –
Миллион еллар алга йөгердем –
Барып җиталмадым – кире кайттым –
Дәресемә чак-чак өлгердем.

Мәңгелек һәм чиксезлекне уйлап,
Мизгелләрнең кадере артты нык.
Мизгелләрдән башка мәңгелек юк,
Мәңгелектән башка мизгел юк.
1992

**Яшь егеткә**

Сөюемне белми диеп көтмә син,
Серләреңне сүзсез тынлык сөйләсен.
Бердәнбер ул сакламасаң югала,
Ә күңелдә үкенү дигән чир кала.

Әгәр миңа йөз кыз бар дип ышансаң,
Чын бәхетең беркайчан да атмас таң.
Күзләмә син һәр очраган йолдызны,
Күр шул кызның бер үзендә йөз кызны.
1993

**Яшьлек белән хушлашу**

- Вакыт сиңа, Сәйфи, картаерга,

Булып булмый җирдә мәңге яшь,

Бер син генә үзгә зат түгелсең,

Яшьлек белән, җитәр, бәхилләш, -

Шулай диде миңа яшьтәшләрем,

Озак карап тордым көзгемә:

Бик күп таптым картлык билгеләрен,

Моңсу булып китте үземә.

- И, яшьлегем, - дидем, - мин картайдым,

Синең белән яшәү килешми.

Кешеләрдән яхшы түгел, диләр,

Картларча яшәргә тиеш мин.

Хуш, яшьлегем, инде мине калдыр,

Картлык белән клдыр ялгызым.

Йөрәк белән йөзем тиң булсыннар,

Йөрәк ярсуларым басылсын.

Күнде яшьлек, очты күкрәгемнән,

Очты күккә нурлар эчендә.

Картлык белән бер ялгызым калдым,

Сырхау килде бөтен төшемә.

Күзләремдә дөнья шыксызланды,

Кап-караңгы калды хыялым.

Әйтерсең лә җаным очты минем –

Йөрәгемне буп-буш тоямын.

Мин ялвардым шунда: и, яшьлегем,

Йөрәгемә кире кайтсана!

...Рәхмәт сиңа, яшьлек, кире кайтып,

Күкрәгемдә иттең тантана.

Йөрәк типте яшәү дәрте белән,
Хисләр өермәсен кузгатып.
Мин картларча япь- яшь йөрәк белән
Матурлыкка тагын күз аттым.

Нурлар белән тулды йөз сырларым,
Ак чәчләрем рәхәт елмайды.
Хыялларым ап-ак чәчәк атты,
Барлык сырхауларым югалды.

Йөрәгемдә яши үз яшьлегем
Картлыгымны күмеп нурларга.
Һәр кешене кояш тигез назлый,
Тигез озата соңгы юлларга.

Яши яшьлек узган еллар булып,
Сөйгән ярлар булып йөрәктә.
Күзләремдә дөнья шуңарга яшь,
Кимесә дә көчләр беләктә.

Яшә, яшьлек, яшә картлыгымда,
Икәү бергә язсын үләргә.
Гөнаһлардан мине арала син,
Синең белән ашыйм күкләргә.
1993

### Яратмасаң

Яратмасаң, калдыр бер ялгызын,
Яратмасаң, ялгыз кал үзең,
Икегез дә тапсын үз йолдызын,
Йөрәгеңдә ялкын кабызып.

Яратмасаң, калдыр бер ялгызын,
Ялгызларга парлар табылыр.
Яратмыйча әгәр кавышыр булсаң,
Үкенерсең – инде соң булыр.

Яратмасаң, аны алдама син,
Яратмасаң, сөймә - алданма,
Яратмасаң, ялгыш килеп капма
Үзең иҗат иткән ялганга.

Мәхәббәтсез – идеалсыз яшәү
Ике гомерне дә буш итәр.
Кайнар сөю – илаһилык белән
Яшәүләргә җирдә ни җитәр.
1993

**Төнге зиратта**

Төпсез күкнең якты йолдызлары
Күзләремне йомшак иркәли.
Үләннәрне назлы кыштырдатып,
Вакыт ага тәнем үтәли.

Яшем үткән саен серлеләнә
Бөтнекләрнең төнге хуш исе...
Әни каберенә башны куеп
Онытылып килә үксисе.

Юк, ярамый, әби-бабайларның
Әрвахлары тыныч йокласын...
Ай-йолдызлар нурлар коеп торсын,
Җитсен җиде төннең уртасы.

Шул чагында герман якларыннан
Әти рухы кайтып тын гына,

Беркемне дә борчымаска теләп,
Үз нәселе янына сыена.

Төн тынлыгын бер дә бозмый гына
Кайта тагын ике абыйсы.
Тулылана шулай нәселем сафы,
Бергә күрешә шулай барысы.

Яшем үткән саен серләләнә
Бөтнекләрнең төнге хуш исе.
Әрвахларга дога укый-укый,
Иман белән килә яшисе.
1993

### Нәфрәтләнеп сөю

Нәфрәтләнеп тә сөяргә мөмкин!
Мөлдерәмә тулы сагыш белән,
Соңгы бәхетне тик шунда күреп,
Соңгы үпкә, соңгы каргыш белән.
1994

### Дөнья мине мең алдады

Фани дөнья мине мең алдады, -
Янсын әйдә җанда мең көенеч.
Үзем, шөкер, бер кат алдамадым –
Барсын каплый шушы бер сөенеч.
1994

### Булса да тешләрең ясалма

Булса да тешләрең ясалма,
Көлүең булмасын шул чама.
Булса да көлмәгең бик купшы.

Булмасын эчендә тик бушлык.

**Картайган саен**

Картайган саен, балачакка кайта барам,
Күрәсең, җаным Раббысының хозурына
Гөнаһсыз сабый булып кайтырга тели –
Максатның иң-иң асылына һәм зурына.

**Ватан улы була бел**

Атаң улы гына булма,
Ватан улы була бел.
Артка түгел, алга карап,
Заман белән атла гел.

**Мең кат кудым сине**

Мең кат кудым сине күңелемнән,
Мең кат кире кайттың күңелгә:
Диңгездәге мәңге күтәрелеш
Һәм чигенеш булдың гомергә.
1994

**Туган йортта**

Нигә рәхәт болай туган йортта,
Бар борчулар китә онытылып?
Эче-тышы чөнки әниемнең
Мәрхәмәте белән туп-тулы.

Идәннәрдә аның кул җылысы,
Тәрәз төбендәге кыналар,
Сүзсез генә тып-тын елмаешып,
Аңа рәхмәт укып торалар.
1994

## Мөңгер

И Мөңгер, Мөңгер – нәни инешем,
Сердәшем минем, дустым – үз ишем,
Читләрең чирәм – ямь-яшел хәтфә,
Хан түшәгеннән йомшактыр хәтта.

Инешләр алар җиһанда меңдер –
Һәркайсын өзелеп сөядер кемдер.
Минем инешем – бары син генә,
Йөрәк тибешем – туган җир генә.

Җиде бабамны күргән син, Мөңгер,
Аккан ялганып гомергә гомер,
Киләдер күзгә яшь мөлдер- мөлдер:
Үтеп барадыр минем дә гомер.

Шәфәкъ моңнары синең агышта,
Кыяк- камышлар тоташ сагышта.
И Мөңгер, Мөңгер, эчең тулы сер
Үтеп барадыр минем дә гомер.

Миннән соң да гел агарсың, Мөңгер,
Минем хакта да сөйләрсең бер сер.
Саф суың саклап үскән сусакка,
Яп-ялгыз калган моңсу усакка.
1994

## Ага Зөя безнең тарих булып

Гомерләрем шаулап үткән алан,
Керәшәле Зөя ярлары.
Аста сулар ага, язлар саен
Ташкын ашый минем яланны.

Дөньядагы гүзәл бу җәннәтем
Еллар үткән саен тарая.
Яшьлек имәннәрем ташкыннарда
Умырылып төшә ярлардан.

Яр эченнән чыгып керәшәләр
Оча битләремә кагылып.
Аларның да шушы ояларын
Яңа язлар китәр агызып.

Чираттагы имән баскан ярга,
Белми тиздән китеп барасын.
Ботагына кунган күке әйдә
Озын гомер аңа юрасын.

Аръяк ярда сөзәк җирләр арта,
Өянкеләр каплый моң гына.
Буйдан-буйга тезелешкән таулар
Бу хәлләргә карый тын гына.

Мәңгелекнең чагылышы кебек
Үзгәрмичә ята ул таулар.
Шул тауларның җәйпәк итәгендә
Тезелеп киткән серле авыллар.

Исемнәре милли, чын безнеңчә -
Өтәк, Чулпан, Мәйдан, Карамыш.
Халкы – урыс, татар кыяфәтле,
И гаҗәп соң безнең бу язмыш!

Бу ягыннан аның ерак түгел
Җәйрәп ята Норлат, Мулилем –
Татарлыгын саклап чорлар кичкән,
Хәсрәт эчкән җирем шул минем.

Ага Зөя минем гомерем булып,
Бергә бәйләп татар, урысны.
Азмы монда мин марҗалар белән
Җиләк җыйдым тутырып тырысны.

Көймәләрдә йөздем урыс белән,
Иделләргә юллар алдык без.
Зөя каласының каршысында
Икебез дә сүзсез калдык без.

Ага Зөя безнең тарих булып,
Явыз Иван йөзгән сулар бу.
Мең башларны өзгән шул явызның
Казасына түзгән сулар бу.

Татарча да, урысча да җырлап,
Тарих булып ага Зөябез.
Сулар уртак, җирләр уртак булгач,
Ике милләт дуслар тиябез.

Теге якта тауда – ак чиркәүләр,
Бу як ярда балкый мәчетләр.
Язмышлардан узмыш юктыр инде,
Һичвакытта булмыйк без читләр.

Һәр урысын беләм Карамышның,
Һәр марҗасын – Чулпан, Өтәкнең.
Безне бергә бәйләп Зөя ага,
Яраларын юып йөрәкнең.

1994

**Заманаы тартып барасың**

Уналтынчы язың иде синең:
Кыр түренә килдең бик иртә;
Бер тартуга гөрләп киткәч дизель,
Шатлыгыңнан алдың биеп тә.

Киттең таңда, офыкларга карап,
Киттең кырлар буйлап җир сөреп.
Сөрлексәң дә, туктап уфтанмадың,
Утырмадың авыр көрсенеп.

Гөрләп уздың назлы язлар аша,
Тургайлардан иңгән дулкында,
Күпереп, йомшап, кара кучкылланып,
Буразналар калды артыңда.

Уздың җәйләр аша болыннардан,
Печән теземнәрен калдырып;
Гөрләп кичтең төннәр патшалыгын,
Кара пәрдәләрен яндырып.

Уздың җилле, соры көзләр аша,
Үзле балчык тыгылып чылбырга,
Ыңгырашты мотор, ләкин үзең
Чыкмадың син һич тә чыгырдан.

Уздың чатнап торган салкыннардан,
Тимер булып тимер тилмерде.
Йөрәгеңнән туңган тимерләрне
Эретерлек җылы йөгерде.

Җиһан буйлап гөрләп киләсең син,

Ышанычлы, якты карашың.
Тракторың белән әйтерсең лә
Замананы тартып барасың.

Узган елларыңның һәр фасылы
Тагылып килә кебек артыңнан.
Син үзеңә һәйкәл торгызасың
Хезмәт дигән иң саф алтыннан.

Син киләсең гөрләп яңа язга –
Шушы язың – инде илленче.
Игелегең белән илне назлап,
Мең-мең яшә, батыр игенче.
1994

**Бәхетле син, кешем**

Бәхетле син, кешем, кулларың бар,
Тимер ясап, иген игәр өчен;
Бәхетле син, кешем, хыялың бар,
Ерак киләчәккә җитәр өчен.

Бәхетле син, кешем, хәтерең бар,
Үткәннәргә кире кайтыр өчен;
Бәхетле син, кешем, акылың бар.
Кояш кебек нурлы балкыр өчен.

Бәхетле син, кешем, зиһенең бар,
Могҗизалар серен аңлау өчен;
Бәхетле син, кешем, иманың бар,
Хак юлыннан читкә таймау өчен.
1994

*****

Ходай миңа туган йортны

Сагынырга язмаган.
Сагынуның ни икәнен
Беләм киек казлардан.
Гомерем буе бертоташтан
Яшәп туган нигездә,
Айрылмадым, кайрылмадым,
Йөрдем һаман бер эздән.
Дөньялыкта белмәдем мин
Сагынулар газабын.
Ахирәттән җаным кайтыр
Сагынып шундый чагын.
1995

**Замана әбиләре**

Инде менә сез дә картайдыгыз,
Инде сез дә әби тиясез.
Коллар кебек толлар, ирсез килеш,
Замананы сөйрәп киләсез.

Иман шартын укый белмиләр дип,
Дөнья сезне гаеп итмәсен.
Гөнаһлары үзләренә булсын,
Йөрәгегез әрнеп типмәсен.

Сандыкларда сезнең медаль ята –
Дөнья сезне шулай зурлады.
Шәһит киткән ирләрегез исемен
Ташка язды заман уллары.

Яшь чагында нәрсә караганнар?
Мәдрәсәгә килеп,  әбиләр
Иман шартын хәзер өйрәнәләр,
Соң булса да, булсын уң, диләр.
1995

*********

Тышта чатырман салкын гыйнвар.

Дәрес.

Парта өстендә камка пәйда булды.

Күңелдә җәй яралды.

Күңел офыкларга тикле җәелде.

1996

*****

Зәһәрләнден, кара көйдең тәмам,

Авызыңнан чыкты утларың.

Ләкин күңелем минем диңгез кебек

Сүзләреңнең яшен укларын

Үзенә йотып, төпсез чоңгылында

Тавыш-тынсыз гына сүндерде.

Ошап калдың мескен аждахага...

Шулай күрү сине күңелле.

1996

**Кара кеше**

(*Тукайдан сүзләр алып)*

Кая барсам, нишләсәм дә,

Калмый бер дә артымнан,

Мине берәү эзәрлекли –

Шайтанилар затыннан.

Кара эчле кара бәндә
Бертуктаусыз бәйләнә,
Авызыннан утлар бөркеп,
Яман усал сөйләнә:

Мин мөгаллим дип зурайма,
Татар теле укытып,
Татар телең –авыл тале,
Аннан килгән шымытык!”
(Татар теле укытып син
Күкрәк какма.
Татар теле – ул бит ү...
Аннан килгән берни юк.)

Аерырга теләп мине
Җан сөйгәнем – халкымнан,
Кра эчле кара бәндә
Көн-төн йөри артымнан.

Син үзеңчә изге эшләр
Эшләгәндә халкыңа,
Кара бәндә зәһәрләнеп
Тозак кора гаклыңа.

Бер син генә яхшы булма.
Безнеңчә йөрт үзеңне.
Тыңламасаң, кара, ди ул
Кыскартырбыз эзеңне.

Елан кебек сызгыра да
Кизәнә ул бәхтемә,
Ул бәдбәхет борыла-сырыла
Үрмәлидер тәхтемә.

Эт кебек һаулап яманым,

Күз йома ул яхшыма,
Көнләшә ул, түзми шайтан
Бик аз чыккан яктыма.

Яхшылыктан коты очып,
Кара көеп йөридер.
Милләтемнең бәгыренә
Бәбәкләрен теридер.

Саташтырмам сине, шайтан,
Чын кеше – инсан белән,
Безнең сафлар хәзер ишле,
Без көчле иман белән.

Гәүһәр кебек вөҗдан белән
Үткәч тормыш пычрагын.
Галиҗәнәп Вакыт безгә
Ачар нурлы кочагын.

И ачу тоткан көчек син!
Милләт башын ашыйсың.
Тукайларның ак рухына
Эч кереңне ташлыйсың.

Нәкъ Тукайча яшим дисәм,
Җиһанда шат, хөр булып!
Әллә кайдан син чыгасың,
Шатлыгыма тап булып.

Минем артта ышыкланып,
Алда торган түрәне
Үчекләп, мине аттырасың –
Яралыйсың күкрәкне.

Күзләреңнән шайтан карый

Кабан тешен ыржайтып.
Баемассың, тик бөләрсең
Милләт намусын сатып.
1996

**Дардуш**

*Мулла Иле авылында борынгы төрки этноним дардуш белән мөнәсәбәтле Дардуш кушаматы йөртүче нәсел бар (Сәйфетдин Дардуш, Гарәфетдин Дардуш, Бибинур Дардуш, Равил Дардуш, Ринат Дардуш, Рөстәм Дардуш Һ.б.). дардуш этнонимы беренче мәртәбә Танъюкук исемле каһарман хөрмәтенә багышланган төрки Орхон ташъязма ядкарьдә очрый.*

*Гомәр Саттаров хезмәтләреннән.*

*Танъюкук хөрмәтенә язылган текстның эчтәлеге борынгы төркиләр җәмгыятенең 10еллык тарихын (683-693еллар) үз эченә ала.* Татар әдәбияты тарихы, I том.

Туган авылым Мулла Иле
Зөя үзәнлегендә.
Беркая да китмим шуннан
Үзем исәнлегемдә.

Монда бит Гайнан Вәиси
Кайтканы саен читтән,
Изге җирем – бер генәм дип,
Сәҗдәләр кылып киткән.

Минем нигезем урталыкта –
Тора Олы урамда,
Бакчам арты - Әрә суы
Ташый язлар булганда.

Уңъяк күршем Гомәр Саттар
Мулилле әл-Болгарый,

Казаннардан сагынып кайткач,
Бездә кунак булгалый.

Бөтен йортым балкып китә
Аның шигырьләреннән,
Хикмәт чишмәләре ургый
Йөрәк бәгырьләреннән.

Минем нәсел кушаматын
Галим бик тә ярата,
Китабында фәнни ачыш
Ясый шуңа карата.

Шатлан, дус, ди, Дардуш дигән
Кушаматың барында:
Ташка уелган исем ул
Орхон язмаларында.

Җиденче йөздә яшәгән
Бер төрки кабиләнең,
Я раббым, мин хәзергәчә
Исмен саклап киләмен.

“Дардуш” – шигырь кебек матур,
Нәселем белән гел йөрсен.
Яшәсен бу кушаматым,
Яшәсен галим күршем.

Җиденче йөздә, күр, бабам
Кайларда бит яшәгән.
Гомәр Саттар аркасында
Ерак китте шәҗәрәм.

Орхон кайда!Зөя кайда!
Бөтен җирдә татар бар.

Татар булган бөтен җирдә
Безнең Гомәр Саттар бар
1996

**Ак төнбоек кебек борынгы**

Яшәсә дә Кызыл Китапта
Без кичергән хәтәр көннәрдә
Ак төнбоек, җанны иркәләп,
Күренгәли әле күлләрдә.

Ак төнбоек кебек борынгы
Татар теле Кызыл Китаптан
Чыгып килә олы тормышка,
Яшәсен дип халкым һәм Ватан.
1996

**Татар теле**

Латин теле кебек үле түгел
Татар теле.
Рецептларда түгел, көнкүрештә
Яши тере.
Урыс теле кебек бөек түгел
Татар теле.
Бөек телләр үлгәндә дә ләкин
Бетмәс түлке.
1996

**Гомергә ян, уңышлар көт**

Алтмыш тулган икән – тулсын,

Артка түгел, алга кара.
Ясалган дип күп хаталар
Йөрәгеңә алма яра.

Ул хаталар - яшькә сабак,
Ул шулардан гыйбрәт ала,
Хаталарын урап узып,
Ялгышмыйча алга бара.

Үкенмә син бу дөньяны
Алмадым дип шаккаттыра.
Гадилегең яшьләр өчен
Үрнәк булып балкып тора.

Гомергә ян, уңышлар көт,
Һич кайгырма картайдым дип.
Җәннәттә дә бар ул иҗат,
Җәннәттә дә иҗтиһат ит.

Иҗат – Аллаһ Тәгаләнең
Сиңа биргән бүләгедер,
Үзең белән ахирәткә
Бара торган терәгеңдер.

Иҗат – ике дөньяны да
Алга таба әйдәүче ул.
Иҗат безнең фанилыкны
Бакый белән бәйләүче ул.

Алтмыш тулган икән – тулсын,
Артка түгел, алга кара.
Яшьлегең бит – йөрәгеңдә,
Үзең белән бергә бара.
1997

## Мин өч кызны сөйдем

Мин өч кызны сөйдем гомеремдә,
Эчтән янып, тыштан мутланып.
Мәхәббәтнең өч язмышын кичтем,
Ал хыяллар белән тукланып.

Беренчесе – минем сөюемне
Белми калып китте кияүгә.
Икенчесе белде – каршы килде,
Һәм тормышка чыкты берәүгә.

Өченчесе – минем хатын инде –
Мәхәбәтнең насыйп булганы.
Насыйп булмаганнар йөрәгемдә
Яши бирә аңа ялганып.

Йөрәгемдә яши өч мәхәббәт,
Кушылып үскән гөлләр шикелле,
Бу – язмышым минем һәм бәхетем,
Өчесе дә якын шул тикле.
1997

## Матурлык

Миллион еллар элек тә бит җирдә
Зәңгәр күкләр булган, зәңгәр
гөлләр.
Якты нурлар чәчеп, таңнар
аткан,
Көннәрдән соң килгән айлы төннәр.
Аңсыз күзләрендә динозаврның
Гүзәл манзарасы зәңгәр таңның
Чагылган тик кыргый, хиссез генә,
Су шәүләсе кебек эзсез генә.

Ә матурлык туган Кеше белән,
Кеше белән бергә үсә килгән.
Керсез йөрәк аша карый торган
Күзләр генә аны күрә белгән.
Бары Кеше күзләрендә генә
Чыклар биешәләр җанлы булып,
Гөлләр телгә килә, уйный-көлә,
Һәр күбәләк, шөпшә телгә килә,
Таш булып таш уйлый-елый белә,
Җилләр яфрак белән сөйләшәләр,
Йолдыз белән йолдыз серләшәләр,
Ак болытлар туктап киңәшәләр...
Әгәр Кеше кинәт чыкса юкка,
Җир әйләнер күчәрендә бушка.
Шәһәрләрнең таш коридорларын
Үле тынлык сарыр,
Гөлләр матдә генә булып калыр.
Матурлык һәм Кеше аерылгысыз,
Матурлыкның гүзәл алиһәсе
Нәфисләнә, сылулана барыр
Гасыр арты гасыр үткән саен.
Атом җырлар, елмаер һәм балкыр
Кеше хисе дулкыннарында.
1997

## Синсез калган урамда.

Ничәнче кат кайтам яшьлегемә,
Һаман шулай шаулый бу урам.
Синсез калган йортның
                    каршысында
Күпмегәчә болай мин торам.

Монда кичләр күзләреңдәй зәңгәр,
Өрәңгеләр күксел эңгердә.
Йөгереп чыгарсың да, җитәкләшеп
Йөрербез күк тагын без бергә.

Монда төннәр чәчләреңдәй җылы,
Без вәгъдәләр биргән чатларда
Мәңгелек сер булып юкәләрдә
Безнең хатирәләр саклана.
(Күк күләгә булып юкәләрдә
Безнең хатирәләр саклана.)

Монда таңнар йөзләреңдәй алсу,
Таң җилләре синдәй ягымлы,
Синең кебек балкып кояш чыга,
Дәваларга теләп җанымны.
1997

**Нәни юбиляр**

Бүген зур бәйрәм –
Юбилей бездә.
Җыелдык менә
Барыбыз бергә.
Өстәл башында
Нәни юбиляр.
Әни-әбиләр:
 - “Үс, улым”, - диләр.
Бер яшь тулып син
Чыктың икегә,
Бишектән төшеп,
Чыктың иркенгә.
Инде зур үскән
Безнең Искәндәр:
Тешләр дә чыккан

Астан-өстән дә.
Ботинка киеп,
Идәннән чаба.
Ни тапса, шуны
Авызга каба.
Инде буе да
Өстәлгә җитә.
Хәтта өстәлне
Ул этеп китә.
Үрелеп менә
Диван өстенә?
Егылмый гына
Төшә дә белә.
Бусага аша
Мүкәләп чыга,
Песине күрсә,
Тота да ега.
Үзе егылса,
Елый да көлә.
Егылган төштән
Тора да белә.
Тиктормас малай
Безнең Искәндәр.
Чәчләр дә инде
Шактый үскәннәр,
Аларны матур
Итеп кискәннәр.
Безнең дәү малай:
Йомры бай малай,
Бар үз әнисе,
Бар үз әтисе,
Ике әбисе,
Ике бабасы,
Бик күп абыйсы,
Бик күп апасы.

Алар белән ул

Ипле сөйләшә.

Кулларын сузып,

"Бир" дип эндәшә.

Кеше киткәндә,

Ул карап кала.

Кулларын изәп

Озатып кала.

Алма тоттырсаң,

"Мәм-мәм, тәмле", - ди.

Батарей тотмый –

"Пеш-пеш" тәнне, ди.

Җылап та җибәр,

"Фонтан" да аттыр

Көн дә бер хикмәт -

Бер һөнәр арттыр.

1998

**Алтыдан алтмышкача**

Бик еш кайтып киләм кырык бишкә.

Клуб яны. Майның тугызы.

Мин – бер алты яшьлек кара малай

Тыңлап торам колак торгызып.

Җиңдек! – диләр, "ура" кычкыралар,

Кемдер мине чөйде һавага,

Җиргә төшкәч, һавадагы шатлык

Кара сагыш булды яңадан.

Шул сугышның кара сагышыннан

Телгәләнеп калды йөрәгем.

Ул этине миңа күрсәтмәде

Һәм әнинең йотты терәген.

Әтиләрне саклап йөрәкләрдә,
Мәңге сагынып, мәңге юксынып,
Без, малайлар, бик тиз ирләр булдык,
Кечкенәдән зурлар күк янып.

Без, малайлар, һич тә зарланмадык
Икмәк-бәрәңгесез калганда,
Үгез җигеп сукаладык җирне
Унөч яшьтән язгы сабанда.

Авыр булды, ләкин кайгыларны
Йөрәкләргә яшереп елмайдык.
Чәчләр юкка иртә агармады,
Юкка иртә олыгаймадык.

Безнең әниләрнең бәгырьләрен
Нинди генә пуля тишмәгән.
Үзләре ир, үзләре ат булып,
Кайтмаганнар өчен эшләгән.

Йөрәкләрне мәңгә телгәләде,
Бигрәк авыр килде замана.
Без малайлар йөрәгендә менә
Алтмышта да сәер ут яна.

Яна, дөрли, әрни, өзгәләнә,
Күмер кебек көйри бу йөрәк.
Һәйкәлләргә карап кына тынмый,
Торган саен яна көчлерәк.

Мәңгелек ут урамнарда түгел,
Бәгырьләрдә яна, бәгырьдә.
Бу сагышны мәңге җиңеп булмый,

Үзем белән бара кабергә.
1998

*****

Матурлыкың алиһәсе, диләр,
Диңгез күбегеннән яралган.
Безнең авылдагы һәрбер чибәр
Хезмәт диңгезендә чарланган.

Җиңел түгел гүзәл булулары,
Ансат кына булмый матурлык.
Матур дигән данны казанганчы,
Хезмәтеңдә күрсәт батырлык.

Хатыннарның гүзәллеге белән
Җәйдәй җылы кышкы иртәләр.
Күңел аклыкларын бөркеп тора
Тәрәздәге ап-ак челтәрләр.

Гүзәлләрнең гүзәллеге булып,
Урам тулы уйный сабыйлар.
Киләчәкне алар балкыталар,
Туар еллар булып шаулыйлар.
1998

**Ромашка**

(Сентименталь шигырь)
Тау итәгендә Ромашка үсә;
Сөйгәнен көтә, ә Болыт килми.
Керфекләренә моңсулык кунган,
Ак йөзе сулган, елмаймый-көлми.

Менә күк күкри, кылычлар уйный,
Тирбәлеп куя Ромашка шунда.
Килә сөйгәне – диңгез сулышы –
Бөркү һаваны юк итеп юлда.

Утлар уйнатып, Болыт килде ул,
Күктән җемелдәп энҗе коелды.
Ромашка белән болыт кавышты,
Ах, шул чак миңа авыр тоелды.

Ышанам, бәгърем, син килерсең бит,
Киптермәссең бит күңелне минем.
Тизрәк кил дә син, шифа яңгырдай
Сөюең белән коендыр, тиңем.
1998

**Коридорда йөри бер малай**

**1**

Коридорда – җиде яшьлек малай,
Беренчегә килгән укырга.
Сугыш әле кичә тынган гына,
Ул бәгырьдә яна сулкылдап.

Коридорда нәни малай йөри.
Яланаяк – тоташ чебиле.
Аны өйдән озата килмәгәннәр,
Ил кайгысы баскан һәр өйне.

Әтисен ул белми – сугыш йоткан,
Әни сутковойдан кайтмаган,
Әби сукыраеп өнсез ята
Өч баласын җуйган кайгыдан.

Сентябрьнең нурлы иртәсендә
Коридорда йөри бер малай.

Чәче – кара, күзе – шомырт кара,
Бите – гүя кара яккан ай.

Тартык малай, юаш һәм кырагый,
Сәерсенеп карый дөньяга.
Күзләрендә әллә нинди үпкә,
Әллә нинди сәер ут яна.

2

Мөгаллиме аның башын сыйпар.
Йөрәгенә кереп укытыр,
Бертуктаусыз чыңлап кыңгыраулар,
Зиһеннәрен гыйлем балкытыр.

Ул аркага фанер букча аскан,
Бик күп китап сыйган аңарга.
Шуңа утырып, таудан шуып төшәр –
Кызык табар кырыс дөньядан.

Ул гомергә калыр бу мәктәптә,
Бар ихласын куеп укытыр.
Кыңгыраулы еллар агымында
Үз дөньясын хәтта онытыр.

Коридорда – ап-ак чәчле бабай,
Кичке шәфәкъ яна тәрәздә.
Яна шәфәкъ, яна җылытмыйча.
Язлар булмый инде көзләрдә.

Аны бүген авыр тынлык баскан.
Соңгы көне аның биредә.
Уе һаман ага кирегә.

Узган гасырның ул мең-мең эшен

Эшләп туялмыйча картайды.
Яңа гасыр аңа мохтаҗ түгел.
Кемгә хаҗәт мескен карт айгыр.

Иргә түгел, миргә эшләде ул
Кыйссадагы Ишми агайдай.
Бик еректан моңсу гына карап,
Кулын изи нәни бер малай.
1998

**Җиһан әби**

Монда, авыл читендәге үрдә,
Җиһан әби йөри ни эзләп?
Ферманымы? Инде аны күптән
Куйганнар җир белән тигезләп.

Бәрәңгегә җәннәт монда – рәхәт,
Буразналар ап-ак чәчәктә.
Җиһан әбиләрдән калган тирес
Кешеләргә әле кирәккән.

Үткәннәрдән тирес исен иснәп,
Тора әби зиһене таралып,
Ап-ак чәчәкләрнең уртасында
Ак чәчләрен каплый ак яулык.

Ап-ак шәһәр кебек ул фермадан
Калган бары бетон бер каркас.
Шулдыр һәйкәл – кырык эш елына,
Заман сиңа башка таш тапмас.

Үр янында зират. Гүрләрендә

Яшьтәшләре ята әбинең.
Кырык елны бергә тартканнарның
Берсе исән. Кадерен кем белсен.

Үрдән ерак түгел Җиһан әби
Фураж тарткан иске тегрмән.
Билдән карга батып, капчыкларны
Ул иңкәеп шуннан китергән.

Онытылган, эштән чыккан карттай
Оеп тора мескен тегермән.
Җиһан әби кебек арган, талган,
Хәрәкәтсез калган, бөгелгән.

Үрдән аста – тоташ алсу җәйләү –
Җиһан әбиләрнең яшьлеге.
Тоташ киңлек булып нурда балкый
Кызлык чытлыкларын яшереп.

Шул җәйләүдән яуга киткән егет
Илле биш ел буе кайтмаган.
Җиһан әби җиһан күк картаеп
Һәм кыз булып үтәр дөньядан.

Ап-ак чәчәкләрнең уртасында
Ак чәчләрен каплый ак яулык.
Үз аягы белән йөри әле,
Иртәгесен аны кем җитәкләр,
Беркем дә юк. Ходай, бир саулык.
1999

**Ашыгырга миңа һич ярамый**

Миңа хәзер нигә ашыгырга –

Күп калмаган барып җитәргә.
Көнбатышка китә барган кояш
Сүрән җылы бөрки битләргә.

Көнчыгышта минем арттан сузыла
Биниһая озын күләгә.
Әллә нинди бер моңсулык килә,
Кошлар киткән тонык күлләрдән.

Ашыкмыйча карыйм уҗымнарга,
Карыйм әле күреп туйганчы.
Ә арышлар мине хәтерләрме
Кышлардан соң – алтын булгачтын?

Кирәксезгә санап, алтыннарын
Очыра каен көзге җилләргә.
Ә каргалар кире кайтыр өчен
Әзерләнә ерак илләргә.

Кабат яз килә дип алданыпмы,
Кабат чәчәк аткан тузганак.
Син дә, күңел, шулай икенче кат
Чәчәк атып кал бер – соң кабат.

Аяздамы, белмим, болыттамы –
Ничек булыр шәфәкъ – билгесез.
Гомер кояшы тик кабат чыкмас,
Калыр микән җирдә безнең эз?

Күк кояшы ләкин һәр иртәдә
Нурга төреп җирне гел чыгар.
Безнең гомер узган сукмакларда
Биешер микән энҗе тамчылар.
1999

**Син дөньяга кеше өчен килгән...**

Син кышын да чәчәк үстерәсең,
Өләшәсең бушлай - бүләккә.
Бит аларны шундый зәмһәрирдә
Табып булмый акча түләп тә.

Кешеләрне болай яратырга
Өйрәндең син каян, дускаем?
Яратудан куәт, көч аласың,
Йөз нурларың арта көн саен!

Кешеләрдән сиңа рәхмәт ява,
Җавап булып ява ярату.
Коенасың сөелү бәхетендә,
Кешеләргә шатлык таратып.

Мин сөенәм, дустым, янәшәмдә
Син булганга авыр көнемдә,
Мин дә синең кебек гомеремдә
Зарар китермәдем беркемгә.

Ләкин синең шулай булуыңа
Берәү бик тә йөри ачынып.
Кешеләрне ятканың өчен
Иблис кебек сиңа ачулы.

Кара кеше кабарынып йөри,
Ак күңелле булып елмая.
Явызлыгы күзләренә чыга,
Бәбәгеннән шайтан ыржая.

Ә син, дустым, аны яратасың,
Явызлыкка ачу тотмыйсың.
Зәмһәрирдә чәчәкләрең биреп,

Туган көне белән котлыйсың.

Син телисең аның үзгәрүен,
Үзең кебек кеше булуын.
Син телисең аның күңеленә
Керсез иман нуры тулуын.

Син кышын да чәчәк үстерәсең,
Өләшәсең бушлай бүләккә.
Бит аларны шундый зәмһәрирдә
Табып булмый акча түләп тә.
1999

**Туган телем**

Сүзләр, сүзләр, туган тел сүзләре,
Күңел бакчамдагы чәчәкләр
Мең-мең төсләр белән балкыйлар да
Мең-мең төрле хуш ис чәчәләр.

Юк җиһанда байлык моннан да зур –
Һәр чәчкәсе тора мең алтын.
Һәр чәчкәне миңа сөеп бирде
Гасырларны кичкән үз халкым.

Бишегемнән башлап гомрем буе
Миңа хезмәт иткән хәзинәм,
Бөтен хисләремә исем табып,
Синең белән атлыйм һәр җирдән.

Күңелем бакчасының һәр чәчәге -
Изге туган телнең һәр сүзе –
Әлмисактан нәфисләнә килеп,
Камиллекнең булган нәкъ үзе.

Минем гомер шушы хәзинәне

Бик кадерләп саклап, бөртекләп,
Туплап алып барса ахыргача
Һәм яшьләргә бирсә бик теләп,

Буыннарны буыннарга бәйләп
Бара торган алтын чылбырның
Бер алкасы булып яшәвемнән
Мин канәгать, риза булырмын.
1999

**Болытлар артында – зәңгәр күк**

Бүген көн караңгы, шыксыз дип,
Кадерлем, кайгыга тарыма:
Күкне тик болытлар каплаган,
Алар бит тик тормый – агыла.

Болытлар артында – зәңгәр күк,
Болытлар артында – ай-кояш.
Кышын да шомырттай карлардан
Хуш исләр таратып аңкый яз.

Аяз көн кадерен белергә
Кирәк ул томаннар, болытлар,
Күк йөзе елмаер һәм балкыр,
Еракка чакырыр офыклар.

Алдагы көнебез кояшлы,
Төнебез йолдызлы һәм айлы.
Аяз күк астында милләтем
Каршылар киләчәк язларны.
1999

**Олуг юбилей мөнәсәбәте илә**

О мөкатдәс РОНО аппарты!
Син дә, мин дә хәзер алтмышта –
Икебезнең уртак юбилей бу –
Күмел, әйдә, күмел алкышка!

Тәхетеңнең күрке Үзбәк ханга –
Мәгарифнең бөек иренә
Ал чәчәкләр бирик һәм утыртыйк
Юбилейның биек түренә.

И асыл зат, чал баш! Мине дә ул
Колагымнан тартып үстерде;
Миннән ике мәктәп төзеттерде
Һәм яшәргә бетмәс көч бирде.

Мәгарифнең гүзәл ханбикәсе
Харис кызы сабыр Сәрия
Йолдыз кебек балкый, кешеләргә
Ихтирамы чиксез бер дәрья.

Мәгарифнең биек күкләрендә
Габделхәбир кызы Әлфия
Тәхетле дә бүген, бәхетле дә -
Милли урынбасар – ул фея.

Яшел Үзән мәгарифе йорты –
Шунда барып йөрдем мин һаман.
Мине укытучы итеп алды
Инде мәрхүм чибәр Нәркәс хан.

Ә Җәгъфәр хан завуч итеп куйды
(Карап тора хәзер Казаннан);

Ә Үзбәк хан директорга кысты
Чыкмасын дип гомере казадан.

Инспектор Нурулла Бикмуллин
Минем эшкә бирде зур бәя;
Һәм Надежда өмет уты якты
Фёдор Иванович белән бергәләп.

Илгиз Мәгъдән безне күп тикшерде,
Акча язды Татьяна Павловна.
Ай кебек бер балкып китте монда
Үзебезнең Суфия Хәлиловна.

О мөкатдәс РОНО аппараты!
Син дә, мин дә бүген алтмышта!
Икебезнең уртак юбилей бу –
Күмел, әйдә, күмел алкышка.
1999

**Автобиографиям**

Картайсам да кыска булып калды,
Йон йомгагы кебек бертөрле.
Бер шигырьдә әйтеп биреп була
Артта калган бөтен гомерне:

Туган елым, әллә кая калып,
Күксел томаннарга күмелгән.
Балачакны сугыш ялмап алып,
Йөрәк калган утлы күмергә.

Әтине мин бер дә хәтерләмим:
Утлы Көнбатышта югалган.
Тумыштан ук ятим булган әни
Тол көенчә үтте дөньядан

Әби миңа, һәркөн тәүфикъ теләп,
Иман сүрәләрен ятлатты.
Тормыш мине, кысасына салып,
Тик бер генә юлдан атлатты.

Мулла Иле – минем туган җирем,
Мулла Иле – торган җирем дә.
Мәктәбендә үтте бөтен гомерем
Шушы булсын соңгы чигем дә.
1999

*****

Кешелекне яратам дип әйтү җиңел,
Яратам дип әйтеп кара күршеңне.
Ерактагы кеше һәрчак якын була,
Күрәлмисең бик еш якын кешеңне.

*****

Элек чакта шаккатканнар
Түрә русча сөйли алса.
Хәзер исә таң калабыз
Татарча сүз әйтә калса.

*****

Кеше үзе белми
Ак биләүле чагын,
Ак кәфендә чагын
Белми кала тагын.

*****

Бу дөньяны һаман каргыйсың син
Һәм бетүен тизрәк телисең.
Ә тумаган булсаң бу дөньяга,
Күрер идеңмени тегесен?
Ни кызганыч – шуны белмисең.

**Ачык дәрес**

Меңләп ябык дәрес биреп әле
Кемнең булганы бар мәртәбәле?
Бир бер ачык дәрес, куштанланып –
Хуҗаң итәр шундук дәрәҗәле.

**Яшьләргә**

Сез кабызган учак гомер буе
Якты янсын, дәртле дөрләсен;
Очкыннары, безне сокландырып,
Йолдызларга кадәр үрләсен.

*****

Татар телен җимереп атып булмый,
Борынгыдан килгән шәһәр кебек.
Ул бит әле матди генә түгел,
Ул җан кебек тере һәм мәңгелек.

**Хәзер миндә**

Хәзер миндә акыл гына торып калды,
Хисләр сүнде,
Хисләр белән бергә син дә сүндең –

Акыл җинде.

**Яшел шәлең, каен, кая очкан?**

Яшел шәлең, каен, кая очкан?
Кара көзнең кара җилендә
Кара толымнарың чәбәләнә
Һәм чайкала шәрә иңендә.
2000

**Егерменче гасыр**

Егерменче гасыр, мин – синеке! –
Мең эшеңне эшләп картайдым.
Туар гасыр, юк, минеке булмас,
Кемгә хаҗәт мескен, карт айгыр?!

Гасыр бабай! Без китәрбез җирдән,
Син тарихта яшәп калырсың.
Безнең гомерләрнең моңлы рухын
Киләчәккә алып барырсың.
2000

**Рәхмәт сиңа, җирем**

Рәхмәт сиңа, Җирем,
Эш кешесе
Кулы тигән һәрбер почмагың
Кеше өчен, кеше бәхете өчен
Тулы ача үзенең кочагын.

Рәхмәт сиңа, Җирем,
Эш кешесе
Тире тамган газиз туфрактан

Бер могҗиза булып бодай шыта.
Кеше тормышына җырлап дан.

Рәхмәт сиңа, Җирем,
Эш кешесе
Зиһен көчен түккән урында
Тимергә җан керә,
Таш терелә
Һәм җанлана кояш нуры да.
2000

**Ил үзе сөйләр**

"Кешене рәнҗеткәнем юк,
Җәбер-явызлык кылып,
Алдамадым һичкемне дә
Мәкерле хәйлә корып", -

Шулай диеп мактана күрмә,
Тик яткан ташлар көләр;
Күпме яхшылыгың тиде? –
Монсын ил үзе сөйләр.
2000

**Татар мәктәбе**

Мәктәп – гүя киләчәккә карап
Сәфәр чыккан заман корабы.
Шул корабта, ил өметен аклап,
Бертуктаусыз юлда барамын.

Давыллар да була, томаннар да,
Зәңгәр күкне каплый болытлар.
Ләкин кояш чыга, хуплап безне,

Еракларга чакыра офыклар.

Көннәребез булсын гел кояшлы,
Төннәребез – айлы, йолдызлы.
Шулай булсын өчен мәгърур мәктәп
Сөеп бага һәрбер ул-кызны.

Рәхмәт, мәктәп, нурлы гыйлем йорты –
Балачакның алтын сарае!
Уйнатасың назлап һәм кадерләп
Халкыбызның милли сорнаен.

Яшь гакылга гыйлем сеңдерәсең
Тормыш күкләренә үрләргә;
Яшь күңелгә ак нур иңдерәсең,
Өйрәтәсең чынлап сөяргә.

Синдә үсә илнең киләчәге –
Әткәй-әнкәйләрнең дәвамы –
Кешеләргә изгелекләр кылып,
Явызлыкны җиңә торганы.

Халкыбызның күз карашы, мәктәп,
Өмет белән сиңа төбәлгән.
Син бар чакта бәхет һәм тынычлык
Булыр, дибез, килер көннәргә.
2000

**Малаеңның шуклыгына**

Малаеңның шуклыгына
Ачуың чыгып кулың озайтма –
Кулың авыртыр.
Шуклык анда тормас – китәр.
Явызлыгың, зураеп,
Үзеңә кайтыр.

*****

Кыш ул – рәссам. Тәрәзәгә ясый
Чәчәкләрнең чуар бәйләмен.
Һәм яңарта безнең күңелләрдә
Хатирәсен узган җәйләрнең.

**Атабыз Адәмнең...**

Уфтанма, сукранма, шөкер ит дөньяга –
Кулыңда машина, өеңдә газ яна.
Атабыз Адәмнең берние булмаган,
Шулай да ул безгә рухланып юл ярган.

**Кырык бер кыраудан калган гөл**

Кырык бер кыраудан калган гөл
Бакчамда чәчәккә күмелде –
Илаһи матурлык терелтте
Кырык бер ямаулы күңелне.
2000

**Гомер**

Гомерең, диләр, инде үтеп бара...
Ышанасы килми һич кенә:
Мин бит әле менеп җиттем генә
Ымсындырган үрләр өстенә.

**Чиксезлек**

Чиксез икәнен дә беләм, ләкин,
Хәйран калып чикнең югына,
Уем оча гел җитәргә теләп

Чиксезлекнең теге ягына.

**Депутат**

Ул кандидат чакта хәлдән тайды,
Халкы өчен бөтен көчен куеп.
Инде дүрт ел лаеклы ял итсен,
Йомшак кәнәфидә йомшак оеп.

**Гомерлеккә**

Монда, аулак кыргый әрәмәдә,
Мәңгелекнең шушы төшендә
Әрә белән Зөя кавыша бергә,
Яшеренеп кеше күзеннән.

**Һаман яхшы булып йөрсәң**

Һаман яхшы булып йөрсәң –
Көнләшерләр:
Колаклардан колакларга
Гайбәт өләшерләр.

**Ялгыз чакта**

Ялгыз чакта ялгыз булсаң –
берни түгел,
Ашкынырсың дуслар арасына.
Дуслар арасында ялгыз калсаң –
Түзәрсеңме йөрәк ярасына?

**Декабрь таңы**

Сул офыкта галәмәт зур кояш
Тау өстенә чыгып утырган.

Уң офыкта йомры туп-тулы ай
Аңа карап күзен тутырган.

### Кирәкми, димәк

Атна буе эчеп йөреп тә,
Эше бара икән –
Кыскартырга кирәк:
Андый штат кирәкми, димәк.

### Кеше артыннан бару

Кеше артыннан ияреп
Ансат барган сукмакны
Табып булмый икән, дуслар,
Ялгызың барган чакны.

### Ялгызың барган чакта

Кеше артыннан ияреп
Барган җир онытыла.
Ялгыз барып табып кара –
Шайтаннар ялгыштыра.

### Диванамын

Диванамын:
Чынлык, хаклык тапсам –
Куанамын.
Акча тапкан юк.

### Шәхес

Кыймадым мин ялгыз җырга,
Калырмын дип куркып хурга,

Җырладым гел кушылып хорга.
Инде белдем: халык өчен
Ни сандугач мин, ни карга.
2001

**Без – җиһанның гади бәндәләре**

Олуг патшалар да хаталанган,
Бөек шагыйрьләр дә ялгышкан.
Кубрат, нәфесләнеп, байлык җыйган,
Хәйям хәмер белән ярышкан.
Без, гадиләр, үзебез гөнаһларны
Алар исеме белән акламыйк,
Алар хаталарын кабатламыйк,
Алар ялгышларын ясамыйк.
Без ирешик шундый биеклеккә.
2001

**Кайрадым мин...**

Кайрадым мин чалгы һәркемгә,
Кайрамадым тешне беркемгә.

2001

**Төш**

Үлеп барам бозлар арасында,
Дөм караңгы салкын котыпта,
Тәнем өшеп, боз шикелле ката
Гүрдә түгел, котсыз бушлыкта.
Бер кәлимә Ясин ишетмичә,
Гаип булып нурдан, кешедән,
Бер уч туфрак күрми үлдем шулай...
Бәхетемә каршы, төшемдә.
Ә өнемдә насыйп булса иде
Үз өемдә тыныч үләргә,
Ятсам иде авылым зиратында
Тын кабердә күмелеп гөлләргә.
Янәшәмдә әни гүре булсын,
Зикер әйтеп торсын тупыллар,
Тәмле арыш исен, бөтнек исен
Алып килсен җылы дулкыннар.
2001

**Ялгызлык**

Ялгыз чакта ялгыз булсам –
Түзәрмен мин.
Кешеләргә илткән юлны
Эзләрмен мин.

Тик кешеләр арасында

Ялгыз калмыйм,
Ыргытылып, читкә кагылып,
Сансыз калмыйм.
2001

**Атлантида**

Атлантида, Атлантида –
Әллә чын, әллә ялган.
Шаһит булып ул чаклардан
Ай калган, кояш калган.
Безнең гомер – Атлантида
Айкалыр да чайкалыр,
Бездән шаһит булып бары
Кояш калыр, ай калыр.
2001

**Мин яраткан мизгел тагын килде**

Мин яраткан мизгел тагын килде,
Аваз салды бар җан иясе.
Аккорд бирде күлдә бакаларның
Җанга якын симфониясе.

Хәтерләтеп чикерткәләр чырын,
Бака җыры чыңлый колакта.
Шушы чыңнар белән күтәрелә
Исерткеч ис юеш туфрактан.

Таллар мыштым гына яфрак яра
Бака моңы дулкыннарында.
Тупыллардан әчкелт хуш ис аңкый
Кичке шәфәкъ салкыннарында.
2001

**Җәйге яңгыр юа йөрәгемне**

Җәйге яңгыр ява күбекләнеп,
Куыклары тора өрелеп,
Чәчләремне юа, битләремне,
Аркам буйлап ага йөгереп.

Җәйге яңгыр юа йөрәгемне,
Юшкыннарын китә эретеп,
Һәм салават күперен кора кояш
Күңлем балкышына тиң итеп.

Кайгыларым бар да юылып төшә,
Җиңеләеп калам, сафланам.
Сабыйлыкка кире кайткан кебек
Бер сәбәпсез көләм, шатланам.
2001

**Татар теленә**

Минем гомер синең хәзинәңне
Бик кадерләп, саклап, бөртекләп,
Туплап алып барса ахыргача
Һәм яшьләргә бирсә бик теләп,

Буыннарны буыннарга бәйләп
Бара торган алтын чылбырның
Бер алкасы булып яшәвемнән
Мин канәгать, риза булырмын.
2001

**Һәйкәлләре монда әтиләрнең**

Һәйкәлләре монда әтиләрнең,
Исемнәре ташка уелган.
Каберләре ерак Европада,
Өсләренә йолдыз уелган.

Бүген безнең янга – тын бакчага
Әрвахлары очып кайткандыр,
Күренмичә карап торалардыр
Алар безне – заман картларын.

Карап торалардыр күренмичә,
Исәннәрдән алар ни көтә?
Бернигә дә мохтаҗ түгел алар,
Бер минутлык тынлык – шул җитә.

Ватан өчен шәһит киткән алар,
Без яшәсен өчен үлгәннәр.
Үзләре гел яшь көенчә калып,
Гомерләрен безгә биргәннәр.

Без яшәдек, давылларда сынып
Тернәкләнгән имән шикелле...
Безнең үткән гомер дәфтәренә
Заман, шаять, куймас икеле.

Без яшәдек, шуның өчен менә
Чал башларны түбән иябез.
Бу дөньяны матурларга, шөкер,
Хәтер дигән көчкә ия без.

Безнең оныкларда дөрли әнә

Шәһит киткәннәрнең ялкыны.
Тамырларда ага алар каны,
Давыл екмас алар токымын.
2001

**Салмыш чакта...**

Салмыш чакта син бик мәрхәмәтле,
Риясыз һәм нечкә күңелле.
Айныгачтын барысы юкка чыга
Төштә тапкан акча шикелле.

**Эт-шайтан**

Минем артка ышыкланып һәм мин булып
Алда торган түрәләрне үчекләдең,
Ук аттылар миңа, ә син ләззәтләндең,
Шаркылдадың җыйнап барча көчекләрне.

**Хеопс пирамидасы**

Бер исемгә сыеп калган
Барлык төзүчеләре.
Юк көнләшү, юк үпкәләү,
Тып-тыныч, юк үчлеләре.

**Кем җавап бирә?**

Кызыл китапка кергән татарга

Инкыйраз яный – үткен күз күрә.
Гөлләргә илдә тыюлыклар бар,
Милләткә - кайда, кем җавап бирә?
2001

**Авыл башлыгының йорты яна**

Авыл башлыгының йорты яна,
Бөтен авыл килгән күрергә,
Җыелышып карап каткан халык,
Беркем кыймый утка керергә.

Буран белән бергә котырып ут,
Ялмап йота төннең карасын.
Халык башлык көтә, фәрман көтә,
Мондый хәлдә чара кайда соң?

Афәт нәкъ вакытын сайлап килгән:
Күз ачкысыз шушы мәхшәрдә
Авыл башлыгы юк – йорт хуҗасы
Больницада ята – шәһәрдә.

Җыерылмас кашлы башлы башлык
Беркемгә дә золым кылмаган.
Кешеләргә бик күп йорт салдырган,
Берәүгә дә зарар салмаган.

Җил дә, илгә зарар килмәсен дип,
Утны куа кырлар ягына.
Үз йортына афәт янамагач,
Карап тора халык тын гына.

Язмышныңмы усал шаяруы –
Җавап табып булмый моңарга.
Үпкәләгән кебек үрсәләнеп,

Чатный-чатный дөрләп йорт яна...

Ә хуҗасы кичә кайталмаган:
Чыгып барган чакта каланы,
Янгын күреп, туктап, утка кергән
Һәм коткарган ике баланы.
2001

### Ачык һәм ябык дәрес

Ачык дәрес бирдем. Башкаларның
Ни әйтәсен беләм үзем дә.
Ник тегеләй, болай итмәдем дип,
Уйга батып торам хәзергә.

Мактау көтмим, көтәм тик дөреслек,
Күңел һич тә түгел канәгать.
Ябык дәресемә кереп китәм
Табар өчен җанга сәгадәт.

Монда кайтам тәмам асылыма,
Үземә мин патша, хөкемдар.
Юк, ясалма битлек кимим монда,
Монда минем тулы иркем бар.

Монда юктыр кер эзләүче синнән,
Яшерен көнләшүче зат та юк.
Юктыр купшы гыйльми сүз әйтүче,
Данга сусап, гайре мактанып.

Юк җитәкче монда – даһиланып,
Үзен әллә кемгә санаучы,
Буйсындырып сине нәкъ кол кебек
Гаршеләрдән торып караучы.

Юк ялагай – хуҗа зәвыгына
Гел ләббәйкә әйтеп торучы,
Шул юл белән өскә үрмәләүче,
Хәтта галим-хәлфә булучы.
2001

**Балачакның шундый биек тавы**

Балачакның шундый биек тавы
Без үскәчтен калды бик нәни.
Заманалар үтеп, без картайгач,
Ул яңадан үсте, билләһи.

**Без утырткан нәни наратлардан**

Без утырткан нәни наратлардан
Шаулап үсте калын зур урман.
Урман үскән чакта гомерләрнең
Үтүләре өчен кайгырмам.

**Гомер сәгатенә**

Туктап куйсаң - җибәрәлмәм,
Борып кирәк урыннан:
Син бит минем кулда түгел,
Син бит язмыш кулында.
2002

**Төклетура**

Ходай сине матур киендергән:
Чем карадан, хәтфә сарыдан.
Жу-жу килеп тартып кубызыңны
Ни сөйлисең миңа изге җан?

Төклетурам, хәйран калып торам:
Юк килмәгән җирең бер генә.
Син кайларда кышлап, кайсы яктан
Килеп кундың апрель гөленә?
2002

**Яшел Үзән**

Яшел Үзән диләр безнең якны
Гөлбакчадай матур булганга.
Чал Иделнең йомшак җиле белән
Бөдрә таллар шаулап торганга.

Яшел Үзән диләр безнең якны
Мул игеннәр гөрләп үскәнгә.
Сандугачлы Зөя буйларында
Карлыганнар тулып пешкәнгә.

Кешеләрнең иң-иң гүзәлләрен
Үзенә туплап яши алганга
Яшел Үзән үсә, матурлана,
Һәм яшәрә бара һаман да.

Чал Казаннан нурлар алып балкый
Карауҗасы, Күлбаш, Бишнәсе.
Зур юлларга озатып кала сине
Ак бәхетләр теләп Әйшәсе.

Дастан булып күтәрелә Норлат,
Еракларга сибелә нурлары.
Монда бит ул, монда алмаларның
Эрмекләнеп пешә торганы.

Бу төбәкнең иңлә тугайларын,
Тургайларын тыңла Танайның.

Шунда гына татып була тәмен
Бездә үскән арыш-бодайның.

Борынгы безнең тарихыбыз.
Юк, югалмас безнең хәтерләр.
Каюм бабай Насыйриның рухын
Саклый Шырдан, саклый кадерләп.

Мул Иленә кил дә, тып-тын калып,
Тыңла моңлы азан тавышын.
Һәм аңларсың безнең гүзәл якта
Замананың ничек агышын.

Иделкәйгә сыенып бәхет тапкан,
Яшел кала – төбәк шәһәре.
Татар илен танытып еракларга.
Гел арттыра бара шөһрәтен.

Кил Күгешнең иркен кырларына,
Күр үскәнен ничек кәбестә.
Безнең якның гүзәл кешеләре
Могҗизалар ясый һәр эштә.

Безнең өстә кояш бөтен җирдән
Ягымлырак яна, назлырак.
Һәр йортына бәхет үзе килә,
Ел буена бездә яз тора.
2002

### Йолдызнамә

Шагыйрьләр бик күп бит, шулай да
Ник сиңа табындым, Лермонтов?
Ник сине яраттым, Есенин,

Хисләнеп, дөньямны онытып?

Соңыннан аңладым: без икән
Бер йолдыз астында туганнар –
Үлчәүләр – алтын көз затлары,
Көз моңын тыңлап зар булганнар.

Шуңадыр бу дәрья – тормышта
Мин ялгыз җилкәндәй чайкалам.
Күделдә - торналар елавы,
Очалмыйм – яп-ялгыз мин калам.
2002

**Мәхәббәт – кара урман**

Сиңа булган мәхәббәтем – кара урман,
Шул урманнан мине алып чыга торган
Юлны, ахры, гомрем буе таба алмам,
Сөю янар хәсрәт булып эчтә һаман.

**Сфинкс “Уникс”**

*Казанда, Пушкин урамында, хәзерге “Уникс” бинасы урынында диварына бик матур итеп “Бу йортта Такташ яшәде” дип язып куелган йорт бар иде без яшь чакта*

Менә монда, Пушкин урамында,
Бу галәмәт пулат “Уникс” –
Такташ торган йортны йотканына
Үкенеп ята торган сфинкс.

**Көз**

Кырлар чишенеп яткан йокларга,

Яшереп саклый аларны томан.

Яфрак кала көпчәк эзендә

Алтын көзнең мөһере сыман.

**Ничек өлгерергә?**

Инде хәзер ничек өлгерергә?

Эшләнмәгән эшләр тау-тау тора.

Кайгырмас та идең әле –

Гомерләр бит узып бара.

**Кара кешегә**

Һәр сүземнән, һәр эшемнән

Көлдең мыскыл итеп.

Үзеңә ияреп көлгәннәрне

Күрдең дустың итеп.

**Вакыт ага**

Вакыт ага күзгә күренмичә,

Ага галәм аша, йолдызларның

Берсен кабызып, берсен сүндереп.

Вакыт ага таулар аша,

Вакыт ага минем тәнем аша.

**Чишмә кебек тышка ургыла**

Мин шигырьне иҗат итеп тормыйм,

Тормыш үзе тоташ моң гына.

Хисләр, эчкә сыймый башлагачтын,

Чишмә кебек тышка ургыла.

**Киләчәк ходай кулында**

Намазыңны хәзер укы,

Казаларга калдырма.

Хәзер син бар – шуңа шатлан,

Бәхетеңне качырма.

**Яшерен серем**

Уңъярымшарыма кереп оялаган

Яшерен серем!

Синең белән миңа нишләргә?!

Үзем белән генә була сөйләшеп,

Үзем белән генә була серләшеп.

2002

**Комета**

Карап калыйк әле төн йокламый,

Карыйм әле күзем талганчы,

Беренче кат һәм дә соңгы тапкыр

Насыйп тамашадан туйганчы.

Зәңгәр күктә көн-төн йөзәсең син,

Зур койрыклы, серле бер затсың,

Биш йөз елга тик бер генә килеп

Китә торган сирәк кунаксың.

Син китәсең тагын без белмәгән

Галактика чоңгылларына.

Сәлам әйтче, анда кеше булса,

Безнең җирнең угылларыннан.

Биш йөз елдан тарих кабатланыр:

Син үтәрсең тагын бу юлдан.

Карап торыр халык исе китеп,

Алар арасында мин булмам.
2003

**Әни**

Май иртәсе шундый көләч иде,
Нәкъ әни кебек.
Тын бакчада әни тып-тын йөрде
Елмаеп, көлеп.

Ул өйрәнгән иде кайгыларны
Эчкә күмәргә,
Күз яшьләрен йөрәгенә яшереп,
Тып-тын көләргә.

Юк иде бит безгә шомланырга
Һичбер сәбәп тә.
Ул хушлашып йөргән икән шулай
Соңгы сәгатьтә...

Ике күзен миңа баккан килеш
Тынды әнием,
Шул сурәте калды мәңгелеккә
Аңымда минем.

Бер мизгелдә тәрәз төбендәге
Кыналар сулды.
Алмагачның ап-ак чәчәкләре
Кап-кара булды.

Бер мизгелдә сирень, хәлсезләнеп,
Койды чәчәген.
Нигә, әни, рәхәт заманада
Бик аз яшәдең?

Үткән гомерләрем бер-бер артлы
Ага кирегә.
Исән чакта өлгердем мин аңа
Нәрсә бирергә?

Ул яшәде һаман билен бөгеп
Кырлар түрендә,
Сугыш йоткан әтиемнең хәтта
Күрми гүрен дә.

Ул өйрәнгән иде кайгыларны
Эчкә күмәргә,
Күз яшьләрен йөрәгенә яшереп,
Тып-тын көләргә.

Алга барыр хәлем юк әлегә,
Барам кирегә.
Исән чакта өлгермәдем аңа
Нәрсә бирергә?
2003

**Сөеклә әнкә**

Йорт падишаһы,
Сөекле әнкә -
Изүең тулы
Зөбәрҗәт тәңкә.

Бер дә кызганмый
Куеп бар көчең,
Яшисең җирдә
Тик безнең өчен.

Зур йөк күтәреп
Нәни иңсәңдә,

Көн буе эшләп
Арып китсәң дә,

Карыйсың безне
Сөеп, яратып.
Ягымлы, җылы
Нурлар таратып.

Күңелләр гөле
Сөекле әнкә!
Бу җырны сиңа
Бирәм бүләккә.

Бирмимен сиңа
Миллиард тәңкә,
Син бит бәһасыз
Сөекле әнкә.
2003

**Шушындый чатнама салкында**

Ни дисең үзсүзле Дилбәргә -
Акыллы киңәшкә карамый.
Әнисе хак сөйли: салкында
Клубка чыгарга ярамый.
Ә Дилбәр әнисен тыңламый:
Шушындый чатнама салкында
(Танцылар була бит, нишләтик)
Клубка ашыга тагын да.
Шул яшьлек гаепле, нишләтик,
Акыллы киңәшне тыңламый.
Әни дә гаепле: Дилбәргә
Уналты тулганны аңламый.
Йөрәктә ут янгач, салкынның
Юк инде гомергә тиясе.

Урамда искиткеч гүзәл моң –
Зәмһәрир суык симфониясе.
Биегән шикелле җип-җиңел
Атлаган аяклар астында
Кар җырлый. Ток узган чыбыклар
Көй суза багана башында.
Юк, димә син, Дилбәр, яшермә,
Мин беләм егетең барлыгын.
Мин беләм яшьлегең язының
Ак карлар шикелле сафлыгын.
Ашык син, ул көтә, кызула,
Егетең йөрәген дәвала.
Тик чәчәк икәнең истә тот:
Яз көне кыраулар еш була.
2003

**Бүген тагын йоклап булмас, ахры**

Бүген тагын йоклап булмас, ахры,
Тагын шигырь кайтты ияреп, -
Кайтты илнең шатлык-кайгылары
Күңелемә таудай төялеп.

Нишлим, илнең бөтен борчуларын
Үзенеке иткәч йөрәгем,
Бәхет итеп күргәч бу тормышта
Кешеләргә үзенең кирәген?!

Көннәр буе төялгәнне төнлә
Шигырь юлларына бушатып,
Яңа көнгә калам җиңеләеп,
Яңа салган йорттай бушанып.
2003

*****

Син яхшыра барган саен сиңа
Арта бара икән үчлеләр.
Андый көнчеләрне җиңә ала
Фәкать рухы белән көчлеләр.

Җиңелгәннәр җиргә егылып аунар
Үчлеләрнең табан астында.
Инде алар сиңа үчекмәсләр:
Син чүп инде дөнья каршында.

Җиңелмәгән жан да рәхәт күрмәс:
Тоташ көрәш булыр юллары.
Ләкин сабырлыклар канатында
Ул җан ашар күккә - югары.
2003

## Егет булсаң

Егет булсаң – син шундый бул:
Таңбатыр шикеллерәк.
Куәт ничек кирәк булса,
Акыл да шулай кирәк.

Егет булсаң – син шундый бул:
Намус белән бул юлдаш;
Кая барсаң да тырыш бул,
Тырыш егет хур булмас.

Егет егетлеген итәр,
Ат эчерер буранда;
Өермәләр аша үтәр
Илгә кирәк булганда.

Егет булсаң шундый бул син:

Чык батырга алмашка;
Үзең ега алмасаң да
Тырыш син егылмаска.

Егет булсаң – Җәлил кебек
Илеңне ярата бел;
Кыен чакта үз халкыңның
Кайгысын тарата бел.
2003

******

Гомер дәфтәреңне сөргечләп куй,
“Үтә яшерен” дип бас мөһер дә.
Яшерен гөнаһларың беркем белмәс,
Үзең белән барыр кабергә.

******

Гел яхшылык кылып сөелим дисәм,
Хөсетлек бар икән җирдә, белмәдем.
Эш белән илне сөендерим дисәм,
Эшем җилгә очкан икән, белмәдем.
2004

**Мин карт инде**

Мин карт инде.
Минем белән бергә,
Бу дөнья да күпме үзгәрде:

Асфальт күмеп китте балачакта
Яланаяк йөргән эзләрне.

“Уфалла”га җигелеп, әни белән,
Читән өчен чыбык ташулар.
Чабатаны көрттән алалмыйча,
Көч-хәл белән торып басулар.

Җәйгә чыккач, тирес өемен җәеп,
Ягулыкка кирпеч сугулар.
Болыт кебек черки көтүенә
Түзә алмый учак ягулар.

Яу кырында үлгән әтиемнән
Мирас булып калган пәлтәләр.
Әниемнең нәни урагыннан
Кырлар тулып калган көлтәләр.

Ындыр табагында төннәр буе
Тәпәч белән ашлык сугулар,
Капчык белән билчән ташыганда,
Эссе юлда кояш сугулар.

Бүген инде алар берсе дә юк,
Саклаunion фәкать хәтердә...
Балачакның кайтавазы булып,
Тик тургайлар гына хәзер дә,

Картаймыйча, һаман элеккечә,
Бытбылдыклар белән ярыша.
Тәкәрлекләр генә уйсулыкта,
Бер-берсеннән сәлам алыша.

Тик бакалар гына һаман шулай –
Кубыз тарта язгы күлләрдә.

Чикерткәләр генә һаман шулай –
Пычак кайрый җәйге көннәрдә.
2004

**Давылдан калган тал**

Юл буенда үскән шушы талга
Гаҗәпләнми калмый һичберкем.
Шулкадәрле гарип гәүдә белән
Ничек яши, диләр, бу мескен.

Ә ул исә яши генә түгел,
Шатлык сибә кеше күзенә.
Мең чыбыктан чыккан яфраклардан
Яшел чатыр корган үзенә.

Ун ел элек моннан давыл үткән...
Күкрәп үскән биек бу талның
Ботаклары белән ярты сынын
Умырып алып киткән ул давыл.

Шул давылдан калган ярты гәүдә
Эче тоташ куыш булса да,
Һаман яши, үзенең бар көүсәсе
Тик кабыктан гына торса да.

Тамырлары исән, тамырлары...
Тамырлары барда ул яшәр.
Алар җирдән татлы ширбәт эчәр,
Күктән кояш:”Нихәл!” – дип дәшәр.

Бер могҗиза булып яши бу тал,
Шатлык чәчеп кеше күзенә.

Гариплеген яшереп, матур булып,
Яшел чатыр корып үзенә.
2004

**Һиндыба**

Умырзая сулгач, сукмагымда
Калкып чыга яңа бер чәчәк,
Җәйләр буе зәңгәрләнеп балкый,
Кара күзләрдә дә нур чәчә.

Кара күзләрдә дә коелмый ул
Кыр чәчәге - кыргый һиндыба.
Такыялар үреп булмый аннан,
Өздең исә - шундук йомыла.

Әни белән кура җыйган чакта,
Сугыштан соң кара көзләрдә
Ул иде бит безгә елмаючы
Күз яшьләрен корытып күзләрдән.

Мин дә яшәр идем аның кебек
Картайгач та яшьтәй нурланып,
Кара көземдә дә кешеләргә
Бер ямь биреп, ихлас елмаеп.
2004

**Мин мәҗүси түгел...**

Мин мәҗүси түгел, тик шулай да,
Төнлә Коръән укып ятсам да,
Чыгып басам Кояш каршыларга,
Сызылып-сызылып таңнар атканда.
Балбал кебек тып-тын басып торам,

Таңга куеп ике битемне.
Бу вакытта мин үземне тоям
Нәкъ борынгы бабам шикелле.
Әнә чыгып килә алтын Кояш –
Аллаһының бөек кодрәте.
Җаным-тәнем нурлар белән тула,
Ачыла шунда Тарих сурәте:
Гүя Тарих минем белән бергә -
Сөннәр, һуннар, болгар бабамнар,
Минем артта тигез сафлар булып,
Чал даланы иңләп басканнар.
Миңа рәхәт шушы иркенлектә,
Чал гасырлар монда берләшә,
Ал кояшның җылы нурларында
Үз кавемем белән серләшәм.
Кояш безне назлап кавыштыра,
Кояш безгә карап шатлана,
Кояш безнең гадел шаһитебез,
Тарихыбыз итә тантана.
Мин мәҗүси түгел, тик шулай да,
Төнлә Коърән укып ятсам да,
Чыгып басам Кояш каршыларга,
Сызылып-сызылып таңнар атканда.
2004

## **Мин бит Мулла Иле баласы**

***Мулла Иле авылы булсын да,***
***Коммунистлар динле булмасын.***
***Мулла Иленең һәрбер коммунисты***
***Алмашырлык авыл мулласын.***

***Һади Такташ***

Манаралар киселеп ауган чорда,
Такташ килеп безнең авылга
Әнә шундый шигырь язып киткән,
Чынбарлыкны тоеп тамырдан.

Мин үзем дә Мулла Иленең бер
Коммунисты булып яшәдем.
Тик шулай да, явыз Иблис булып,
Дингә кршы ләгънәт чәчмәдем.

“Син коммунист идең, инде хәзер
Коръән укып йөргән буласың” –
Кемдер миңа шулай нәфрәт ора,
Сүзе дөрес, нихәл кыласың.

Әйе, әйе, ерак яшьлегемдә,
Мин фиркагә кердем атлыгып,
“Коммун” сүзендә мин күрдем фәкать
Бергә тигез яшәү шатлыгын.

Кемдер димләп түгел, үзем теләп
Мин фиркагә кердем ашкынып,
Данга сусап түгел, кешеләргә
Эшләргә дип күбрәк яхшылык.

Һич үкенмим, шул фиркадә торып,
Мин мәгърифәт нурын тараттым,
Һәр дәрескә кердем иман белән,
Һәр баланы тигез яраттым.

“Коммун” сүзе минем өчен мәңге
“Бергә тигез яшәү” була гел.
Шушы изге сүзгә ышыкланган
Алдакчылар миңа иш түгел.
2004

**Мин яшимен Тукай дөньясында**

Мин яшимен Тукай дөньясында,
Монда патша – кодрәтле үзаң!
Монафикълык монда керә алмый,
Сакчылары – Намус һәм Вөждан.
Мин яшимен Тукай дөньясында,
Күп кирәкми миңа: татарым
Татар булып иркен суласын да
Мәңге булсын азат Ватаным.
Мин яшимен Тукай дөньясында,
Мин нәфесле түгел: милләтем
Үз тарихын бары онытмасын
Һәм җуймасын динен, өммәтен.
Мин яшимен Тукай дөньясында,
Бу дөньяда әгәр һәр татар
Үзен үзе сөеп олылаcard,
Ватан үзен яклар һәм саклар.
Мин яшимен Тукай дөньясында,
Тоеп читтән күпме каршылык.
Һәрбер татар үз теленә гашыйк
Көннәр җиткән чакка ашкынып.
2004

**Көрәшчегә**

*(Динар Хәлиловка)*

Татар халкы борын-борынгыдан
Дан җырлаган батыр ирләргә.
Батыр ирләр тулы сабантуйлар
Гөрләп торган безнең җирләрдә.

Батырларның батырлары булып,
Хәлиловлар тоткан мәданны.
Динар атлы улы бөтен илгә

Алып киткән ошбу зур данны.

Бу нәселнең гаярь җегәрлеген
Ул күрсәткән шәһри Казанда,
Егып салган филдәй батырларны,
Ул дан алган хәтта Германда.

Мулла Иле дигән безнең җирне
Ул таныткан ерак-еракка.
Чемпионнар чемпионы булып,
Җиңү яулап барган һәр чакта.

Ул бүген дә горур һәм мәһабәт,
Батырларның данлы остазы.
Ул барында сүнмәс көрәш дәрте,
Ул яшьләрнең дусты, юлдашы.

И яшь батыр, син егетлек күрсәт илгә,
Динар абый кебек бәйлә сөлге билгә.

Чык мәйданга тәвәккәлләп, нык-нык басып,
Дәртләрең һәм дәрманнарың торсын ташып.

Тимер тәнле, корыч рухлы ул батырның
Көрәшкәнен безнең халык онытырмы?!

Батырларның батыры ул, тыйнак батыр,
Ул барында безнең шөһрәт һаман артыр,
Көрәш дәртен бөтен җиргә ул таратыр.

Чык мәйданга Динар батыр кебек балкып,
Карашыңнан чынлык-хаклык торсын аңкып.

Тот сөлгене Динар батыр кебек ипләп,
Көндәшең кул бирсен сиңа үзе теләп!

Яшәсен чын милли көрәш, милли бәйрәм,
Дөнья безгә гаҗәпләнсен, калсын хәйран!
2004

## Барлык килештә төрләнә Казан

Килде, ниһаять, шундый бер заман:
Барлык килештә төрләнә Казан.

Көндәш илләрен узып базарның,
Товары ерак китә Казанның.

Хаклык табалмый гаҗиз калганда,
Килә татарлар, килә Казанга.

Татар җан атып тыңлый азанны –
Мең ел изге моң урый Казанны.

Ак нур бөркелә егет-кызлардан –
Мәгърифәт иңә изге Казаннан.

Татарлык рухы сүнмәс кайчан да,
Ул яшәр мәңге нурлы Казанда.
2005

## Җыр турында баллада

Бөтен җирдә дә - урман-кырларда,

Дәрья-сулардңа, таулы юлларда –
Яңгырый һаман мөкатдәс җырлар,
Тезелеп үтә айлар һәм еллар.

Яңгырый һаман Җәлил җырлары,
Көрәшкә дәшеп җирнең улларын.
Җир тыныч түгел, җирдә - азгынлык,
Вәхшиләр йөри улап, ажгырып.

Кансызлык тулы җирнең бар ягы,
Гүя мәрхәмәт, хаклык байрагы –
Җирнең өстендә Җәлил җырлары
Тирбәтеп үтә йөрәк кылларын.

Ул җырлар туган үлем каршында –
Фашист күтәргән балта астында.
Шагыйрь йөрәге, шагыйрь ялкыны,
Шагыйрь хисләре, шагыйрь акылы,

Соңгы минутта башын чапканда
Әверелгәннәр мәңгелек җанга.
Мең үлем аша, таш капчык аша,
Гитлерны җиңеп, очкан Ватанга.

Тыңла, бар дөнья, ишет, Кешелек,
Тор син тарихны искә төшереп.
Ник болай ярсый Җәлил җырлары?
Нигә тартыла йөрәк кыллары?

Әй сез, кешеләр, намус коллары,
Җирнең акыллы, гадел уллары,
Берләшеп бергә гигант хор белән
Җырлагыз әйдә хаклык җырларын –
Көйләгез батыр татар моңнарын.

Күмәк җырлаудан тусын шундый көч:
Явызлар бетсен, кайтсын безнең үч.
Бөек Җәлилнең рухы шат булсын,
Газиз халкымның йөзе яктырсын.
2005

**Мәхәббәт рифмалары**

Рифмаларга бай син, мәхәббәт!
Хәтта Хәдичә һәм Мөхәммәт
Укыганнар сиңа мең рәхмәт,
Бер-берсенә кылып мәрхәмәт.

Рифмаларга бай син, мәхәббәт!
Синең хакта язу бик рәхәт.
Тик сөюдә - иң чын сәгадәт,
Тик сөюдә иңә бәрәкәт.

Рифмаларга бай син, мәхәббәт,
Калкып чыга Ширин һәм Фәрһәд:
Бу мәхәббәт – нинди мәһабәт,
Барлык заман хуплар: мәрхәбә!

Мәхәббәткә итсәң хыянәт,
Йөрәк булыр тоташ җәрәхәт:
Һәм уятыр шунда мең нәфрәт,
Ямьсезләнеп калыр мәмләкәт.

Син кабынсаң җанда, мәхәббәт,
Матур була хәтта сурәбәт.
Бөтен дөнья балкый, вәт әйбәт,
Җирне саклап тора бу халәт.

Мәҗнүн һич тә булмый хәшәрәт,

Ләйлә итә аны мөбарәк.
Уйларында яна мең гайбәт,
Синдә шундый гаҗәп көч-гайрәт.

Зөләйхада янган мәхәббәт.
Йосыфында кала ул фәкать.
Картлыкта да сүнми гүзәл дәрт,
Шатлык белән көтәр кыямәт.

Адәм белән Һава тәү нәүбәт
Кичерделәр сине, мәхәббәт.
Синең хакка калды бу җәннәт,
Оҗмахтагы хурлар һәм ләззәт.

Иблис үчле сиңа, мәхәббәт,
Шайтаннарга төшсен мең ләгънәт!
Аздырмакчы безне һәр сәгать,
Әй, алданып булмыйк һәлакәт.
2005

**Җиңү бәйрәме**

Безнең әтиләрне ил зурлады:
Онытмаска теләп беркемне,
Сугыш бетеп егерме ел үткәч,
Үлгәннәрне барлап беркөнне,
Колхоз рәисләрен аптыратып,
Клуб янындагы бер читтә
Төзеттеләр ыгы-зыгы килеп,
Һәйкәлсыман сәер бер хикмәт.
“Мәңгелек дан!” дигән сүз астында
Исемнәре ташка чукылды.
Әнине һәм мине шунда чакырып,
Күпме түрә доклад укыды.
Хисап тотты рәис һәйкәл өчен

Күпме таш, ком, цемент киткәнен.
Сезнең өчен болар барсы да дип,
Ул күрсәтте тырыш икәнен.
Без кул чаптык, күз яшьләрен яшереп,
(Йөрәкләр бит барыбер әрниләр).
Доклад тыңлый-тыңлый үтте еллар...
Гүр иясе булды әниләр...
Үлгәннәрнең калган балалары
Бабай булды инде барсы да.
Алтмыш еллык бәйрәм иртәсендә
Алар тагын һәйкәл каршында.
Дәшми генә доклад тыңлый алар,
Юк, аларны беркем барламый,
Ил әлегә белми исәннәрен,
Үзләре дә дәшми, зарланмый.
Ил бүгенгә күңел хакы өчен
(ни күрсәтер, белмим, киләчәк)
Алтмыш елга фәкать  бер мәртәбә
Бирә алмый безгә бер бүләк
(Нәни генә гади бер чәчәк).
2005

**Гел яшь калсын, яшел торсын Милли Үзән**

Мең-мең шөкер, раббым, “Яшел Үзән” яши!
Ташка басылып, саф татарча сүзләр яши!
Яши Әрә, яши Зөя, яши Идел –
Туган җирсез, туган телсез нишләр идем?!

Яшел шавың белән шаула, Милли Үзән!
Чәчәкләрең нинди нәфис, нинди гүзәл!
Үз җиремдә үз телемдә чәч мәгърифәт!
Кыю дуслар, барыгызга мең-мең рәхмәт!
2006

**Мин дә битлек киям**

Мин дә битлек киям, усалларга
Усал күренер өчен тышымнан.
Елмаерга торган йөрәгемне
Күрмәсеннәр өчен тырышам.

Юаш битлек, күндәм битлек кимим,
Садә битлек миңа кирәкми.
Алар тумыштан ук үз битемдә,
Усал битлек саклый йөрәкне.
2006

**Иртәнге дога**

Шундый хозур, җиңел мәлдә,
Таң яктысы җәелгәндә,
Мин уяндым янә тагын,
Мең-мең шөкер сиңа, Раббым.
Саф су бөркеп, пакьлим тәнем,
Кул-аяклар сихәт таба,
Басам карап кыйбла таба,
Ризалыгың өчен, Тәңрем,
Укыйм намаз: кылам рокуг,
Китеп барам сәҗдәләргә.
Акыл вә тән, фикер вә рух
Биргәнсең, хак, бәндәләргә.
Сәлам бирәм мәләкләргә
Илаһи тел – гарәбидә,
Укыйм Коръән, Иман нуры
Әйләнәмдә - бөтен җирдә.
Чын күңелемнән укыйм Корьән,
Аның әҗер савапларын
Ирештерче бабамнарның

Рухларына, Хак Тәгаләм.
Киң рәхмәтең белән, Ходам,
Кабуллардан кылгыл догам!
Мәрхәмәт кыл кавемемә,
Тәүфикълар бир җаннарына,
Юл ач татар моңнарына,
Чишмәләрдәй саф телемә.
Коткар, Ходам, татарымны,
Аермагыл Иманыңнан.
Җирдәге һәр кеше җанын
Яраткансың үз нурыңнан.
Күп кавемнәр яраттың син.
Изгеләрен яраттың син.
Һәлак иттең азгыннарын –
Тугры юлдан язганнарын.
И Ходаем, калебемне
Иман нурың белән пакьлә,
Татар дигән кавемемне
Кыяматкә кадәр сакла.
Кичер безне, татарларны –
Сөннәр, Һуннар, болгарларны –
Надан-җаһил чагында без
Кояшыңа табынганбыз.
Кавемемне Син саклаучы,
Кавемемне Син яклаучы,
Инкыйразга кылма ирек,
Ватаныма бир иминлек!

Дога кылам мин ялварып,
Аллам, Синнән ярдәм сорап,
Шөкер, кылдың безне мөэмин,
Иман нуры белән нурлап.
Сине зурлап, тартам тәсбих,
Сәлам бирәм мәләкләргә.
Хак Рәсүлең пәйгамбәргә

Салаватлар ирештергел.
2006

**Әрәләр, әрәмәләр**

Әрәмгә түнгән үзәннәр –
Әрәләр, әрәмәләр.
Сугарган чорлардан калган
Торбалар, хәрабәләр.

Джунгли күк чытырманлык,
Кыргый сәер хөррият.
Кем уйлаган бу хикмәтне –
Бармы яшерен бер ният.

Кайда җәйрәп яткан болын,
Печәннең билдән чагы?
Тын иртәләр сафлыгында
Чыжламый нигә чалгы?

Җәйне яшереп куя идек
Меңләгән кибәннәргә.
Мең баш терлек утлап йөрде
Бу уйсу үзәннәрдә...
2006

**Коръәнгә иярүләр**

(А.Пушкиннан тәрҗемә)

VII

Мәгарәңдә таңга чаклы
Изге ут яна.

Күндәм колым – пәйгамбәрем,
Укы, йоклама.

Изге догаларың белән
Ку син йокыны,
Ку син дөнья кайгыларын,
Күңел шаукымын.

Укы таңга чаклы, колым,
Күкләр китабын,
Өйрәт газиз өммәтеңә
Догалар бабын.

VIII

Раббым, җирең нинди иркен,
Нинди биек күкләрең,
Гөмбәзләрең - бер тәрәүсез,
Иксез-чиксез кодрәтең.

Иксез-чиксез галәмнәрең,
Нурлар сибә кояшың.
Һәр бәндәне күрәсең син,
Һәр йөрәкне тоясың.

Син мәңге бар, мәңге тере,
Мәңгегә бер генәсең,
Бәндәңнәргә чилләләрдә
Яңгырлар китерәсең.

Син шәфкатьле: Мөхәммәткә
Күктән Коръән иңдердең.
Томаннарны йолып күздән,
Безгә иман иңдердең.
2006

**Өмәләрдә үтте яшьлек**

Өмәләрдә үтте яшьлек,
Хезмәт хаксыз да рәхәт:
Һәрбер йортның хуҗалары
Укыды безгә рәхмәт.

Өмәләрдә үтте яшьлек,
Атна саен – яңа йорт.
Гөрләп торды бөтен урам,
Хозурланып, яңарып.

Бүрәнәне бертуктаусыз
Без ташыдык Зөядән.
Зөя тулып килде саллар
Без белмәгән җирләрдән.

Салчылары,
Салчылары – мылтыклылар,
Ялт-йолт килә күзләре.
Яшел шәһәр “пиратлары” –
Кеше төсле үзләре.

Бүрәнәне ул пиратлар
Эләктерә Иделдә.
Ә үзләре эләкмичә
Хезмәт күрсәтә безгә.

Һәр килгән сал – бер ызбалык,
Кинәнә авыл халкы.
Рәхмәт әйтеп, акча бирә,
Пиратлар тора балкып.

Өч йөз йортны кордык шулай
Пиратлар ярдәмендә.

Район түрәләре килеп
Үткәрде бәйрәмен дә.

- Коммунизм авылы бу!
Диделәр семинарда.
Шундый үрнәк булдырдык дип,
Мактанды алар бар да.

(Ләкин йортка ярдәм сорап
Барып кара түрәгә.
Законлы рәвештә һич тә
Бирмәс сыңар бүрәнә).

Тып-тын чорга керде картлык,
Онытылды өмәләр.
Урам буйлап барам ялгыз.
Без куйган бүрәнәләр

Безнең кул җылысын саклап,
Моңаешып торалар.
Гөлләр тулы тәрәзәләр
Елмаешып калалар.

Карап кала миңа алар,
Ерак яшьлегем булып.
Картлыгым йөри урамда,
Бер ялгызы каңгырып.
2006

**Узган гомерләргә - салават!**

*Ә шулай да, һаман хыялланып,*
*Сөям сине, сөям акылсыз!*
*Һәм сөярмен шулай мәңге янып,*
*Поэзия атлы матур кыз.*

*Ш. Маннур*

**Күңелемә сеңгән әкият**

Әбелхәят суын табармын күк,
Мәңгелекнең утын ягармын күк,
Камыр батыр кебек әгәр дә
Чыгып китсәм ерак сәфәргә.

Бу ни хикмәт икән – җиде яшьтә
Күңеләмә сеңгән әкият
Җитмештә дә минем белән яши,
Гүя җанга сеңгән ахирәт.

Бу ни хикмәт икән – югыйсә бит
Күпне күрдем гомер эчендә,
Ә ул һаман бер могҗиза булып
Кала бирә үзе төсендә.

Борын-борын замандагы кебек
Урман уртасында әле дә
Бер убырлы карчык яшәп яткан
Ул йорт тора шул ук хәлендә.

Әбелхәят суын табармын күк,
Мәңгелекнең утын ягармын күк,
Камыр батыр кебек әгәр дә
Чыгып китсәм ерак сәфәргә.
2006

**Бәхет эзләп чаптым гомрем буе**

Бәхет эзләп чаптым гомрем буе,
Ә ул
Куып җиттем дигән чакта һаман
Кача торды миннән алга табан.

Инде белдем:

Бәхтем минем – аны куудадыр.

---

Мин эзләүгә бирдем гомеремне,

Ә табуны калдырам улларыма.

2006

**Әти**

Гомеремнең ерак таңнарыннан

Биш яшьлегем калган хәтердә.

Мин әнигә ияреп кырга барган,

Көн кызуы инде сүрелгән.

Камыл ерткан канлы куллар белән

Арыш ура иелеп әниләр.

Кайчан гына урып бетерерләр,

Кояш байганын да күрмиләр.

Кояш инде әнә баеп бара,

Шәфәкъ кызыл - нәкъ кан шикелле.

Күктә бомба төяп шул якларга

Самолётлар китә үкереп.

Офыкларның теге якларында

Сугыш бара – безгә бик якын.

Бик куркыныч: офыкларны ярып,

Фашист килеп чыгар кебек,

Чәнчер кебек мине, әнине.

Офыкларның теге якларында

Минем әти йөри сугышта.

Хат язарга аның вакыты юк,

Ут яудыра әти фашистка.

Ә әниләр һаман урак ура,

Бармаклары тоташ кан гына.
Кояш баткан инде, чыклар төшкән,
Төн пәрдәсе төшә тын гына.

Кинәт шунда хат ташучы килеп,
Әнине чакырып бирде бер язу.
Шуны укып, әни катып калды,
Аннан коелып төште камылга.

Шуннан хәлсез канлы кулы белән
Кочагына мине кысты да:
“Атаң хәбәрсез югалган бит,” – дип,
Сулкылдады тын күк астында.

Ә мин әле берни аңламадым.
Минем әти ничек югалсын!
Ул окопта гына утырадыр,
Күрми калганнардыр югартын.

Мин әнине шулай юаттым.
Бик күп еллар үтте.
Мин көн саен,
Кояш баеганда кызарып,
Офыкларга карыйм.
Кичке шәфәкъләрдән
Берәр хәбәр көтәм зарыгып.

Шәфәкъләрдән әти кайтыр кебек,
Батырлык бит җирдә югалмый.
Батырларның рухы мәңге яши,
Яктырта ул безнең юлларны.

Әти – солдат һаман егермөчтә –
Сагынган ул мине ничаклы.
Тыелгысыз күрешү шатлыгыннан

Кысып-кысып мине кочаклый.

- Без үлмибез, улым, без яшибез,
Һәр гасырдан яшәү даулыйбыз.
Без КамАЗлар булып юл йөрибез,
Без башаклар булып шаулыйбыз.

Безнең батырлыкны дөнья белә,
Йолдызлардан килгән нурлардай
Буыннардан буыннарга таба
Килеп торыр бездән хәбәрләр.

Гомеремнең ерак таңнарыннан
Биш яшьлегем һаман хәтердә.
Югалган бер табылыр дигән өмет
Үзем белән бара кабергә.
2006

**Ак юл сезгә**

Бүген мәктәп әйтерсең лә мәгърур кораб,
Аллы-гөлле нурлы офыкларга карап,
Сәфәр чыга белем дигән зур дәрьяга –
Ак юл сезгә, яшь дусларым, ак юл сезгә.

Кояш һаман бүгенгедәй балкып торсын,
Бәхетегез көннән- көнгә артып торсын,
Хәвеф-хәтәр кичермәгез берегез дә,
Ак юл сезгә, яшь дусларым, ак юл сезгә.
2006

*****

Үземә дә, кешегә дә
Бер дә ошап бетмәсә дә,
Сакал-мыек үстердем мин,
Максат куеп бернәрсәгә:

Үземә дә, кешегә дә
Күренеп торсын картайганым,
Ак сакалым – казганганым,
Яшәп җыйган бар байлыгым.

Күпме картлар сакалының
Ниндилеген күрми кала.
Яшьлек юләрлеге белән
Акыл керми китеп бара.
2006

*****

Майның әле бары башы гына,
Бер кырау да әле булмаган.
Төнгә  каршы кыз клубка ашыга –
Үндүрте дә әле тулмаган.

Майның әле бары башы гына,
Бер кырау да әле булмаган.
Ә алмагач инде шау чәчәктә -
Вакытым җитсен диеп тормаган.

Вакыт җитми аткан чәчәкләрне

Саклау килә безнең куллардан.
Үндүрте дә әле тулмаганны
Сакла, Ходай, үзең кыраудан.
2006

**Холкым**

Ишетсәм сүз – җанга ярамаган,
Тыелгысыз ачу кайный миндә.
Үрсәләнәм, тәнем кызулана,
Кайнар каннар ага шаулап мидә.

Вакыт агып узгач тәнем аша,
Юылып төшә барлык ачуларым,
Кайтам кабат рәхәт халәтемә,
Онытыла һәм юк була борчуларым.
2006

**Бәя**

Мин озынмы, әллә тәбәнәкме?
Янда башка кеше юкта мин
Һәм озын да, һәм дә тәбәнәк тә -
Үз-үземә каршылыкта мин.

Янда кеше булган чакта гына
Үз бәямнең күрәм мин чынын:
Янда озын барда мин – тәбәнәк,
Кыска барда инде мин – озын.
2006

**Тагын килде язлар**

Тагын килде язлар, тагын йөрәк

Унсигездә кебек талпына.
Тагын чыктым егет чакта йөргән
Әрәмәле Әрә артына.

Бар табигать монда элеккечә,
Шул ук күпер, шул ук ылыслар,
Күктә шул ук тулы ай елмая,
Күз кысыша шул ук йолдызлар.

Яз нишлисен белми: кичке җылы
Битләремнән үбеп шатлана.
Яз сулышын өргән каеннарда
Минем хатирәләр саклана.

Бар иде бит монда тамашалар,
Кадерен белгән чаклар язларның!
Яңгырап тора иде тавышлары
Йөзәрләгән егет-кызларның.

Тальяннарның көмеш чыңлаулары
Йолдызларга хәтле үрелә,
“Зәлилә”дә җырлап әйләнүдән
Нурлар тула күңел түренә.

Хәзер исә заманалар башка:
Бер кеше юк: тып-тын әрәмә,
Шундый гүзәл язгы шигъри төндә
Ай нурларын түгә әрәмгә.

Бер ялгызым йөрим моңсуланып
“Зәлидә”сез Әрә артында.
Заман агышын белми торган йөрәк
Унсигездә кебек талпына.
2007

******

Ап-ак чәчләр, ап-ак сакал –
“Аллаһ нуры” дигән хәдистә,
Ап-ак күңел белән кешеләрне
Сөендерсәм иде һәр эштә.
Язсын иде күбрәк яхшылыгым
Уңъяк иңемдәге фәрештә.

*****

Инде гомер үтеп бара.
Ә мин әле
Чытырманнар ерып
Чыктым гына
Үзем эзләгән кояшлы аланга.

*******

Мин көн саен, белә торып,
Үземә авыр алам.
Я кемнедер яклап чыгам,
Кемгәдер каршы барам.

*******

Үз хатының белән айлар буе
Сүз кушмыйча йөргәч, и татар,
Читләргә бер чакрымнан биргән
Сәламеңнән килгән ни соң бар?

*******

Яхшы эшләреңне яман итеп
Чәйнәсәләр көфер почмагында,

Аларга юл куйма сөенергә -
Изгелегең арттыр син тагын да.

*****

Кеше барда – син нәкъ артист –
Гел уйныйсың уңай рольдә.
Кеше юкта – нәкъ үзең син –
Уңай ягың юктыр бер дә.

*****

Кеше сиңа көлеп килгәндә,
Кырын басып, читкә карама.
Бәлки үзең елап килерсең,
Постың мәңгелек дип юрама.

*****

Мин пәйгамбәр түгел, гади зат дип
Гөнаһларны аклау кирәкме?
Һәр гади зат булсын пәйгамбәрдәй –
Ак күңелле керсез йөрәкле.
2007

**Мулла Иленә**

Кешеләрнең иң-иң гүзәлләрен
Үзенә туплап яши алганга,
Мулла Иле үсә, матурлана
Һәм яшәрә бара һаман да.
Дастан булып күтәрелә авылым,
Еракларга сибелә нурлары.

Монда бит ул, монда алмаларның
Эрмекләнеп пешә торганы.
Бик борынгы безнең тарихыбыз,
Юк, югалмас безнең хәтерләр –
Вәисиләр рухын мәңгелеккә
Саклый авыл, саклый кадерләп.
Килегез сез безгә һәр фасылда,
Кунакларга бездә зур хөрмәт.
И авылым, газиз Мулла Илем,
Гомеремнең моңлы җыры син.
Гомеремне шау чәчәкле итте
Халкың күңеленең җылысы.
Рәхмәт сиңа, газиз Мулла Илем,
Канаткуеп мине очырдың
Тормыш дигән гаҗәп орбитага
Тиң кешесе итеп чорымның.
Күңелләрем әллә ниләр эзләп
Табалмыйча гаҗиз калганда,
Тыелгысыз бер ашкыну белән
Сиңа кайтам, авылым, һаман да.
Яратам мин сине, хезмәт белән
Дан казанган газиз Мулилем.
Кырларыңда сине сөюемә
Җавап булып үсә мул иген.
Ничә бабам рухы сеңгән
Борынгы бу туфракта.
Тамырларым тармакланып
Киткәннәр бик еракка.
Минем авылым өстендәге кояш
Ягымлырак яна, яктырак.
Һәр йортыннан бәхет карап тора,
Ел буена бездә яз тора.
Авылым, Мулилем,
Мул иген иккән җирем,
Гомерләрем йөзәү булса –

Гел сиңа бирер идем.

Тамырларым бик тирәндә -
Тоташкан гасырларга.
Бабамнарның сүнмәс моңы
Ургый безнең җырларда.

Кайтып төштем тагын сиңа,
И минем торган җирем,
Чәчләремнән, битләремнән
Иркәли йомшак җилең.

Хуш, авылым, китеп барам,
Сагышларга уралып.
Мин яшәрмен сине сагынып,
Җанга синнән нур алып.
2007

**Агачлар яфрак ярганда**

Агачлар яфрак ярганда
Мин катлаулы халәттә,
Гүя мин дә яфрак ярам
Алар белән беррәттән.

Күңелемдә яткан хисләр
Бәреп чыга дөньяга,
Ашкынамын әллә кая,
Омтыламын яңага.
2007

**Идрис Туктар урамында**

Йөрим Идрис Туктар урамында
Бер ялгызым йөрим моңаеп.
Яшел Үзән үз кайгысы белән

Тыз-быз килә, меңгә тулганып.
...Бер урамда хәсрәт белми торган
Бер кайгысыз Кеше яшәде.
Сиксәндә дә шутлык-мутлык белән
Көнләштерә иде яшьләрне.
Мут елмаю китмәс мыегының
Бөтергәләп нәфис очларын,
Урам тутырып мәзәк сөйли иде,
Күңел китә иде хушланып.
Йөри идек Картлык белән Яшьлек,
Бер баш өстен булып дөньядан,
Вак-төяккә исләр китми генә,
Туган кебек көн дә яңадан.
Аның күңеле,төпсез диңгез кебек,
Явызлыкның кара яшенен
Чоңгылына йотып яшереп килгән
Кешеләрдән, күздән яшереп.
Йөрим Идрис Туктар урамында,
Йөрим аның белән сөйләшеп.
Бер кайгысыз Кеше бар дөньяга
Йөри һаман шатлык өләшеп.
2007

**Тау ягы**

Гомер сөрәм Зөя үзәнендә -
Уйсулыкта яткан авылда.
Күләгәле таллар ышыгында
Тирбәләмен йомшак агымда.

Үзән генә, елга гына түгел,
Биргән безгә Ходай тавын да.
Тып-тын горур биеклеккә карап,
Көч алам мин хәлсез чагымда.

Мәңге үзгәрмәгән таулар мине
Ымсындырып үзенә чакыра.
Күтәреләм тиз-тиз менгән саен
Җир киңәя, дөньям яктыра.

Хәйран калып иркен киң үзәнгә,
Карап торам таулар башыннан.
Түбәнлектә күреп булмаганны
Күреп була фәкать шушыннан.

Нинди җирдә гомер кичерәм бит, әй!
Мондый авыл бар соң кайларда?!
Тыелгысыз бер ашкыну белән
Үзәнемә төшәм таулардан.
2007

**Сөям дип әйтергә ашыкма**

Сөям дип әйтергә ашыкма –
Син аңа әлегә дус кына,
Ул әле каядыр ашкына,
Бәхетең диңгезен ярсытма –
Сөям дип әйтергә ашыкма.

Син аңа әлегә дус кына –
Янында атлый ул янәшә,
Эчкерсез сөйләшә, серләшә,
Күзләрен кыскалый еш кына,
Син аңа әлегә дус кына.

Ул әле каядыр ашкына,
Урамда барганда ашыгып,
Ташларга абынса ялгышып,
Ул сиңа тотына шаркылдап...
Ул әле каядыр ашкына.

Бәхетең диңгезен ярсытма,
Мәхәббәт ялкыны кабыныр –
Ул күзләр гел сиңа табыныр,
Мондый чын дуслыкка таш атма,
Бәхетең диңгезен ярсытма.

Сөям дип әйтергә ашыкма,
Ул качар, китермәс яныңа,
Шик-шөбһә үрмәләр җаныңа.
Йөр бергә бәхеткә коенып,
Сөям дип әйтергә ашыкма.
2007

## Кара көз

Бигрәк озак торды бу кара көз,
Шыр ялангач ята декабрь.
Кайчан соң ул туңган бу кырларны
Ак юрганга төреп йоклатыр?!

Агачларның шәрә ботакларын
Кайчан сарыр җылы йомшак кар?!
Ачы җилдә әрнеп сыктап ята
Ачык җирдә мескен тамырлар.

Уҗымнарны кара кайгы баскан:
Бу язмыштан исән калырмы?
Илем белән зарыгып аклык көтәм,
Билгесезлек телә җанымны.
2007

## Без ирешик шундый бөеклеккә

Олуг патшалар да хаталанган,

Бөек шагыйрьләр дә ялгышкан.
Кайсы нәфесләнеп байлык җыйган,
Кайсы хәмер белән ярышкан.

Без, гадиләр, үзебез гөнаһларны
Алар исеме белән акламыйк.
Алар хаталарын кабатламыйк,
Алар ялгышларын ясамыйк –
Без ирешик шундый бөеклеккә.
2007

**Без ирешик шундый бөеклеккә**

Олуг патшалар да хаталанган,
Бөек шагыйрьләр дә ялгышкан.
Кайсы нәфесләнеп байлык җыйган,
Кайсы хәмер белән ярышкан.

Без, гадиләр, үзебез гөнаһларны
Алар исеме белән акламыйк.
Алар хаталарын кабатламыйк,
Алар ялгышларын ясамыйк –
Без ирешик шундый бөеклеккә.
2007

*******

Бар нәрсәне әйттем авыз тутырып,
Пышылдауны җенем сөймәде.
Моның өчен күпме газап чиктем,
Гомер үтте – тәүфыйк килмәде.

Бернәрсәм юк кешеләрдән яшерен,
Барлык серләремне тапшырам.
Төннәр кочагыннан сөенә-сәенә
Кеше арасына ашыгам.

Гомер узды шулай ачыклыкта,
Алны-артны уйлап тормыйча,
Төн пәрдәсен ябынып, үтә яшерен
Эшләр өчен җәтмә кормыйча.
2007

**Бу – мәхәббәт түгел**

Мең-мең кеше узган урамда син
Фәрештәдәй миңа бактың.
Якты күзләреңнән күңелемә
Сихри нурлар акты,
Шундый җылы җилләр исте –
Кайгыларым юылып төште.
Юк, бу – мәхәббәт,
гыйшык түгел,
Күзләреңдә саф йөрәгең.
Миңа баккан бу карашың –
Миңа биргән бер бүләгең.
Билгесез зат, рәхмәт бүләгеңә -
Бу илаһи матурлыктан
Мин дивана хәзер,
бер сәбәпсез
Гел елмаеп йөрим урамнарда.
2007

**Яшел Үзән гимны**

Урамнарың алып бара якты таңга,

Алда Казан нурлар сибә киң Ватанга.
Уңда сине, данга күмеп, Идел ага,
Сулда синңа моңнар тулы урман бага.

Идел җиле, урман шавы, рәхәт һава,
Ил күгеннән йортларыңа бәхет ява.
Бу бәхетне яуладың син зур хезмәттә,
Лаеклы син, Яшел Үзән, чын хөрмәткә.

Азмы койды батыр халкың ил калканын,
Яшәү өчен тынычлыкта гел шатланып.
Даның гизә һавларда аккошлардай
Йөрәкләрен үзең куйган очкычларда.

Корабларың урап кайта океаннардан –
Дөнья сине таный бүген әллә кайдан.
Татарстан матурлыгын гел арттырып,
Бөтен җиргә маяк булып тор яктырып.

Күтәрел син дастан булып, яшел кала,
Һәр милләткә яшел юллар сала-сала.
Горур Тукай басып торсын мәйданыңда,
Яңгырасын Сәйдәш җыры Һәрьягыңда.

Кушымта:
Елдан-ел яшәреп, яшә, Яшел Үзән,
Картларың, яшьләрең булсын мәңге гүзәл.
Кояшка үрелеп, елмай, шәһәр, елмай,
Иделләр гомерен бирсен сиңа Ходай.
Хөр бул син гомергә, мәңге хөрлек ярат,
Соклансын йолдызлар күктән сиңа карап.
2007

**Татар теле тыюлыгы**

Яшим дисәң татар мохитендә
Иркәләнеп туган телеңә,
Кил торырга безгә гомерлеккә
Минем гүзәл Мулла Иленә.

Бу бит – теле бер дә үзгәрмәгән,
Гел саф торган татар дәүләте.
Картларында борынгыдан килгән
Мәкльләрнең яши куәте.

Матур телнең рәхәт кочагында
Хозурланып үсә балалар.
Телебезне ерак киләчәккә
Шул балалар алып баралар.

Эфирлардан татар бетә бит дип
Зарлар ташып торган чагында
Без яшибез әле тыюлыкта
Уяу калып телнең сагында.

Санамагыз соңгы магиканга,
Шушы җирнең изге тынлыгы
Татар рухын җуймас гомерлеккә,
Гел сакланыр, үсәр һәм ныгыр.
2008

*****

Нишләр идең әгәр үлгәч бетәр булсаң,
Һич терелмәс туфрак булып китәр булсаң,
Бер мәгънәсе булмас иде бу яшәүнең,
Чарасызлык биләр иде бар яшьләрне.

Мең-мең шөкер, Ходай безгә мәрхәмәтле,
Һич калдырмыйк Аллаһыга гыйбадәтне,
Үлгәннән соң биргән безгә терелүне,
Кыямәттә бездән җавап бирелүне.
Биргән безгә ахырзаман, кыямәтне,
Шундый татлы, чиксез бөек хак нигъмәтне.
2008

**Ләйлә белән Мәҗнүн**

Берсен-берсе өзелеп сөя-сөя
Чәчләренә чаллар керсә дә,
Ләйлә белән Мәҗнүн, Сак-Сок кебек,
Һаман ялгыз – сәбәп нәрсәдә?

Уналтыга кәдәр ике яшьне
Бергә йөртте авыл кочагы.
Һәм Ләйләне, Мәҗнүненнән аерып,
Тартып алды шәһәр почмагы.

Авылына кире кайтмас итеп
Сихерләде шәһәр Ләйләне:
Мәхәббәтен йөрәгенә бикләп,
Заманга тиң чиргә бәйләде.

”Рәхәт яшәү – мәхәббәттән өстен,
Сүнәр-бетәр бу уй бервакыт”.
Мәҗнүн килсә - кыз бәхетен куа,
Төнен елый ялгыз капланып.

Мәҗнүн йөри авыл урамында,
Төннәр буе ялгыз каңгырап.
Көндезләрен, бер юаныч итеп,
Гөрелдәтә “корыч айгырын”.

Берсен-берсе мәңге сөяр алар,
Ләйлә генә кайтмас шәһәрдән,
Мәҗнүн һаман саклар үз нигезен,
Без дә гаҗиз ошбу хәлләрдән.

Башкаларны алар сөя алмас,
Чөнки алар
Ләйлә-Мәҗнүн булып туганнар.
Кабергәчә тугры бу сөюгә
Ничек ярдәм итик, туганнар?
2008

*****

И нәфис кар бөртекләре!
Иңли-иңли киң күкләрне,
Озак-озак агылгансыз,
Алҗыгансыз, арыгансыз.

Төшегез, төш, әйдә җиргә,
Ял итегез бергә-бергә,
Бизәп илнең киң кырларын,
И сез, рәхмәт яугырлары.

Язлар җиткәч уянырсыз,
Дәрьяларга юлланырсыз.
Кабат кышлар килер безгә -
Сез кайтырсыз җиребезгә.
2008

## Узган гомерләргә - салават!

Узган гомерләргә - салават!
Әүлияләр булып булмады,
Әллә кызлар сөзеп карады,
Әүлияләр булып булмады.

Җәйге күкрәүләргә - салават!
Күктә аллы-гөлле көянтә
Зөяләргә төште бөгелеп –
Тотмак булдым тиз-тиз йөгереп...
Матур иде шул ул бигрәк тә.
2008

## Картайдым дип

Картайдым дип тып-тын яши башлыйм гына,
Шундук чик куела рәхәт тынлыгыма:
“Әле монда без бар!” – ди-ди, шау-гөр килеп,
Мыштым гына, посып кына, яшеренеп,
Йөрәгемдә йоклап яткан җирләреннән
Килеп чыга балачагым һәм яшьлегем.
2008

## Мин мөселман була торып

Кичер, Ходай, мин мөселман була торып,
Пушкинны да өзелеп яратамын,
Христиан икәнлеген белә торып;
Евтушенко өчен җан атамын,
Аның яһүд икәнлеген белә торып.;
Һотене дә шулай бик сөямен,
Ул католик икәнлеген белә торып;
Тагорга да сөеп баш иямен,

Буддист икәнлеген белә торып.
Бит аларга бу кодрәтне үзең биргән,
Миһербанлык бу дөньяга Синнән иңгән.
Сиңа гына сыгынамын шайтаннардан,
Белә торып язмам бердәнбер хак диннән.
2008

**Гафу әйлә, әдәби тел**

Гафу әйлә, әдәби тел,
Сине шундый яхшы белә торып.
Капка төбендәге эңгердә
Мин сөйләшәм авылым телендә.
Шундый рәхәт монда –
Әби-бабамнардан калган
Сүзләр дәрьясында.
2008

**Яшьлектә кунакта**

Күңелләрем әллә ниләр эзләп
Табалмыйча газиз калганда,
Ашкынулы хисләр канатында
Мин Казанга барам, Казанга.

Эзләп табам монда яшьлегемне
Колонналы гыйлем йортында:
Иркәләнәм фәннәр кочагында,
Дөрләп янам сөю утында.

Монда дөнья гел яшьлектән тора,
Яңа кызлар, яңа егетләр
Безнең яшьлекләрне кабатлыйлар,
Тик үзләре чит, ят кебекләр.

Яшьлегемнән кинәт айнып китәм,
Бик җиңел дә миңа, авыр да.
Әллә нинди сусау, җирсү белән
Мин авылга кайтам, авылга.
2008

**Хөр бул, Рәсәй!**

*Иң бөек максат безем:*
*Хөр мәмләкәт, хөр Русия!*
*Г.Тукай*

Хөр бул, Рәсәй, нәкъ Тукайча хөр бул,
Шуны тели һәрбер татарың.
Хөрлек барда гына чәчәк атар
Халыкларның уртак Ватаны.

Һәр төбәктә синдә татарлык бар:
Кар диңгезе – ерак төньякта,
Көнчыгышта татар диңгезе бар,
Каф тавы бар яулы көньякта.

Бер бөек зат юкка әйтмәгәндер
Чын тарихка саклап тугрылык:
Кайсы русны ярып карасаң да
Татар каны чыгар ургылып.

Уртак Ватан бергә төзегәнбез,
Саклаганбыз уртак дошманнан.
Шулай булгач, гүзәл татар теле
Ватан теле әллә кайчаннан.

Бөтенесе милли, чын татарча:
Байкал, Урал, Уфа, Казаннар...
Һәр төбәктә урыс белән бергә
Сайрашучы минем татар бар.

Чын дөресе ничә миллиондыр,
Тукай әйткән әнә - егерме.
Санап бетергсез булган чакта
Инкыйразлар безгә килерме?

Бу бүленмәс , бердәм Русиядә
Татарлар да бердәм, бүленмәс.
Җир-су уртак икән, Ватан уртак,
Хакыбыз бар, хаклык җиңелмәс.

Үз төсендә балкып торсын милләт,
Уртак күктә әнә һәр йолдыз.
Эресе дә, хәтта бик вагы да
Бик дустанә яна ызгышсыз.

Тукай хыяллары чынга ашсын,
Мәскәү торсын хөрлек сагында.
Бар милләтне тигез яратып, ул
Үстерсен чын дуслык багында.

Һәр төбәкне Мәскәү күзләп торсын,
Яхшы яшиме дип татарлар,
Милли аңны чәчәк аттырырга
Җитәме дип ирек һәм шартлар.
2008

**Бер шагыйрьнең кабер ташына**

Бу кабердә йоклый мәшһүр шагыйрь
Формаҗанов Рифма улы Заһир.

(Чынлыкта ул Заһир түгел дә бит,
Шагыйрь белән рифмалашмый Хәмит.)

*****

Гомеремнең фирүзәдәй күкләрендә
Яшьлегемне йолдыз итеп кабыздым да
Еллар белән бик еракка китеп бардым...
Шул йолдыздан менә хәзер картлыгыма
Бертуктаусыз җылы нурлар явып тора.

*****

Урак, урак! Калдың нинди ерак!
Кайрак утларында тешәлеп,
Арыш басуларын чыктың урап...
Моңлы, зарлы безнең истәлек
Басуларда ята түшәлеп.
2009

**Татар теле диңгезенә чумып**

Татар теле дәрьясына чумып,
Энҗеләрен җыйдым иң төптәге
Һәм аларны шәкертләргә бирдем,
Бизәсеннәр дидем ил күкләрен.

Тикшердем мин көн-төн тау-тау дәфтәр,
Ак битләрдә калды кызыл карам.
Шәкертләрем күңелендә хәзер
Дөреслеккә юл күрсәтеп барам.
2009

**Соңгы юлга озаткач**

Ялгыз картка котылгысыз вакыт җитте:
Раббысының хозурына чыгып китте.
Дөньядагы йорты ятим, буп-буш калды,
Һәр тарафны битараф бер тынлык сарды.
Ачык тора шып-шыр булып мескен капка,
Песи генә көтеп тора: тизме кайта?
2009

*****

Суык кышның салкын тын таңында
Мин яратам терлек карыйсын.
Рәхәтләнеп сулыйм шул чагында
Печән исе катыш кар исен.

Зәңгәр аклык сипкән кар яктысы
Күзләремне рәхәт иркәли.
Аяк табанымда карлар җырлый,
Котлы булсын яңа иртә дип.

Мин киткәч тә булсын кар тавышы,
Кар яктысы һәм дә кар исе.
Мәңге булсын бөтен иртәләрдә
Рәхәтләнеп терлек карыйсы.
2009

*********

Фани җирнең төрле җирләреннән –
Эреле-ваклы бөтен илләреннән
Җыйналганнар бөтен уенчылар,
Урнашканнар әкияти зур сәхнәгә.
Кешелек уйлап тапкан

Бөтен уен кораллары белән
Фонтастик оркестр
Бер-бер артлы
Төрле кавемнәрнең моңын суза.
Бу дөнҗья нинди гүзәл, нинди бай:
Аһәңнәрнең бииһая төрлелеге
Күңелләрнең әллә кайлардагы
Йоклап яткан хисләрен уята.
И Ходай! Яраткансың бәндәләрне
Кавем-кавем итеп. Бер кавем
дә ят түгел, чит түгел.
Тик шулай да...
Менә бер заманны фантастик
Оркестр сызды "Тәфтиләү"не.
Күңел галәм кебек иксез-чиксез
булып китте. Бар галәмне
шушы моң сарды.
2009

**Бернәрсәгә кайгырмады**

Бернәрсәгә кайгырмады –
Һаман эшләде генә,
Бу дөньяның тәмен белеп,
Фәкать яшәде генә.

Ул да күпне белә иде,
Ләкин дәшмәде генә
Алтын фикерләре белән
Фәкать яшәде генә.

Кеше сукмагына гөне
Бары түшәде генә,
Кешегә мөкиббән китеп,
Фәкать яшәде генә.

Кинәт кенә китеп барды –
Әллә нишләде генә.
Кичер, Ходай, ул бит җирдә
Фәкать яшәде генә.

Гөнаһлары бардыр инде –
Ул бит яшәде генә.
Кеше матур яшәсен дип,
Фәкать эшләде генә.
2009

Аллаһының могҗизасы –
Мәңгелек һәм чиксезлек.
Мәңгелек һәм чиксезлекне
Юк дип булмый берничек.

Күреп булмый, тотып булмый,
Сыймый безнең акылга.
Кеше күңелен дә Аллаһ
Галәм чаклы киң кылган.
2009

*****

Әйдә киттек, ятма мәгарәдә!
Әрә буйларында әрәмәдә.
Эре-эре кара бөрлегәннәр
Кай арада пешеп өлгергәннәр.

Хөрмәләрең калсын мәгарәдә,
Җыйыйк әйдә кыргый әрәмәдә
Кыргый җимешләрен балачакның,

Как коярбыз – җитәр язга чаклы.

Кичер, Ходай, бөҗәк башым белән
Арысландай гаййәр егетнең
Сөйгән ярын үземә тартып алып,
Ник мескеннең җанын тилмерттем.

Моның өчен февраль бураннары
Гомерем буе миннән үч алды.
Язмыш белән килешим дигән саен
Шул бураннар җанны талады.
2009

**Яшьтәмени соң ул хикмәт!**

Шул җитмешкә җиткән башым белән
Егермедән узган Тукайның
Һәр сүзенә бүген мөкиббәнмен –
Хикмәт нидә, мантыйк кайда соң?

Йөз ел элек әйткән бөек сүзләр
Бүген әйткән кебек тәэсирле.
Күпме укысаң да туеп булмый,
Шундый гади, моңлы һәм серле.

Заманага карап үзгәрми ул,
Яшькә карап артмый-кимеми.
Эзләр бетә, янар таулар сүнә,
Тукай нуры сүнми – сүрелми.
2009

**Туган көнем таңында**

Сәлам сиңа, Туган көнем!
Җитмеш яшем тулар көнем!
Гомер чаклы озын бул син,
Килми торсын үтмәс төнем.
2009

**Диңгездә**

Кара диңгез кояш белән тулы,
Күзләремне рәхәт иркәли.
Ә күңелдә һаман авылым күле –
Диңгездән дә артык микәнни?

Тәнем тула диңгез назы белән,
Кочып алам җылы агымны.
Күңелем исә коена шул ук күлдә -
Әнием кебек юа җанымны.
2009

**Алтмыш биш ел**

Бүген олуг җиңү бәйрәмендә
Миңа кемгә нәрсә дияргә?
Бәлки, ветераннар каршысында
Сүзсез генә башым ияргә?

Бу бәйрәмдә мөнбәр сүз әйтергә
Бәлки, фәкать алар хаклыдыр.
Алтмыш биш ел буена Җиңү
Алар исеме белән балкыйдыр.

Юк, мин түгел, мөнбәр сүзне әйтсен

Сугыш елын кичкән хатын-кыз.
Без аларны күләгәдә калдырып,
Йөртмибезме икән лаексыз?

Бу бәйрәм, юк, сүзгә мохтаҗ түгел,
Җиңү өчен кирәк эш кенә.
Ә без менә сугыш вакытында
Булган әле бик-бик кечкенә.

Безнең балачакны сугыш өткән
Өчтә, дүрттә, биштә, алтыда.
Әтиләрне безнең сугыш йоткан
Без күрмәгән офык артында.

Сугыш безгә шундый якын булган,
Бу бабайлар әгәр шул чакта
Басмаганнар булса утка карап,
Без буласы идек туфракта.

Сугыш безгә килеп җитми калды
Алар күкрәгенә терәлеп.
Без сугыштан исән-имин калдык
Нәкъ кылганнар кебек тибрәлеп.

Без җиңүне яланаяк килеш
Каршыладык көлеп яшь аша.
Шул чактагы сәер кичерешләр
Бөгенгегә килеп тоташа.

Алтмыш биш ел буе бертоташтан
Шушы җиңү белән яшәдек.
Шушы җиңү белән горурландык,
Ил күгендә күкрәп яшьнәдек.

Шушы җиңү белән рухланышып,

Җигелеп тарттык туган ил йөген,
Җиңү белән бергә без картайдык.
Ап-ак чәчле бабай без бүген.

Син исәнме, сугыш елларында
Бездә торган Мәскәү малае?
Кичер безне: үрти идек сине
Рус малае дип – тәре калае.

Без белмәгән, җаным, балачакта
Синең ничек мескен икәнең.
Күз алдыңда әти-әниеңне
Ничек фашист үтереп киткәнен.

Исән булсаң, искә аласыңдыр,
Урамнарын Мулла Иленең.
Бәлки, беркөн килеп тә чыгарсың
Канатында Җиңү җиленең.

Бүген олуг җиңү бәйрәмендә
Миңа кемгә нәрсә дияргә?
Яшь балалар, заман сезгә кала –
Киләчәктә балкыр гөлләргә.

Бу көн сезгә, беләм, кызык түгел,
Ил тарихын ләкин ятлагыз.
Кабатланмас өчен яңа сугыш
Җиңү рухын сез дә саклагыз.
2010

*****

Мин эфирдан, йөз каналны ача-ача,
Йөз милләтнең сөйләмнәрен тыңлаганда,

Гүя йөрим илаһи киң бер аланда;

Һәрберсенең кабатланмас үз төсе бар,

Һәрберсенең сулап туймас хуш исе бар.

2010

**Шагыйрьгә**

Кайда яшәп иҗат итәсеңдер –

Мәркәздәме әллә төбәктә –

Анысы нигә миңа, ә җырларың

Урын ала безнең йөрәктә.

2010

**Язып кала алмый калган шигырьләрем**

Үзегездән үзегез миңа килеп,

"Яз!" – дип ялвардыгыз, илһам биреп.

Тыңламадым, кичектердем һаман,

Форсатларны ычкындырдым кулдан.

Үкенсәм дә эзләп табып булмый.

Нәкъ төш кебек: кире кайтып булмый.

Кичерегез мине, бәгырьләрем –

Яза алмый калган шигырьләрем.

2010

**1957 нче ел язы**

Казан халкы бетон ярга чыгып баскан,
Әкиятләр бүген чынга ашкан.
Күз күреме җитмәс киңлекләрне
Әллә каян килеп диңгез баскан.
Казан халкы бетон ярга чыгып баскан.
Канлы тарих су астына күмелеп калган,
Диңгез уртасында Пирамида калган,
Карап тора кебек шуннан Явыз Иван,

Сөембикә бу хәлләргә киткән хәйран.
Безнең эзебез дә калган су астында
Икәү бергә йөргән сукмаклар да,
Чишмәләрдән агып чыккан ермаклар да,
Сандугачлар сайрап торган куаклар да
Һич булмаган кебек әйтерсең лә монда...
Казан халкы диңгез карый бетон ярда.
1957

**Татар теле диңгезенә чумып**
Татар теле дәрьясына чумып,
Энҗеләрен җыйдым иң төптәге
Һәм аларны шәкертләргә бирдем,
Бизәсеннәр дидем ил күкләрен.

Тикшердем мин көн-төн тау-тау дәфтәр,
Ак битләрдә калды кызыл карам.
Шәкертләрем күңелендә хәзер
Дөреслеккә юл күрсәтеп барам.
1999

**Мәхәббәт – кара урман**
Сиңа булган мәхәббәтем – кара урман,
Шул урманнан мине алып чыга торган
Юлны, ахры, гомрем буе таба алмам,
Сөю янар хәсрәт булып эчтә һаман.

**Сфинкс “Уникс”**
*Казанда, Пушкин урамында, хәзерге “Уникс” бинасы урынында диварына бик матур итеп “Бу йортта Такташ яшәде” дип язып куелган йорт бар иде без яшь чакта*
Менә монда, Пушкин урамында,
Бу галәмәт пулат “Уникс” –
Такташ торган йортны йотканына
Үкенеп ята торган сфинкс.
2002

**Көз**
Кырлар чишенеп яткан йокларга,
Яшереп саклый аларны томан.
Яфрак кала көпчәк эзендә
Алтын көзнең мөһере сыман.

**Төнге ай**
Төннең уртасында ай Зөягә
Таллар белән суга керә.
Судан чыккач, көмеш тарак белән
Арышларны тарап көлә.

**Кара көз**
Яшел шәлең, каен, кая очкан?
Кара көзнең кара җилендә
Кара толымнарың чәбәләнә
Һәм чайкала шәрә иңендә.

**Ак юл сезгә**
Бүген мәктәп әйтерсең лә мәгърур кораб,
Аллы-гөлле нурлы офыкларга карап,

Сәфәр чыга белем дигән зур дәрьяга –
Ак юл сезгә, яшь дусларым, ак юл сезгә.

Кояш һаман бүгенгедәй балкып торсын,
Бәхетегез көннән- көнгә артып торсын,
Хәвеф-хәтәр кичермәгез берегез дә,
Ак юл сезгә, яшь дусларым, ак юл сезгә.

**Ашкыну**

Мин вакытны бер дә кызганмадым,
Ашыктырып кудым һаман да,
Иң яхшы чак тизрәк җитсен өчен,
Ашкындым гел гүзәл заманга.

Сабый чагымда ук ашыга-ашыга
Үзсүзләнеп төштем бишектән,
Тәрәз аша дөнья аз күренгәч,
Үрелдем мин тизрәк ишеккә.

Анда чыккач, мине кояш үпте,
Аннан яңгыр яуды чиләкләп,
Йөгерделәр көннәр борылмалы
Сукмаклардан мине җитәкләп.

Хыялларның берсе чынга ашса,
Икенчесе калды иртәгә.
Иртәгесен инде өченчесен
Теләдем мин куып җитәргә...

Бертуктаусыз шулай ашкынганда,
Очрадым мин кинәт кызыкка –
Картлык әйтте: ”Иң-иң матур чагың
Калган инде артта – кырыкта”.

Күрәм: кичке шәфәкъ нурларында
Гомрем чәчәкләре коела.
Тик шулай да
Иң яхшы чак әле җитмәгәндер,
Алдарактыр кебек тоела.

Мин вакытны һаман ашыктырам,
Мин вакытны куам һаман да,
Мәңгелеккә килгән кеше кебек
Ашкынамын алгы заманга.

**Ничек өлгерергә?**

Инде хәзер ничек өлгерергә?
Эшләнмәгән эшләр тау-тау тора.
Кайгырмас та идең әле –
Гомерләр бит узып бара.

**Кара кешегә**

Һәр сүземнән, һәр эшемнән
Көлдең мыскыл итеп.
Үзеңә ияреп көлгәннәрне

Күрдеӊ дустыӊ итеп.
******
Аланнардан күчәм аланнарга,
Үткәннәрне искә төшереп.
Биредә мин ничә җәйләремне
Кибәннәргә куйдым яшереп.

**Күңелемә сеңгән әкият**

Әбелхәят суын табармын күк,
Мәңгелекнеӊ утын ягармын күк,
Камыр батыр кебек әгәр дә
Чыгып китсәм ерак сәфәргә.

Бу ни хикмәт икән – җиде яшьтә
Күңеләмә сеңгән әкият
Җитмештә дә минем белән яши,
Гүя җанга сеңгән ахирәт.

Бу ни хикмәт икән – югыйсә бит
Күпне күрдем гомер эчендә,
Ә ул һаман бер могҗиза булып
Кала бирә үзе төсендә.

Борын-борын замандагы кебек
Урман уртасында әле дә
Бер убырлы карчык яшәп яткан
Ул йорт тора шул ук хәлендә.

Әбелхәят суын табармын күк,
Мәңгелекнеӊ утын ягармын күк,
Камыр батыр кебек әгәр дә
Чыгып китсәм ерак сәфәргә.
2006

**Бәхет эзләп чаптым гомрем буе**

Бәхет эзләп чаптым гомрем буе,
Ә ул
Куып җиттем дигән чакта һаман
Кача торды миннән алга табан.
Инде белдем:
Бәхтем минем – аны куудадыр.

---

Мин эзләүгә бирдем гомеремне,
Ә табуны калдырам улларыма.
2006

**Узган гомерләргә – салават!**

Узган гомерләргә – салават!
Әүлияләр булып булмады,
Әллә кызлар сөзеп карады,
Әүлияләр булып булмады.

Җәйге күкрәүләргә – салават!
Күктә аллы-гөлле көянтә
Зөяләргә төште бөгелеп –
Тотмак булдым тиз-тиз йөгереп...
Матур иде шул ул бигрәк тә.
2008

**Картайдым дип**

Картайдым дип тып-тын яши башлыйм гына,
Шундук чик куела рәхәт тынлыгыма:
“Әле монда без бар!” – ди-ди, шау-гөр килеп,
Мыштым гына, посып кына, яшеренеп,
Йөрәгемдә йоклап яткан җирләреннән
Килеп чыга балачагым һәм яшьлегем.
2008

**Мин мөселман була торып**

Кичер, Ходай, мин мөселман була торып,
Пушкинны да өзелеп яратамын,
Христиан икәнлеген белә торып;
Евтушенко өчен җан атамын,
Аның яһүд икәнлеген белә торып;
Һотене дә шулай бик сөямен,
Ул католик икәнлеген белә торып;
Тагорга да сөеп баш иямен,
Буддист икәнлеген белә торып.
Бит аларга бу кодрәтне үзең биргән,
Миһербанлык бу дөньяга Синнән иңгән.
Сиңа гына сыгынамын шайтаннардан,
Белә торып язмам бердәнбер хак диннән.
2008

**Болытлар артында – зәңгәр күк**

Бүген көн караңгы, шыксыз дип,
Кадерлем, кайгыга тарыма:
Күкне тик болытлар каплаган,
Алар бит тик тормый – агыла.

Болытлар артында – зәңгәр күк,
Болытлар артында – ай-кояш.
Кышын да шомырттай карлардан
Хуш исләр таратып аңкый яз.

Аяз көн кадерен белергә
Кирәк ул томаннар, болытлар,
Күк йөзе елмаер һәм балкыр,
Еракка чакырыр офыклар.

Алдагы көнебез кояшлы,
Төнебез йолдызлы һәм айлы.
Аяз күк астында милләтем
Каршылар киләчәк язларны.
2009

**Соңгы юлга озаткач**

Ялгыз картка котылгысыз вакыт җитте:
Раббысының хозурына чыгып китте.
Дөньядагы йорты ятим, буп-буш калды,
Һәр тарафны битараф бер тынлык сарды.
Ачык тора шып-шыр булып мескен капка,
Песи генә көтеп тора: тизме кайта?
2009

**Чернобыль**

Җен шешәдән чыгу берни түгел,
Монда җимереп
Йөз елларга салган ныклыкны,
Атом дигән гыйфрит бәреп чыккан,
Котын алып барлык халыкның.

Ни буласын бер дә уйламыйча,
Шул ыржайган үлем өстенә
Боралактан яшь егетләр көн-төн
Бетон койган өсте-өстенә.

Сүндергәннәр үлем реакторын,
Үзләре дә сүнгән егетләр,
Радиоактив затка әверелеп,
Бакыйлыкка очкан бөркетләр.

Гәүдәләрен шул реактор кебек
Нур чәчмәсен өчен кабердә
Җирләгәннәр бетон саркофакта.
Шул егетләр яши бәгырьдә.

26.04.2010.

**2010 нчы ел җәе**

Корылыктан көлем кибеп бетте,
Буш бер чокыр калды ыржаеп.
Камышларын җуеп яргаланган,
Беләүләнгән ярлар кыршавы.

Чиксез әрнү белән өзгәләнеп
Оялып ята шәрә күл төбе.
Киләчәккә өмет белән багып,
Бер юаныч эзли бу күңел.

Кышын карлар тау-тау булып яуса,
Күлем тулыр язлар җиткәчтен.
Күңел күле генә корымасын,
Күңел күле генә кипмәсен.

14.10.2010.

**Пар канатым**

Авылымда бар шул минем зур бәхетем:
Пар йолдыздай үз мәктәбем, үз мәчетем,
Икесен дә тигез күреп мин яраттым,
Алар минем көчле рухи пар канатым.
Түбән калмас бу җан алар бар чагында,
Алдый алмас тормыш чуар кочагында.

10.09.2010.

**Казаларга калдырма**

Кичәге көн ул синеке түгел,
Кайтасы юк аның мәңгегә.
Хаталарың булса, тәүбәңне кыл,
Ярлыкауны сора тәңредән.

Бүгенге көн әле ул синеке,

Минутларны юкка яндырма,
Эшләреңне бүген эшләп бетер,
Иртәгәгә, зинһар, калдырма.

Иртәгене Алла үзе белә,
Кем җиһанда булыр, кем булмас.
Өметеңне ләкин һич сүндермә
Өмет уты җиргә күмелмәс.

13.09.2010.

**Сары, сары, сап-сары...**

Мин яратам чәчәкләрнең сарыларын –
Яз җитүгә бөтен җирне саруларын,
Йөзләрендә кояш балкып чагылганын,
Уйнап үскән бала чакны сагынамын.
Күрәм сары чәчле кызның чалымнарын,
Мин яратам чәчәкләрнең сарыларын,
Гомрем булды бертоташтан сары агым,
Җиткән икән ничек кенә сабырларым.

2010

**Ак шигырь**

Могҗизалар могҗизасы булган
Тереклекнең башлангычын
Тып-тын гына, яшерен генә
Мәңгелек бер сер иттереп
Үзләрендә саклап торган
Орлыклардан
Җир өстенә чыккан шытымнарның
Сабакланып, тармакланып,
Ботакланып,
Кояш нурларында хозурланып,
Яшел кыякларга,
Яшел яфракларга
Купшыланып төренүен
Күреп тору нинди рәхәт!
Бар төсләрнең
Хуш исләнеп балкулары белән
Мең-мең чәчәкләрнең
Матур кызлар кебек
Елмаешып карауларын
Күреп тору нинди рәхәт!
Килеп җитә бөек вакыт:
Тып-тын гына, яшерен генә
Чәчәкләрдән хасил була
Тук бөртекләр
Һәм төшәләр мыштым гына
Үзләрен бер тыелгысыз наз белән
Көтеп торган җирнең туфрагына.
Орлыкларда мәңгелек бер хәтер яши
Җәйләр саен гел яңарып.
Мәңгелеккә барган орлыкларның барын
Белеп тору нинди рәхәт!
Нәни генә орлыкларда

Булачак гомерләр дә,
Үткән гомерләр дә
Сыеп беткән.

**Кем нәрсә тели**

Ятсам иде, дия, болыт
Рәхәтләнеп шул тау булып.
Ә тау тели күк гизәргә
Шул болыттай томырылып.
2010

**Яраткан шагыйремә**

Син тиргәлдең шома язмаганга
Ә бит шундый максат куйсаң,
Коя ала идең үрнәк шомалык,
Тик калсыннар иде шомланып.

Синдә исә
Бөтен күңелләрне сискәндереп
Бүселеп чыга я артыклык,
Яки сокландыра
Юлларыңда сүзгә кытлык.
2010

***

Яхшы эшләреңне яман итеп
Чәйнәсәләр көфер почмагында,
Аларга юл куйма сөенергә –
Изгелегең арттыр син тагын да.
2010

***

Мәхәббәтем сарайлары янды,
Күрмәсеннәр хәрабәләрен –
Кичерегез мине, яшерегез,
Әрәләрем, әрәмәләрем.
2010

***

Тау башында пар карама
Ничә генә карама.
Икәү бергә гел янәшә
Һаман бергә серләшә.
2010

**Бер юбилей мөнәсәбәте илә**

(Рияз Гыйбадуллинга)
Бу җитмешкә җитмеш – картлык түгел,
Бөтен җирең җитеш, сөбханалла!
Җитмеш һөнәр белән җегет бул гел,
Җимешләрең пешсен һаман алда.

Сәҗдәләргә яткан биш вакытың,
Сәхәрләрең, моңлы азаннарың
Кабул булсын, гел хәерле кылсын
Тәкъдирләргә Раббым язганнарын.
2010

**Дүрт Сәйфетдин**

*(Бөек җиңүнең 65 еллыгы белән)*
Минем йорттан яуга киткәннәрнең
Исемнәре кайткан – өч Сәйфетдин.
Каберләре – ерак Европада,
Дүртенчесе исән: менә ул мин.

Бу бәйрәмдә хакым бик зур минем,
Өч Сәйфетдин үлгән Ватан өчен.
Мин аларга лаек яшәдемме –
Шушы җиргә биреп барлык көчем.

Явызлыкка каршы кылыч бул син,
Усаллыкны әйдә гел өркет син.
Бөек Җиңү булып балкый бүген
Дүрт Сәйфетдин бүген, дүрт Сәйфетдин.
2010

**“Яңа гасыр”га мәдхия**

Елдан-ел ишәеп,
Язлардай яшәреп,
Яшә син, яшә, “Яңа гасыр”.
Халкымның хыялын,
Ялкынлы уйларын
Әйдә син, әйдә, чынга ашыр.

Дулкының, ил гизеп,
Күңелләр диңгезен
Айкасын әйдә, “Яңа гасыр”.
Җиһанда сафлыкны,
Иң өстен хаклыкны
Якла син, якла, алга бастыр.

Без барган сәфәрдә
Каршы җил әгәр дә
Калдырса уеп маңгайга сыр,
Күңелне юатып,
Сабырлык уятып
Сыйпыйсың баштан, “Яңа гасыр”.

Хөр бул син гомергә,
Ил белән гел бергә
Иркенлек даулап, хөрлек тарат.
Соклансын йолдызлар,
Юл тапсын юлсызлар,
Юл тапсын алар сиңа карап.

Бу бәхет түгелме –
Көн саен күңелне
Иркәли таңнарда милли җыр.
Шатлыклар өләшеп,
Ягымлы эндәшеп,
Нык саулык тели “Яңа гасыр”.

Һәрвакыт янда син,
Һәрвакыт җанда син,
Зур гомер тели сиңа халкың.
Син барда йөрәктә
Һәр чакта, һәр якта
Дөрләр ул, дөрләр милли ялкын.

Халыкның хакларын –
Яшьләрнең, картларның –
Хакла син, хакла нәкъ Тукайча.
Казансын дәү Казан
Яңадан-яңа дан,
Килмәсен афәт һичберкайчан.

Халкымның моңнарын,
Иң асыл җырларын
Бик аулак җирләргә син ташы.
Урманнар шауласын,
Сандугач сайрасын,
Яшәсен безнең "Яңа гасыр"!
2010

**Гомер**

Мулла Иле сигез гасыр буе
Минсез генә шулай яшәгән.
Мин туасын зарыгып көтә-көтә,
Тармакланып беткән шәҗәрәм.

Мин тугач та, авыл сөенечен
Йорттан йортка йөргән өләшеп...
...Бүген сиксән яшьлек талым белән
Өй каршында торам серләшеп.
2010

**Сәхабәләр* килгән Болгарга**

"Сез әүвәлге кавемнәр торган җирләргә барыгыз, карагыз, гыйбрәт алыгыз"
(Коръән Кәрим, "Гыймран сүрәсе, 137 нче аять)

*I*

Болгар бүген халык белән тулы,
Һәр ягыннан килеп Рәсәйнең,
Татар дигән кавем нәрсә эзли
Хозур бер мәлендә бу җәйнең?

Безнең тарих җанга якын булган
Риваятьләр белән үрелгән:
Нух оныгы Алып, монда килеп,
Чабатасын кагып йөргән.

Риваятьләр безнең үткәннәрне
Илаһи моң белән өретә,
Дәрәҗәсен бизи һәм күтәрә,
Күңелләргә иман беркетә.

Риваятьләр бөек хикмәт сөйли,
Әй Болгарым, нинди изге син!
Пәйгамбәрнең исән чагында ук
Килеп җиткән монда безнең дин.

Җиргә рәхмәт итеп җибәрелгән
Пәйгамбәрдән безнең бу илгә
Сәхабәләр килеп болгарларны
Өйрәткәннәр дөрес, хак дингә.

Болгар! Болгар! Шәҗәрәңнең башы
Ерак-ерак гасырлар аша
Җиргә рәхмәт итеп җибәрелгән
Пәйгамбәргә барып тоташа.

II

Егерме мең татар, саф-саф булып,
Атлый менә изге җирләрдән.
Безнең куллардагы яшел байрак
Әй җилферди иркен җилләрдә.

Җанланалар ак таш хәрабәләр,
Тере булып атлый хәтерләр.
Ә кылганнар – ап-ак чәчле тарих –
Озата бара безне кадерләп.

Сахра тулы тәмле әрем исе,
Идел җиле шундый ягымлы;
Күкләр шундый биек, рухи сафлык,
Яшәү көче били җанымны.

Шушы җирдә сәхабәләр йөргән,
Идел суы белән пакьләнеп;
“Бәдәвам” һәм “Йосыф кыйссасы”ның
Саф моңнары калган сакланып.

III

Монда шәһәр чәчәк атып торган,
Еракларга данын таратып.
Һәм бабайлар монда азан әйткән,
Идел киңлекләрен яңгыратып.

Җәмигъ мәчет нигезендә ташлар
Саклый кебек аның эзләрен;
Зур манара тәрәзеннән гүя
Күрәм кебек нурлы йөзләрен.

Гөлчәчәкле җиргә ятып тыңлыйм –
Ишетәм кебек аның сулышын;
Күз нурлары сеңгән диварлардан
Милли моңнар ташый тулышып.

IV

Без барабыз гүзәл тарих аша
Безнең белән гүя янәшә

Атлый кебек бергә сәхабәләр,
Чал гасырлар гүя берләшә.

Йөрәкләрдән ургып-ургып чыга
Пәйгамбәргә сәлам-салават.
Ул нурлаган Бөек Болгар илен,
Ул бердәнбер безгә үрнәк зат.

Бу туфракта соңгы йортын тапкан
Сәхабәнең рухы шат булсын.
Гүре бакый ахыйрәткә кадәр
Изгелеге белән балкысын.

Җиргә рәхмәт итеп җибәрелгән
Пәйгамбәрне күргән сәхабә,
Аның нурын монда ирештереп,
Бабаларга биргән мәртәбә.

V

Ирештер гел, Раббем, догабызны
Болгар бабаларның рухына;
Алар каршында без зур бурычлы
Илткән өчен Аллаһ юлына.

Пәйгамбәргә әйтик салаватлар,
Көннән-көнгә әхлак яхшырсын.
Күңел Пәйгамбәрне сөю белән,
Шәфкать нуры белән яктырсын.

Әй татарым, тайма хак динеңнән,
Иҗтиһат ит булып әхлаклы;
Фанилыкта лаек урының ал,
Бакыйлыкка җыйна савапны.

Укы Коръән, өйрән Хәдисләрне –
Бар сорауга шунда хак җавап.
Салават әйт көн дә Пәйгамбәргә –
Инсанга Ул – сүнмәс маяк зат.

Бар мактаулар, Раббым, Сиңа гына,
Расуленә мең-мең салават.
Бәрәкәтләр иңдер җиребезгә
Бирче безгә гүзәл саф әхлак.
** Сәхабә – пәйгамбәр илчесе.*
2011

**Борынгы язуга иярүләр**

*Себердә Туба елгасы буенда, кыя ташка уеп, безнең эраның V гасырында язылган түбәндәге юллар бар:*
*Йүз яшәйен!*
*Тәңри – өчүк безкә.*
*Идил – йәримә бәңгү балбал бу.*
*(Малов С.Енисейская письменность тюрков. М. – Л. 1952, 66 бит.)*
*Енисей – әни су*
*Ыссык-Күл – эссе күл*
*Байкал – бай күл*
*Туба – тоба (тирән су) (этимологик сүзлектән)*
*Өметнең төне юк (мәкаль)*
*Вакыты җиткәч, һәр милләтнең үз таңы ата (әйтем)*

***Бер уйлану өчен***

Татарлар Себердә – Татар бугазыннан Уралгача – бер тарихи кавем булып, бер телдә сөйләшеп, бер диндә булып яшәгәннәр. Өметнең төне юк. Өметнең таңы гына бар. Вакыт җиткәч, һәр милләтнең үз таңы ата.

Татар иле.
Серле Себер җире.
Төрки кавемнең асыл Ватаны.
Шәҗәрәмнең
Башлангычы монда –
Тәүге бабамның изге калканы.

Монда сулар
Ага чын татарча,

Ага Енисей – сулар әнисе.
Ага Туба,
Ярларында кыя –
Шул турыда килә сөйлисе.

Бу кыяда
Төрки чөй язу бар,
Безнең хәрефләр уеп язылган.
Алар балкый
Унбиш гасыр буе,
Исән-сау калып күпме давылдан.

Шагыйрь бабам!
Кыя ташта шигырең
Чал телне безнең саклап калган ул:
“Йөз яшәргә!
Тәңри – өчүк[1] безкә,
Идил –йәримә бәңгү балбал[2] бу.”

 Унбиш гасыр
Сүзләр аз үзгәргән,
Төрки-татарлык гаҗәп икән бу:
“Йөз яшәргә!
Күк ул – түбә безгә,
Идел – җиремә мәңге һәйкәл бу.”

Енисейны,
Туба, Орхоннарны
Идел дигәннәр төрки-татарлар.
Бу кыяда
Безнең чын тарихны
Раслап торган көч, олуг хикмәт бар.

Шигырь яңгырый
Нәкъ бүгенге кебек,
Чал тарих белән тоташ күңелләр.
Йөз яшәргә!
Бу Күк – түбә безгә,
Бу күк – калкан безгә,
Бу күк – сакчы безгә,
Зур мирас безгә җирдә иделләр.

Исламгача
Чорда яшәсә дә,
Бу бабам сизгән Ислам киләсен.
Бабалары,
Күчеп безнең якка,
Каршы алганнар Хак Дин иртәсен.

Пәйгамбәрдән
Килгән сәхабәне
Чын күңел белән кабул иткәннәр

Үзләштереп
Изге хәрефләрне,
Коръән боерган юлдан киткәннәр.
Таймаганнар
Алар изге юлдан,
Ябырылса да мең-мең хәвефләр.
Ә Себердә
Кыя ташта балкый
Төрки-татарча иске хәрефләр.
***1 Өчүк – оч(күк очы, күк түбәсе)***
***2 Балбал – һәйкәл, иң кадерле мирас.***
2011

Төрки телләрнең тарихын озак еллар тикшергән С.Е. Малов Идел-Кама буенда бик борынгы чорларда яшәгән кабиләләрнең хәзерге татар теленә карата мөнәсәбәтләрен билгеләп болай язды: “Мин уйлыйм: татар теле безнең эрага кадәр берничә йөз ел элек үк хәзергегә охшашлы бер хәлдә булгандыр. Әгәр дә хәзерге татарлар безнең эрага кадәр, якынча әйткәндә, V йөздәге “борынгы татар белән очрашсалар, алар бер-берсе белән тулаем сөйләшеп аңлашырлар иде. Безнең эрага кадәр шундый ук төрки-“татар” теле булган.” (“Происхождение казанских татар” (сборник), Казань, 1948 нче ел, 116 нчы бит) С.Е. Малов үзенең бу нәтиҗәләрен төрки телләрнең бик нык стабильлегеннән һәм бик аз үзгәрүчән сыйфатыннан чыгып ясаганлыгын әйтә. Аның бу фикерләре тел белеменең гомуми законнарына бик туры ***к***илә. Безнең эрага кадәрге “борынгы татар” сүзләре сакланып калган чыганак бармы? Бар. Борынгы табышмакларда, мәкальләрдә, ырым сүзләрендә сакланып калган.

Мисаллар:
Озын-озын эз килер,
Озын буйлы кыз килер;
Кабаклары калтырап,
Маңгайлары ялтырап.

Таба, таба табалама
Таба аркылы юргалама,
Айгыр күрсәң, кешнәмә,
Кеше күрсәң, тешләмә.

Бу – ырым сүзләре. Монда борынгы татарның еланнарга карата әйтелгән ырым сүзләре. Татар еланга юашланырга, тынычланырга куша, аның зарарын булдырмаска тырыша.

“Тимер тапкан тилмермәс,
Тимере бар тилмермәс,
Каены бар кайгырмас”

Без яшәгән шушы җирләрдә тимер безнең эрага кадәр VIII гасырда ук табылган. “Кечкенә генә эт өрми дә, җибәрми дә” Бу табышмакның җавабы: йозак. Бу – борынгы йозак. Борынгы татар йозакны тимердән эткә охшатып ясаган.

2013

***

Сүз әйтергә ашыкма син, сабыр бул,
Сүзсез кыя кебек серле, горур бул.
Астыртыннар әйдә яшрен ут йөртсен,
Берләшсеннәр, чәйнәшсеннәр, җай көтсен.

Беркемгә дә ачуланма, ялгыз бул,
Үз-үзеңне тыңла, ябык авыз бул.
Суфиланып йөрсен әйдә тар күңел,

Син тумыштан андыйларга тиң түгел.
8.06.2011.

*******

Рәнҗетелгән булып, зинһар, кыланма,
Үз файдаңа миннән дошман ясама.
Яшерен өрәк булып торма чатларда,
Мәкерләрең өчен яңа җәтмә сайлама.
17.06.2011.

***

Син ирештең бөек максатыңа:
Минем хакта гайбәт таратып.
Көфер почмагында елмаясың,
Бар гавәмне үзеңә каратып.

Гавәм миңа арты белән басты,
Сәлам бирми – күрми янәсе.
Хәтта дустым гавәм бар чагында
Кырын карый яшереп кенәсен.

Гавәм юкта тирә-юньгә карап
Бик дустанә, җылы эндәшә.
Гавәм килеп чыкса артын бора,
Тизрәк гавәм белән берләшә.
9.07.2011.

**Үз-үземә**

Үзем белән үзем сөйләшәм,
Үз-үземә үзем эндәшәм:
– Булып Равил хәзрәт Сәйфетдин,
Булмадыңмы илгә хәсрәт? – дим.

Исемең Равил – «язгы кояш»тыр,
Язгы кояш – җылы караштыр.
Лаекмы син шушы исемгә –
Нур сибәмсең балкып һәркемгә?

«Дин кылычы» бит ул – Сәйфетдин,
Явызлыкны әйдә өркет син.
Мулла булсаң Мулла Илендә,
Гел гаделлек сөрсен җиреңдә.

2011

**Кандалый** (1797-1860)

Үзең – мулла, үзең – гашыйк,
үзең – шагыйрь!
Тоткансың да өч көймәнең койрыгын син,
Юлыккансың залимнәрнең каһәренә,
Үтәмичә ишаннарның бойрыгын син.

«Шигырь язу – шайтан эше!» – дигән алар,
Мулла кеше шигырь язып маташамы?!
Мулла кеше гыйшык тотып йөримени?!
Һич күргән юк әле мондый тамашаны.

Хөр, тәвәккәл, чәнечкеле шигырьләрең
Фаш иткәннәр бозык әхлак әһелләрен.
Куркып-өркеп алар сиңа үчеккәннәр
Һәм чәчкәннәр ялаларын, мәкерләрен.

Муллалыктан беркөн сине төшерткәннәр,
Хурлык! Ике ел төрмәдә череткәннәр.
Йөр син янып саф дин, саф мәхәббәт өчен!
Нигә болай ялган-мәкер чыга өстен?!

Шагыйрь йөрәгеннән хаклык таша,
Ул ялвара тимер рәшәткәләр аша:
«И кояшым! Чыкчы кара бу болыттан,
Коткар мине алар яккан яла-уттан».

А юк! Халык үзе хаклык даулап чыккан,
Үз мулласын йолкып алган иңнәренә.
Ачкан халык аңа яңа мәхәлләсен
Һәм кайтарган гадел, бөек мөнбәренә.

Габделҗәббар хәзрәт күптән вафат инде,
Үтеп киткән һич кайтмаска күп вакытлар.
Әмма шагыйрь исән: балкып яна әнә
Кандалыйдан калган нурлы, саф якутлар.

2011

**Һибәтулла Салихов** (1794-1867)
(Мулла шагыйрьгә)
***«Гаса» дигән шигыренә карата (гаса (фарсы) - култаяк)***
Тәндә җанның кунак кына
Икәнлеген белгәнсең:
Исән чакта син үлемсез
Мөнәҗәтләр үргәнсең.

Култаягың – гасаңны да
Әйләндереп шигырьгә,
Үгет-нәсыйхәтләр биреп
Калдыргансың син безгә:

Гаса кебек бул син җирдә:
Аяксызга аяк бул;
Ялгызларга юлдаш бул син,
Адашканга маяк бул.

Гаса кебек шыр ялангач,
Ярлы, мескен булсаң да,
Күзсезләргә җитәкче бул,
Төз, туры бул җиһанда.
2011

**Шәмсетдин Зәки** (1825-1865)
*(Тумыштан сукыр суфый шагыйрьгә)*
Максатыңа туры баргансың син,

Күзлеләрдән күбрәк күргәнсең.
Кинәт килгән үлемең дә бөек:
«Үлем миңа дошман түгел» диеп,
Үлемне дә сөеп үлгәнсең,
Хаҗ юлында син җан биргәнсең.
2011

**Шәһәргә**

Заман, авылларның кешеләрен
Чакрып алып, сиңа китерде.
Милләт телен, денен һәм тарихын
Саклау бурычын сиңа җиткерде.

Үтә, шәһәр, изге миссияңне,
Карап тора күрмә авылга.
Яңа гасыр яңа җайлар эзли
Милләтемне саклап калырга.
7.10.2011.

**Поэзия**

Поэзия – гыйшкым ияседер,
Җисми түгел, мәңге тере кыз
Картайтмыйча тора мине дә ул,
Шуңа яздай минем бу тормыш.
2.02.2011.

**Тупыллар**

Сугышлардан исән кайткан ирләр
Дин ирегән күрде картайгач:
Мәчет манарасын күтәргән көн
Утыртты һәрберсе бер агач.

Агачлары гади генә түгел,
Бер хикмәтен уйлап тапканнар,
Шәһит киткәннәрнең каны тамган
Волгоградтан алып кайтканнар.

Һәр җомгага каршы ала-ала
Зифа булып үсте тупыллар,
Берәм-берәм соңгы юлларына
Озатып калды алар сулкылдап.

Фанилыкта бүген берсе дә юк,
Тупыллары мәчет тирәләп
Басып тора горур сакчылардай,
Исәннәрнең күзен иркәләп.

Кипарислар кебек күккә үрелеп,
Манарадан ашып киткәннәр.
Азан тавышларын тыңлый-тыңлый,
Зекер әйтә-әйтә үскәннәр.

Бирешмичә заман җилләренә
Гасыр ярым торган мәчеткә
Мәрхүмнәрнең оныклары килә –

Җан сөенә мондый бәхеткә.

Тупылларга куәт, рәхәт бирә
Оныкларның җылы карашы.
Дин ирегe тәмен белгәннәрне
Хәвефләрдән Ходай сакласын.
3.10.2011.

**Сигез йөз биш**

Мин, аксакал, ялдан файдаланып,
Үземә бер кызык эш таптым:
Укытып үткән хезмәт юлымдагы
Барлык сәхифәне актардым.

Миндә укыганнар берәм-берәм
Килеп баса торды алдыма.
Яза бардым: булды сигез йөз биш,
Мин хәтерлим икән барын да.

Шул сигез йөз бишне хыялымнан
Саф-саф итеп бергә утырттым.
Кавыштылар бергә барлык еллар,
Күңелемне минем яктыртып.

...Июль аендагы умартадай
Гөҗләп торды минем һәр дәрес.
Шул сигез йөз бишнең һәркайсы да
Чыгып керә алды рөхсәтсез.

“Мокамай”дан күбе “бишле” алды,
Ә “икеле” бер дә булмады.
Сигез йөз биш кулның язганнарын
Укый-укый күңлем нурланды.

Кызыл кара белмим күпме киткән,
Күз нурларым күпме коелган.
Мин төзәткән хаталарны карап
Дөреслеккә алар юл алган.

Ләззәтләнеп, ничек хозурланып.
Үз дөньямны тәмам онытып,
Кол Галинең сихри дөньясында
Йөрттем изгелеккә омтылып.

Алып кереп сүзләр бакчасына
Һәрбер сүзнең урынын күрсәттем.
Алма кебек тәмен татыттырдым,
Җанга милли хисләр үрләттем.

Сигез йөз биш холык. Һәрберсенә
Ачкычларын ничек тапканмын,
“Хулиган” дип аты чыкканга да
Дус абыйдай сөеп бакканмын.

Үпкә, кенә, үчне мин белмәдем,
Беркемнең дә шуңа эчендә
Минем өчен таш ятмыйдыр сыман,
Гел яхшылык күрәм төшемдә.

Мин якладым әләк-ялалардан,
Ялганнардан, мәкер-гайбәттән,
Шуның өчен шактый күп таландым
Куштаннардан, хөсед ир-аттан.

Ришвәт тотып килгән ялагайның
Арт сабагын бишкә укыттым.
Гарьләнүдән килгән күз яшемне
Дәресемә кереп корыттым.

Сигез йөз биш язмыш. Һәркайсы да
Алып калган гомрем өлешен.
Мәрхүмнәрнең җаны тыныч булсын,
Ә исәннәр яшик белешеп.

5.10.2011.

**Карт кеше**

Җитмеш елның җитмеш язы миндә,
Җитмеш ташкын, бергә кушылып,
Гомер үзәненнән шаулап ага,
Җирдә яшәвемне хуш кылып.

Җитмеш елның җитмеш җәе миндә,
Чәчәкләре бергә җыелып
Тутырып карый күңел күзләремә,
Шулар белән яшим җылынып.

Җитмеш елның җитмеш көзе миндә,
Яфраклары коелып берьюлы
Гомер сукмагыма түшәләләр,
Күңелемдә шуңа моң тулы.

Җитмеш елның җитмеш кышы миндә,
Бөтерелә тәңкә карлары.
Ак биләүдән ак кәфенгә чаклы
Мин шулардан алам дәваны.

Гомерем калыр шул ташкыннар булып,
Шул чәчәкләр кебек алланып.
Ә хәзергә алар барысы миндә,
Күңелемдә яши җанланып.

12.11.2011.

**Албаба**

Авылыбызга сәлам биреп китә
Албабадан узган поездлар.
Шулар тавышын тыңлап үтте гомрем,

Шул турыда әйтер сүзем бар.

...Сабый чагым. Җирдә сугыш бара.
Фашист килеп җиткән Иделгә.
Кара төндә өйдә ялгыз кунам,
Чикерткә шом сала күңелгә.

Ут кабызу катгый тыелган чак:
Кара төндә авыл өстеннән
Очып үткән фашист очкычлары
Бернәрсә дә күрми үтсеннәр.

Кыл өстендә тора безнең язмыш,
Җимерелми тора чак кына.
Бездән ерак түгел Идел күперен
Шартлатырга дошман ашкына.

Төнне яра уяу зениткалар,
Төшми кала немец бомбасы,
Мин барсын да белеп, тоеп торам,
Мин бит чөнки солдат баласы.

Кыл өстендә тора безнең язмыш,
Сталинград тора чак кына.
Төн караңгы. Кырдан өннәр килә,
Ялгыз күңлем шунда талпына.
Анда
Идел күпереннән Сталинградка
Бара торган юлны салалар.
Әби, әни шунда эшли минем,
Шунда эшли бик күп аналар.

Мин өйрәндем төннән курыкмаска,
Булсын гына тизрәк тимер юл.
Идел буен саклап калу өчен
Бик ашыгыч безгә кирәк ул.

Ул көн килде: яңа тимер юлдан
Эшелоннар шаулап чаптылар.
Озатып калдым кулны болгый-болгый,
Күзләремнән яшьләр актылар.

Эшелоннар чапты хәтәр якка –
Әти сугышып йөргән фронтка.
Сөенгәндер әти җиңәбез дип,
Тик килмәде аннан бер хат та.

Корал төяп чапкан поездларның
Тыкылдавы калды йөрәктә.
Әни, әбиләрнең яшрен генә
Сулкылдавы тора күкрәктә.

Җиңү килде.
Без, зарыккан солдат балалары,
Әтиләрне каршы алырга
Томырылдык дәррәү Албабага...
Балкып кайтты күпләр авылга.

Ә мин күпме барып, бер поезд да
Әтиемне алып кайтмады.
Ул хәбәрсез яуда югалганга,
Күңел һаман өмет саклады.

Караңгы төн. Йоклый алмый ятам.
Өй түремдә тагын чикерткә,
Ерак балачактан килгән дә ул
Таныш җырын миңа сиптертә.

Аңа кушыла поезд тавышлары,
Бөтен гомерем уза хәтердән.
Шул поездлар белән Албабага
Әти кайтыр кебек хәзер дә.
30.10.2011.

**Бәрәкәтле гомер сөрдем**

Бәрәкәтле гомер сөрдем,
Зөя суларында йөздем,
Әрә тугайларын гиздем,
Тауларына менеп йөрдем,
Бәрәкәтле гомер сөрдем.

Зөя суларында йөздем,
Җәйләремнең мең рәхәтен,
Мең диңгезнең мең сихәтен
Аның кочагында сиздем,
Зөя суларында йөздем.

Әрә тугайларын гиздем,
Ал таңнарда хозурланып,
Чәчәкләрнең матурларын
Шигырь юлларыма тездем,
Әрә тугайларын гиздем.

Тауларына менеп йөрдем,
Күтәрелде күңел күгем,
Офыкларга бакты күзем,
Ерак-еракларны күрдем,
Тауларына менеп йөрдем.

Бәрәкәтле гомер сөрдем,
Нәрсә чәчсәм, шуны урдым,
Уңышлардан риза булдым,
Рәхмәт, җирем, барсын бирдең,
Бәрәкәтле гомер сөрдем.
1.11.2011.

**Тәнкыйтьчемә**

Син тиргәмә мине шигыремдә
Бик күп җирле сүзләр барлыкка,
Алар да бит безнең хәзинәбез,
Әверелсен уртак байлыкка.

“Кәлшә” сүзен “кәй”гә санама син,
Әдәби сүз итеп кабул ит.
Икенче кат үскән покосларны
Шул сүз белән халык атый бит.

Син тиргәмә безнең бу заманда
Язасың дип иске ысулда.
Ачык һәм ябык иҗекләрдән
Чират тезмә дисең һәр юлда.

Ә мин телим борынгыдан килгән
Аһәңнәрнең бездә яшәрен,
Илаһи моң булып сузылуын
Җаннарында безнең яшьләрнең.

4.06.2011.

**Кораллар күргәзмәсендә**

Үтерү өчен һай тырышкан кеше!
Чәчәк аткан үтерү иҗаты.
Сәнгать итеп шуны карый ир-ат,
Хәтта тора кызлар чираты.

“Мондый белән Пушкин үтерелгән,
Нинди уңай, диләр, зиннәтле!
Чын ир кеше өчен монда, диләр,
Табып була иң зур ләззәтне”.

Ә мин мәңге чын ир булмам, ахры,
Монда минем җаным кыйнала.
Ләкин корал миңа карап тормый
Тантанасын итә дөньяда.

17.02.2011.

**Тән һәм җан**

Җанны мактап, тәнне хурламагыз –
Икесе дә алар илаһи.
Тәндә җаныбыз булган чакта шуны
Белеп яшик әле, валлаһи.

Иң әүвәлдә Аллаһ үз нурыннан
Яралткан бит безнең җаннарны;
Аннан җирдә үз вакыты белән
Иңдерә барган тәнгә аларны.

Җан тән белән бергә чакта җирдә
Сынауларын уза Аллаһның.
Каралтмыйча яшик җаныбызны,
Ни икәнен белеп гөнаһның.

Тән җаныннан Раббысына очар,
Әҗәл җиткәч кунак чак бетеп.
Тән бетте дип ләкин уйламагыз,
Җан шикелле тән дә мәңгелек.

Мәхшәр көнне тән җан белән кавышып,
Кубарылып чыгып кабердән,
Басачакбыз Аллаһ хөкеменә,
Әзерләник шуңа хәзердән.

Җан тән белән булыр мәңге бергә
Җәннәттәме әллә тәмугта,
Дөньялыкта шуны белеп яшик,
Җанны саклыйк керсез сафлыкта.
28.10.2011.

**Тукай елы**

Арттыр, Кояш, балкуыңны:
Җиһанда – Тукай елы!
Барлык гөлләр чәчәк атсын,
Булсыннар елмаюлы.

Болын күрке – күп төрле гөл,
Һәркайсы үзгә бер ямь.
Болын кебек бул син, Рәсәй,
Нурлан йөз милләт белән.

Төнге күкләр – безгә үрнәк:
Эреле-ваклы һәр йолдыз
Уртак күктә ничек яна
Бик дустанә, ызгышсыз.

Рәсәй безнең – уртак Ватан,
Болын кебек, күк кебек.
Тукай теле – Ватан теле
Үссен алга үрелеп.

Тукай белән бергә булсын
Хөр, гали зыялылар.
Керергә җир тапмасыннар
Имансыз риялылар.

Кочаклашсын түрә-байлар
Бу елда гавам белән,
Тукайча чын хаклык җиңсен –
Барыйк бер әләм белән.

Шомлы җилләр искәндә дә,
Яшик ихлас сайрашып,
Яңа чорга лаек булып,
Лөгать, гадәт алмашып.

Тукайны да, Пушкинны да
Үз итү – олы бәхет.
Шуны аңлаган патшага
Насыйптыр тыныч тәхет.

(Безнең Путин чал Казанның
Мең еллыгы көнендә
Доклад ясап киткән иде
Бөек Тукай телендә).

“Хөр мәмләкәт, хөр Русия!” –
Иң бөек безнең максат.
Инкыйразга юл куймабыз,
Иң дөрес юлны сайлап.

Хаклык байрагын күтәреп,
Атлагыз, тукайчылар –
Милләтемне яклаучылар,
Афәттән саклаучылар.

Арттыр, Кояш, балкуыңны:
Җиһанда – Тукай елы!
Тукае барның җиһанда
Өметле яшәү юлы.

Күк булып күкрә һавада,
Хөр яшәү даулашлары!
Мескенләнеп йөрмә, милләт:
Күп бит йөзек кашларың.

Хөр заманда ак кул белән
Күктән йолдызлар чүплә.
Өргән өрсен, бәгъре өзек
Милләтне санап чүпкә.

Яңа гасыр эргәсендә
Моңлана Тукай сазы,
Бәргәләнә, өзгәләнә –
Гомергә юк тынасы.

Илдә хакы зурдан булган
Халыкның бөек улын
Байрак итеп, Татарстан,
Нурлы ит барыр юлың.

Мөбарәк бул, Тукай елы,
Дөнья торсын яхшырып:
Гасыр хәтле гасыр үзе
Булсын Тукай гасыры.
26.04.2011

**Мәскәүгә бару**

Кырык градуслы февраль төнен

Ерып чаба поезд мәркәзгә.
Яшен яшьнәгәндәй ялт-йолт утлар
Чагылып-чагылып кала тәрәздә.

Күзне йокы алмый, төн буена
Уйларыма  чумып барамын,
Иртәгә мин Равил Гайнетдиннең
Күзләренә тутырып карармын.

Ул үткәргән шигырь бәйгесендә
Мин беренче урын алганмын,
Ул чакырган мине тантанага –
Шунда менә ашыгып барамын.

Пәйгамбәр бит шигъри хикмәтләрне
Тыңлый торган булган елмаеп,
Шулай булгач, шигырь – изге нәрсә,
Изге эшкә барам юлланып.
21.02.2011.

*******

Күпбеләмнәр, сине надан санап,
Гыйлемнәре белән кизәнсә,
Тик тор. Җиңелгәнгә салыш әйдә,
Ярый хәтта мактап җибәрсәң.

Очынсыннар әйдә, андыйларны
Очындыру – үзе бер рәхәт.
Ә җиңәргә теләп һич ярсыма,
Йөрәгеңә алып җәрәхәт.
25.06.2011.

***

Җәй рәхәтен күреп калыйм әле!
Бар эшемне ташлап,
Хәтфә җиргә чалкан ятып,
Барлык буыннарны йомшартып.
Күктә кояш көлә,
Ак болытлар килә,
Күләгәләр шуыша өстемнән.
Рәхәт, шундый рәхәт,
Як-ягымда сакта тупыллар,
Сайрап тора хәтсез былбыллар.
Күңел шунда рәхәтлекне куа башлый,
Җитәр, ди ул, алдың күп сихәт.
Эшкә башла тизрәк,
Хәрәкәттә генә бәрәкәт.
25.06.2011.

***

Бәрәңгеләр чәчәк аткан чакта
Бөтен күңелем серле аклыкта.
Сабый да мин, егет тә мин һаман,
Аксакал да – бер үк вакытта.
30.06.2011.

***

Тын, астыртын, яшерен хөсетлек
Бөтен җанны ала өшетеп.
Халкың өчен ихлас хезмәтең
Тапмый кала тиеш хөрмәтен.
26.09.2011.

**Әнвәр Давыдовка**

Үсмер чакта кырда атка төяп
Көлтә ташыганда ындырга,
Давыдывны укып йөри идем,
Гашыйк булып, һәрбер җырына.

Алтын бертекләрнең хикмәтләрен
Гади итеп миңа ул ачты.
Гомерлеккә минем күңелемә
Сердәш абый булып урнашты.

Мин яраттым аны бөтенләйгә
Хөрмәт иттем эчтән-тирәннән.
Ул бит, горур утлы күкрәк куеп,
Каршы торды хәтәр җилләргә.

Сугышларда мең үлемнән калып
Телгәләнгән шагыйрь йөрәге
Әле галәмнәрне урап кайтты,
Әле күмер булып көйрәде.

Тынычлыкка сөенеп туялмыйча,
Гөлләр белән йөрде серләшеп.
Бөдрә чәчен җилдә җилфердәтеп,
Зәңгәр күзләреннән нур чәчеп.

Ышанмыйча шагыйрь докторларга,
Авыруга булган үченнән
Ашыгып куды шигырь дулкыннарын
Җәлил, Кәрим, Кутуй өчен дә.

Студент чак Тукай клубында,
Кече башыбызны дәү итеп,
Безнең шигырьләрне ихлас тыңлап,
Хуплап торды үзе Давыдов.
2011

***

Без матурлык, дибез, алтын, дибез,
Төсләр балкышына тиңлибез.
Чынлыкта, бу – китеп барган җәйнең
Хушлашуы – шуны белмибез.

Мин дә җирдән китәр көннәремдә
Мине сөйгән кеше күзенә
Күренә алсам иде охшап шулай
Табигатьнең алтын көзенә.

2011

**Өч сәхабә**
Үзебезнең дәүләт тоткан җиребезгә
Без беләбез алты йөз дә утыз бердә
Пәйгамбәрдән килгән мәшһүр өч сәхабә –
Рухларына дога кылыйк күп мәртәбә.

Габдрахман улы Зөбәернең рухын,
Зөбәернең газиз улы Җәгъдә рухын,
Тәльха улы Госман хәзрәтләрнең рухын
Шат әйләсен, сөендерсен иде Раббым.
28.10.2011.

*****

**Узган гомерләргә – салават!**
Әүлияләр булып булмады.
Әллә тормыш безне алдады,
Әллә кызлар сөзеп карады,
Без теләгән таңнар тумады.

Яшьнәү-күкрүләргә – салават!
Аллы-гөлле дуга-көянтә
Зөяләргә төште бөгелеп,
Тотмак булдым тиз-тиз йөгереп...
Ятып калды хыял йөрәктә.
2012

**Якты өмет**
Рәсәй ул – милләтем Ватаны,
Кайда да нур чәчте татарым.
Кушлавыч, Мостафа, Сыркыды
Шагыйрьләр үстереп балкыды.

Бәлки, ул авыллар югалыр –
Алардан җыр калыр, моң калыр,
Хәтердә торыр гел зур сафта
Кушлавыч, Сыркыды, Мостафа.

Яшәрләр Рәсәйдә чын ирләр –
Тукайлар, Такташлар, Җәлилләр,
Яшьнәрләр ил күген балкытып,
Халкымның бәгырен яктыртып.

Рәсәйдә көн саен таң атар,
Һәр таңда елмаер татарлар;
Туарлар ишәеп өр-яңа
Тукайлар, Җәлилләр, Такташлар.

Томаннар таралыр, югалыр,
Замана гел булмас алдавыч.
Үстерер өр-яңа улларын
Мостафа, Сыркыды, Кушлавыч.
2012

**Борынгы зират**

***(ак шигырь)***

***Яшел Үзән районының Мулла Иле зиратында 1493, 1528 нче елларда вафат булган мәрхүмнәргә куелган кабер ташлары бүген дә үзләренең урыннарында, яхшы сакланган хәлдә, нык торалар.***

Тагын килдем изге җиргә – тын зиратка.
Монда күрәм яшәешнең чын тарихын.
Газиз гомерләрнең башын һәм ахырын,
Ике дөнья турында да нык уйлата.

Сәлам сезгә, әй каберләр әһелләре!
Безнең монда килгәнлекне белүчеләр!
Ярлыкасын Аллаһ сезне һәм безләрне,
Сез – алдарак, без сездән соң килүчеләр!

Менә монда, зиратның кыл уртасында,
Бөтен дөнья күренеп торган үр башында,
Авылыма нигез салган Муллаголның
Җир куйнында сыену тапкан соң урыны.

И Муллагол бабам! Гүрең якты булсын!
Шушы җиргә качып килеп син Болгардан
Авыл хәтле авыл торгызгансың, хәзрәт,
Исемең калган җуелмаска гасырларда.

Түп-түгәрәк бу борынгы тыюлыкны
Саклап тора гаскәр кебек карт тупыллар.
Мең-мең гомер тигезләнгән изге җиргә
Керә алмый котырып килгән җил-давыллар.

Кар китүгә, монда гаҗәп бер манзара:
Җир йөзеннән юкка чыккан чәчкә затлар –
Алтынтуйлар алтынланып балкып яна,
Борынгылык хөкем сөрә һәр адымда..

Нинди олпат һәм зиннәтле каберташлар –
Хикмәт сөйли изге Коръән хәрефләре!
Бу ядкярләр гасырлардан хәбәрдарлар,
Кичкән алар ныклык белән хәвефләрне.

Зур таш сөйли: “Мең дә дүрт йөз туксан өчтә
Тәвәккәл Гаяли Рәҗәп  Солтан
Фәнадин бәкага рихләт кылды”, – дип,
Рәхмәтен әйләсен бер Раббым-Ходам.

И борынгы авылдашым Рәҗәп әби!
Тарихыңны бу таш аша беләм мин дә,
Дөньялыкта чакта Казаннардан килгән
Чулпыларны чеңләткәнсең, беләм, син дә.

“Мең биш йөз егерме сигездә, – дип,
Янә дә әнә бер таш сөйләргә кучте,–

Сәфәр айда Шәйх Хәсән угылы Миргали
Фани дөньядан бакый дөньяга күчте.”

Әйтте Аллаһы тәбарәкә вә тәгалә:
“Бәндәләрнең һәрберсе дә үлем татыр.
Дөнья беткәч, ул әйләнеп безгә кайтыр.”

Пәйгамбәрнең әйткәннәрен онытмагыз:
Гомерләрнең дәрәҗәсен күтәрегез.
Аллаһыга бертуктаусыз зекер әйтеп
Һәм файдалы эшләр эшләп үткәрегез”.

И Миргали бабам, кабул булсын догам,
Рухыңны шат әйләсен бер Раббым.
Аллаһыдан җәннәтләрдә синең белән
Күрештерү бәхетләрен теләп калам.

Менә монда изге җирдә – тын зиратта
Ике дөнья турында да нык уйлата.
Монда күрәм яшәешнең чын тарихын,
Газиз гомерләрнең башын һәм ахырын.
2012

**Фани дөнья белән хушлашу**

Йолдызларың, аең, кояшыңны
Күреп туймас булып яшәдем...
Хуш, бәхил бул инде, фани дөнья,
Бик якында бугай әҗәлем.

Мин мәхшәрдә кабат терелермен,
Насыйп итсен Раббым җәннәтен –
Фанилыктан бакыйлыкка күчеп
Мәңгелектә яшәү рәхәтен.

Әмма сине кабат мәңге күрмәм,
Раббым сине кабат бар итмәс.
Син яшәрсең бары хәтеремдә,
Мәңгелектә булып бер иптәш.
2012

**Үткәнем һәм бүгенем**

И мәктәбем, безнең балачакны
Җитәкләдең хәтәр елларда,
Сугыш чорын кичкән малайларны
Син чыгардың олы юлларга.

Ә мин, сине артык яратканга,
Чит җирләргә китеп тормадым,
Бөтенләйгә калдым кочагыңда,
Ә син бер дә каршы булмадың.

Уйлаганмын ничек беркатлы мин:
Бик тиз үрелеп күккә, йолдызга,
Үземдәге телгә мәхәббәтне

Күчерергә малай һәм кызга,

Шигырь белән барысын сихерләргә,
Күңелләргә бик тиз керергә,
Тукай, Пушкин, Хафиз, Шиллерлардан
Сихри такыялар үрергә.

Һәр класста утыз-кырык герой,
Утыз-кырык холык, чуарлык.
Шигырь белән генә алдырып булмый,
Педагоглык кирәк, чыдамлык.

Шул чыдамлык, сабырлыклар белән,
Йомшаклыгын яшереп күңелнең,
Тыштан каты булып, балаларга
Мин үземчә бирдем белемне.

Июль аендагы умартадай
Гөжләп торды минем һәр дәрес.
Иншаларда бала күршесенә
Ярдәм итә алды рөхсәтсез.

Тикшергәчтен, дәфтәр булып калды
Канга баткан әтәч шикелле.
Җәлләү хисен җуйган хирургтай
Мин рәхимсез куйдым “икеле”.

Шул малайлар хәзер, миңа очрап,
Мин оныткан бик күп нәрсәне,
Искә төшереп, җанны җылыталар,
Гомер узган тоташ әсәрле.

Очрыйлар да сөйләп җибәрәләр
Кайсы Тукай, кайсы Пушкинны,
Кайсы Шиллер, кайсы Ясәвине,
Күңелемне рәхәт хуш кылып.

Бер күңелдә бер таш ятмый миңа,
Булган, әлбәт, булган төрлесе.
Кемдер зур бер дастан итеп сөйли
Ялгыш кына алган “берле”сен.

Миңа шундый рәхәт: үткәннәрем
Нур коялар шаулап бүгенгә.
Күңел тулып ташый бәхет белән,
Рәнҗү, ачу, шик юк беркемгә.

Кайсылары минем кебек итеп
Телләр укытып йөри мәктәптә.
Кемдер булган фәннәр кандидаты,
Барысы яхшы, барысы тәртиптә.

И мәктәбем, юлың шулай барсын,
Буын арты буын алмашсын.
Туган телен белеп бетермәгән
Бер татар да җирдә калмасын.

2012

**Фронтовиклар**

Белем бирде безгә фронтовиклар –
Утны-суны кичкән хәрбиләр.
Без алардан алдык тыштан кырыс,
Эчтән йомшак, җылы тәрбия.

Сталинград фронтында булган
Сәмигуллин абый – директор –
Һәр малайны итте математик,
Үзе булды безгә бер доктор.

Ул дарулар ясап бирә иде
Авырып киткән һәрбер малайга.
Дәресләрдә аның белән күпме
Без окопта яттык Мамайда.

Фронттагы кебек, чыбыклардан
Киртә корып мәктәп тирәли,
Әкияти гөлбакча ясады ул,
(Ах, шул чаклар җанны иркәли).

Ленинград фронтында булган
Безнең завуч Сибгать абыйга
Бөтен Татарстан килә иде
Тәҗрибәсен алып калырга.

Шагыйрь, рәссам, җырчы һәм музыкант,
Макаренко кебек нык абый.
Төрле яклап безне кеше итте,
Кем булуга бер дә карамый.

Һәр адымны безнең белә иде,
Күрә иде безне үтәли.
Сугыш кырын тасвирлаган чакта
Була иде аңа әллә ни.

Берлингача җитеп җиңеп кайткан
Сул яңагы җөйле яралы –
Ул Хәйретдин абый Пушкин белән
Әсир итте безнең җаннарны.

Рәхим абый – физо җитәкчесе –
Одергача җиткән офицер.
Чынлап чыныктырды безнең тәнне
Һәм җанга да итте зур тәэсир.

Укыттылар безне фронтовиклар –
Утны-суны кичкән хәрбиләр.
Без алардан алдык тыштан кырыс,
Эчтән йомшак, җылы тәрбия.

2012

### *Яшел Үзән – минем мәркәзем*

I

Сиңа - сиксән, миңа җитмеш биш яшь,
Икәү бергә кордаш булсак та,
Көче ташып торган егеттәй син,
Ә мин инде бабай – аксакал.

Син балкыйсың нурлы шәһәр булып,
Татарстан данын арттырып,
Шул горурлык, шушы сөенечтән
Чал картлыгым тора яктырып.

Гомерем буе авылымнан һаман
Алып килә сиңа поездлар.
Бу тимер юл миңа бик кадерле,
Шул турыда әйтер сүзем бар:

...Сабый чагым. Җирдә сугыш бара.
Фашист килә ыжгырып Иделгә.
Кара төндә өйдә ялгыз кунам,
Кара шомнар тулган күңелгә.

Кыр ягыннан ишетелеп тора
Даң-доң, даң-доң иткән тавышлар.
Анда шулай тимер юл төзиләр,
Килеп җитмәсен дип сугышлар.

Әби, әни минем төн буена,
Ялгызымны өйдә калдырып,
Тачка белән шунда таш ташыйлар,
Фашистларга ләгънәт яудырып.

Дөм караңгы өйдә бер ялгызым,
Дөм караңгы барлык урам да.
Кабызырга утны һич ярамый,
Маскировка кирәк булганга.

Әни әйтә: төнлә безнең өстән
Фашист очкычлары үтә, ди,
Идел күперен шартлатырга теләп,
Безнең өстән шунда китә, ди.

Кабызырга утны һич ярамый,
Дошман күзе күрә күрмәсен.
Саташсын ул юлдан, шартлатырга
Тиеш җиргә барып кермәсен.

Яшел Үзән! Мин соңыннан белдем:
Шундый-шундый хәтәр төннәрдә
Бер бомба да целыгә төшми калган
Без бурычлы икән кемнәргә?

Урманында синең яшеренгән
Зениткалар утны төз аткан,
Синең күктән фашист козгыннарын
Гомерлеккә куып озаткан.

Мин өйрәндем төннән курыкмаска,
Булсын гына тизрәк тимер юл.
Сталинградны саклап калу өчен
Бик ашыгыч безгә кирәк ул.

Ул көн килде: яңа тимер юлдан

Эшелоннар шаулап чаптылар.
Кулны болгый-болгый озатып калдым,
Күзләремнән яшьләр актылар.

Яшел Үзән!
Синең снарядлар китте анда,
Китте анда синең катерлар...
Җиңү килде! Шушы тимер юлдан
Батырлары яуның кайттылар.

Әтиемне каршыларга чаптым
Мин башкалар белән беррәттән.
Ул кайтмады. Бары поездларның
Тыкылдавы калды йөрәктә.

II

Тәүге тапкыр мин, поездга утырып,
Кырык бишнең җылы язында
Сиңа бардым әби белән бергә,
Кырлар чапты тәрәз каршыннан.

Мин Иделне күреп шаклар каттым,
Гигант күпер аша чыкканда,
Әби белән «Ләхәүлә»не әйттем,
Нинди могҗизалар юк анда.

Үрләреңә мендек әби белән,
Чиләкләрне көчкә күтәреп,
Базарында саттык май, йомырка,
Бөтен көнне шунда үткәреп.

Әби миңа шунда алып бирде
Тәүге тапкыр ап-ак морожный.
Сатучы кыз әйтте миңа карап:
«Какой чёрный, какой хороший!»

Без төн кунган йорт һаман исән.
Зәңгәр хатирәгә төренеп,
Милли редакция тәрәзеннән
Моңсу гына тора күренеп.

Истә: йорт каршында зур алачык,
Эче тулы кат-кат сәндерә,
Ярты Мулла Иле шунда куна,
Хуҗа күнеле барсын сыйдыра.

Бу йортта мин хисапсыз күп булдым,
Малайлары белән бергәләп,
Күпме маҗаралар кылып йөрдем,
Рус телен дә оттым иртәрәк.

«Париж Коммунасы» клубында
Кинофильм карап кичкырын,
Шәһәр чыгып, карурманга кереп,
Тарзан булып йөрдек кычкырып.

Урман артларында бертуктаусыз
Гөрселдәүләр торды яңгырап.
Бу – “Серго”ның сынаулары икән,
Халык тормый моңа аптырап.

«Родина»ның затлы сәхнәсеннән
Рәшит Ваһаповны тыңладык;
Аның кебек без дә, каш сикертеп,
Урманда ул булып җырладык.

Шул сарайның аулак бакчасында
Тынлы оркестрда Сәйдәшнең
Мәшһүр маршы безне әсир итте
Матурлыкка, алга ул дәште.

«Авангард»ка өстән качып кереп,
Сызгыра-сызгыра футбол карадык.
Камышлы күл төпләренә чумып,
Хәзинәлар эзләп каралдык.

Челләләрдә качыш уйнадык без,
Идел комнарына күмелеп,
Пароходның дулкын тауларына
Йомычкадай мендек үрелеп.

Чиратларда тордык икмәк өчен
Иң атаклы кибет «Шанхай»да,
Анда булган икмәк исеннән дә
Тәмле нәрсә юктыр беркайда.

Яшел Үзән!
Син бит безнең күпме малайларны
Кеше иттең, егет ясадың.
Ремеслоңның җылы кочагында,
Җитмеш һөнәр биреп,
Киләчәккә якты юл салдың.

Тулай торак бирдең, тукландырдың,
Киендердең – барысы гел бушка.
Бушка китмәделәр болар бер дә,
Әзерләдең шулай тормышка.

III

Мәгарифнең биек үрләренә
Мин менәргә синдә өйрәндем,
Синдә таптым гүзәл кешеләрне,
Тойдым һәрчак җылы иңнәрен.

Сокландым мин Туктар шуклыгына
Һәм яраттым горур йөрүен,
Карамыйча байлык юклыгына
Бар каланы тутырып көлүен.

Сокландым мин Мәхмүт Хәсәновка,
Бар кешене үзенә каратып:
«Ә мин татар урта мәктәбен бит
Монда, Зелендулда, бетердем!» – дип
Мактануын ничек яраттым!

Чыгарса да том-том китапларын,
Һич кунмады аңа зураю,
Сабый бала кебек йөрде һаман,
Ә гәүдәсе мисле зур аю.

Бер могҗиза итеп сокландым мин:
Энгельстагы Фаил Шәфигуллин
Амбар хәтле такта чоланын
Шыплап тутырып куйды китап белән,
Сөенеп торды шуңа анасы.

Сокландым мин Азат Вергазовка,
Үзе – әдип, үзе – педагог.
Пәйгамбәрдәй яши көнкүрештә,
Кая барса – шунда йөзе ак.

IV

Яшел Үзән!
Мәчетләрең гүзәл бер-берсеннән,
Нур сибәләр бөтен шәһәргә.
Зәңгәр күккә ашкан манаралар
Көч бирәләр җирдә яшәргә.

Мин шуларга карап сөенәм дә,
Җылы хисләр били күңелне.
Тоела миңа: гүя син яшь түгел,
Бик борынгы шәһәр шикелле.

Киләсеңдер Болгар чорыннан ук,
Менә монда – Идел үрендә
Торасыңдыр гасырларны кочып,
Тарих миңа шулай күренә.

Мәңгелек җыр, милли “Карурман”да
Тугандыр, дим, синең урманда.
Син ясаган катерларда юкка
Без бармыйбыз бугай Болгарга.

Без, муллалар, барлык авыллардан
Җыелганда синең мәчеткә
Мин коенам әйтеп бетергесез
Бар рәхәткә, ап-ак бәхеткә.

Тоела миңа: гүя мондый җыен
Борынгыдан килә – Болгардан.
Габделхәмит хәзрәт килгәндер ул
Кол Галиләр торган чорлардан.

Раббым Аллаһ! Безнең бу халәтне
Мәхшәргәчә сакла шул килеш.
Кабатланыйк килер буыннарда,
Юк, булмасын артка чигенеш.

Район өчен үзәк булсаң да син,
Минем өчен – мәркәз, башкала.
Юкка гына өзгәләнми үзәк
Кимсеткәндә сине башкалар.

Күпме шәһәрләрне күрмәдем мин,
Күпме хәйран калып йөрмәдем,
Тик алардан
Шашкын сагыну белән
Сиңа алып кайтты йөрәгем.

Поездлардан сиңа төшү белән,
И бердәнбер газиз җиркәем,
Өзелеп сагындым дип кочып ала
Иделемнең йомшак җилкәе.

Таныш баскычлардан, саф-саф булып,
Кешеләрең эшкә ашыга.
Шулар мәнфәгатен кайгыртп, бәгырем,
Шуларны куй мөнбәр каршына.

-------------------------------------------

Сугыш чорын кичкән мин малайга
Бәйрәм иде тик бер вакыйга:
Ул – поездга утырып беренче кат
Барган чагым Паратскига.

Бәйрәм хисе калды гомерлеккә,
Мин бүген дә шулай ашкынып,
Сиңа киләм, гүзәл Яшел Үзән,
Бар хыялны чынга ашырып.

2012

*****

Сабантуйлар гөрләп узып китте,
Тып-тын калды елга тугае.
Сагышымны минем белде бугай –
Җыр башлады сабан тургае.
12.09.2012

**Әбиләр чуагы**

Бүгенге көн шундый кызык:
(Табигатьне аз беләбез)
Күр, бакчада икәү бергә

Ничек уйный яз белән көз.

Алтын кояш каеннарга
Нурын сибә яздагыча.
Яз дип белеп, тузганаклар
Күздә янә күзен ача.

Ятим торган оясына
Кырдан кайткан пар сыерчык.
Яз дип белеп сайрый алар
Икәү бергә талпынышып.

Ботакларда тын җылыда
Җәйри көзге пәрәвезләр.
Бер-берсенә нинди охшаш
Җылы язлар, җылы көзләр.

Яз дип белеп уҗымнарга
Килеп куна төклетура,
Әллә каян очып килеп,
Пар күбәләк пәйда була.
28.09.2012

**Ачыклык**

Дүрт якка да карый тәрәзләрем,
Дүрт якта да күренә офыклар.
Тау башында яшәү нинди рәхәт:
Бөтен дөнья синең хозурда.
11.11.2012

*******

Мәңгелекне аңлый алмый безнең күңел,
Чиксезлеккә төшенергә мөмкин түгел.
Аларны бар кылган Раббым мәңге тере,
Мәңге уяу, юк әүвәле, юк ахыры.
14.11.2012

**Картлык**

Бар вөҗүдем хәзер картлык дигән
Нигъмәт белән, шөкер, туп-тулы.
Мин сабый да хәзер һәм егет тә,
Аксакал да булдым берьюлы.
2012

**Дөнья беткән көндә**

*2012 нче елның 21 нче декабрендә дөнья бетәчәк дип, астрологлар халыкка тәшвиш салдылар.*

Бөтен дөнья дүрт күз белән
Ахырзаман көткәндә,
Котыра-котыра җыя торгач,
Шырпы-шәмнәр беткәндә,

Тик мин генә бу дөньяда,
Шатланып туялмыйча,
Шигырь язам Алиягә,
Хисләрем тыялмыйча.

Бу чатырман декабрьнең
Нәкъ егерме берендә –
Бөтен халык шашып көткән
Ахырзаман көнендә

Без ясыйбыз Алиянең
Бер яшьлек юбилеен.
Аңа дөнья тик башлана,
Гомерле булса иде.

Дөнья да безне аңлады,
Һай, рәхмәтләр төшкере,
Кайда бетү?! Пәйда булды
Күр, салават күпере.

Алиягә җыр җырларга
Ал былбыллар килделәр.
Алиянең ал күлмәген
Ал бишеккә элделәр.

Аллария – ләрия,
Гөлләрия – ләрия,
Ал чәчәктән матур булып
Үссен безнең Алия.

Хак Тәгалә гомерлеккә
Хәерле саулык бирсен,
Һәр сулышын, һәр адымын
Фәрештә багып йөрсен.

Алиябез милли көйгә
Бик күңелле селкенә,
Очып китәргә талпынган
Кош шикелле җилкенә.

Үссен иде ул тупылдап,
Шатлык, бәхеткә тулып,
Әтисенә, әнисенә
Шәфкатьле бала булып.

Ахырзаман булмаганга,
Халык сөенер инде.
Шырпы-шәмнәр туплаучылар
Шактыр көенер инде.
21.12.2012

**Чиксезлек**

Галәмнәрдән ары
Күкләр катламында –
Галактикаларның
Теге якларында

Мәңге тоташ бушлык,
Тоташ чиксезлекме?
Моны белә алмау
Безнең көчсезлекме?

Ул чиксезлек ничек
Яши ала болай?
Бар иткән шул аны
Мәңге тере, уяу,
Мәңге бар бер Ходай.
7.02.2013

**Тәлгать Галиуллинга**

Ике китап тора шкафымда.
Мең тугыз йөз илле алтыда
Син аларны миңа бүләк итеп
Тапшыргансың дуслар каршында.

Китапларда тора язуларың,
Йомры хәрефләрең җанга хуш:
“Бәхетләрең – алда , – дигәнсең син, –
Матур итеп яшә, Равил дус”.

Китапларның берсе – Мәскәү баскан
Кызыл тышлы “Наша Родина”.
Сталинчыл чорга дан җырлаган
Соңгы китап булды ул миңа.

Икенчесе – сөннәр турындагы
Кытай тарихчысы китабы.
Мин мәктәптә укытканда һаман
Файдаландым шуннан тәм табып.

Ул чагында унсигездә идек,
Хәзер менә безгә җитмеш биш.
Син һаман да миңа – профорг,
Дүрт ягың да синең җитеш ич.

Яшь чакта ук ачык күренә иде
Аксакалдай акыл байлыгың.
Инглиз булып тусаң, Драйзердай
Дөнья гизәр көчең бар иде.

Ә син, дустым, татар булып калдың,
Бер дә үзгәрмәдең – гел яндың.
Дәрес бирдең минем улыма да,
Хаклык ягын раслап дөньяның.

Бик куркыныч елларны син, дустым,
Өстерәдең төптән җигелеп.
Хаклык өчен барган көрәшләрдә
Син калмадың, дустым, җиңелеп.

Әдипләрне күрә белеп күрдең,
Иҗатларын миргә яктырттың.
Лаек иттең Тукай бүләгенә,
Юк, язмадың һич тә арттырып.

Әсәрләрең мәңге үлми яшәр
Хөр “Мәһдиев йолдызлыгында”.
Йолдызлардан килгән нурлар кебек
Алар балкыр килер буында.

Яшь чактагы киңәшеңә рәхмәт,
Син кушканча матур яшәдем.
Безнең хисләр кабатлансын иде
Күкрәгендә асыл яшьләрнең.
2013

**Югалтулар булсын хәерлегә**

*Романс-җыр*

Еллар буе язган
Җырлар дәфтәремне
Юллар йөри-йөри югалттым.
Күңелемнең газиз
Ядкярләрен җуйдым,
Кирәк түгел миңа мең алтын.

Тапкан кеше бардыр,
Ләкин дәфтәремдә
Кемлегемне мин шул язмаган.
Табылыр дигән өмет
Әкрен генә сүнде,
Ул кабыныр микән яңадан.

...Көтмәгәндә таңда
Аулак тын урманда
Ямансулап йөргән чагымда,
Эфирлардан ташып,
Яңгырады җырым,
Бәхет уты янды җанымда.

Дәфтәремне тапкан
Мәрхәмәтле кеше
Минем җырны сибә җиһанга.
Кем язганын әйдә
Белмәсеннәр бер дә,
Моң өстәсен җырым урманга.

Хәерлегә булсын
Безнең югалтулар
Җанны мәңге өмет биләсен;
Көенечләр арты
Сөенечләр килсен,
Гомерлеккә кайгы килмәсен.
02.02. 2013

**Ике шагыйрь**

Ике шагыйрь таңда шигырь язды:
Берсе – сиксән, берсе – унбиштә,
Берсе – хәсрәтенә дәва эзләп,
Берсе – дөрләп шашкын бер хистә.

Берсе кичә тәү кат кыз озаткан,
Фәрештәгә аны охшаткан.
Берсе гомер сөргән җан кисәген
Бакыйлыкка кичә озаткан.

Берсе якты хыял канатында
Киләчәккә очты куанып.
Берсе үткәннәргә китеп барды,
Хатирәләр белән юанып.
7.02.2013

**Шиһабетдин Мәрҗани**

(1818-1889)

*“Өч әйбер диндә юк: әмма динне саклый. Берсе – милли тел, икенчесе – милли гореф, өченчесе – милли кием”*

***Шиһабетдин Мәрҗани***

*“XIX гасыр эчендә татар муллаларыннан иң көчлесе, иң галиме, татар мөселманнарын “саф” көендә саклау юлында бертуктаусыз хезмәт иткән кешеләрнең беренчесе – шөбһәсез, Шиһабетдин Мәрҗани иде. Аннан соң аның юлын дәвам иттерүчеләр: Зөя өязендәге Ачасыр авылында Гыйрфанетдин Сәгъдетдинов һәм шул ук өязнең Мулла Иле авылында мулла Вәлихәйдәр Котлымөхәммәтов (1844-1915) иде. Вәлихәйдәр мулланың кулында Мәрҗанинең күп кулъязмалары сакланган.”(Гасыйм Мансуров. “Беренче революция елларында татарлар” дигән китап. – Мәскәү: СССР халыкларының үзәк нәшрияты, 1926 ел)*

Татарларның туңган күңелләрен
Җылытырга милли Казан бар.
Шул Казанның шаулы уртасында
Мөлдерәмә тарих – Кабан бар

Шул Кабанның аулак эргәсендә
Иман йорты – тәүге мәчет бар.
Шул мәчеттә Мәрҗанидән калган
Чын татарлык дигән бәхет бар.

Җиребездә Иблис котырганда,
Җимергәндә иман йортларын,
Бер ялгызы төннәр буе янды
Мәрҗанинең горур утлары.

Килгән чакта башка мең-мең хәсрәт,
Китапларын укып юандык.
Хозурландык милли гөлбакчада,
Күңелләргә изге нур алдык.

Мәрҗанине бөек остаз итеп,
Каршы торып кара агымга,

Дөнья гыйлемен укыту белән бергә
Без мулла да булдык авылда.

Ни әйтсәң дә, безнең авылда да
Мең  сигез йөз сиксән алтыда
Мәрҗани бит булган – якын дусты
Вәлихәйдәр хәзрәт йортында.

Һәм сакларга дип аңа калдырган ул
Кулъязмалар  тулы дәфтәрен...
Мәрҗанине күргән мәчет исән –
Үткәннәрнең бөек ядкяре.

Диндә пакь һәм ихлас булган кебек,
Хакыйкатьне яклап фәндә дә,
Яшиселәр килә Мәрҗанидәй,
Кулны биреп нурлы бәндәгә.

Мәчетендә керсез, тугъры имам,
Мәдрәсәдә юмарт мөгаллим,
Шулай була торып, күпме әләк,
Күпме яла күргән бу галим.

Тырышканнар, мәчетеннән куып,
Утыртырга зиндан төбенә,
Китапларын, барысын бергә җыеп,
Батырырга Кабан күленә.

Мәрҗанине халык яклап чыккан,
Этләр хөкеменә бирмәгән...
Бүген дә бар үчле, көнче затлар –
Гаеп эзли керсез җирләрдән.

Дин әһеле фәнгә кизәнмәсен,
Һәрбер чын фән – Аллаһ нигъмәте.
Хакның җиргә куйган кануннарын
Өйрәнүдә аның хикмәте.

Коръән-хафиз булган иманлы кол
Була ала химик, физик та.
Кешелекнең бәхете –мәгърифәттә,
Яшәү шунда рәхәт, кызык та.

Һәрбер фәндә яман нәрсә күреп,
Мәгърифәтсез кара муллалар
Кешелекнең акыл алгарышын
Үстерергә зарар салалар.

Иман әһеле, Ислам белән бергә
Юлдаш итә алса фәнне дә,
Камил хәлгә куяр әхлагын да,
Гүзәл итәр җанын-тәнен дә.

Хакыйкатьнең даһи яклаучысы
Гыйлем бакчасының сакчысы
Безнең белән бара, биреп безгә
Акылының көчле яктысын.

Без барабыз якты өмет белән,
Мәрҗаниләр белән юлланып.
Чәчәк атсын Ислам яңарышы,
Изге Коръән белән нурланып.

Чайкалдырмыйк мәгърур корабны без,
Тигез җирдә түмгәк ясамыйк.
Мәрҗаниләр рухын горур саклыйк,
Читләр бәхетенә күз салмыйк.
9 март, 2013 ел.

**Гали авылы**

*Университетны бетергәч, 1961-1963 нче елларда Самара өлкәсендәге Гали урта мәктәбендә укытучы булып эшләдем.*

– Җибәрмәгез мине, зинһар, читкә,
Кайтарыгыз Мулла Иленә,
Яуда үлгән әти хакы өчен
Эшләтегез туган җиремдә.

Анда – өч улын да сугыш йотып
Сукырайган мескен әбием,
Көн-төн илгә хезмәт итеп арыган
Яклаучысыз, ирсез әнием.

Анда безнең ызба җиргә иңгән,
Миннән башка йортны кем салыр.
Туган мәктәбемдә урын бар бит,
Безнең хәлләр шулай бик авыр", –

Мин ялвардым шулай, вуз бетергәч,
Дәүләт комиссиясе алдында.
Ләкин юкка! Кем якласын мине
Күрә торып Закон каршында.

Гали! Гали! Авыр уйлар белән
Сөрелеп килдем синдә эшләргә.
Сөйгән яр да миннән йөз чөерде,
Үзенең парын тапты шәһәрдә.

Сиңа барып төшкәч, шаклар каттым:
Коммунизм җиткән чагында
Дәһри СССРның уртасында
Урнашкан бу шәһри авылда

Өч мәчет бит гөрләп эшләп тора,
Өч манара балкый нурланып.
Урта мәктәп тора хозурланып,

Азан моңнарына уралып.

Кайгылырым монда юылып төште,
Мондый халәт күргән юк әле.
Фатир хуҗам Коръәнхафиз икән –
 Җанга үтеп керә мәкаме.

Монда халык сөйли чын татарча,
Туган телем яши гөрләтеп.
Тукай телен укыту зур мәртәбә –
Булдым монда ничек хөрмәтле.

Казаннан бик ерак-ерак җирдә
Өзелеп сөйгән газиз милләтем
Маңгаемнан сыйпап юатты да
Сабырлыкка мине өйрәтте.

Мәктәбендә балалары хәтсез –
Һәр сыйныфта утыз я кырык.
Шулар мине ничек яраттырды,
Газапларым китте яктырып.

Хатлар яздым өйгә: балагыз дип
Көн-төн сезнең хакта кайгырып,
Сезнең кебек көн-төн хезмәт итә,
Ватан аңлар, рәхмәт яугыры.

Тормыш күргән кеше булып кайттым
Мин Галидән Мулла Иленә.
Хак Тәгалә сынауларын узып,
Халкым йөген салып иңемә.

...Күрсәтәләр бүген бар Рәсәйгә
Үрнәк итеп Гали улларын.
Бар Рәсәйдән кунак чакрып алып
Гөрләтәләр Сабантуйларын.

Экраннардан күренә бар Рәсәйгә
Мин яраткан Гали таулары.
Шул тауларга багып карап торам
Яшьлегемнең алтын елларын.

Сыйныфтагы кырык бала белән
Шул тауларның менеп башына
Чаңгыларда выжлап оча идек
Томырылып таулар астына.

Кар китүгә, иң-иң биек җирдә,
Ясап язның тәүге бәйрәмен,
Кырык бала белән без кададык
Үзебезнең сыйныф байрагын.
24.01.2013

**Ак келәт**

*Ак келәтнең эчләрендә*
*Кулъяулыгы эшләдем;*
*Сиңа охшатып гөл утырттым,*
*Ул корыса нишләрем.*

*Ак келәтнең алларында*
*Тәңкә таптым, әләли.*
*Җаның сөйгән ярларыңны*
*Бер күрүе әллә ни.*
***Татар халык җыры***

Борынгыдан килгән нигеземдә
Мирас булып тора ак келәт,
Биек мансардалар көнләшмәсен,
Шуны саклыйм артык кадерләп.

Шәмдәй шома бериш бүрәнәләр
Бер-берсенә тигез береккән,
Чорлар җиле купшы диварларга
Бик килешле сырлар йөгерткән.

Имән ишек бүген дә нык, таза,
Ватып керермен дип уйлама,
Эчтән-тыштан бикләр ышанычлы,
Ә тоткалар – нәфис урама.

Имән капкачларын ачып куеп,
Ерак чорлар аша яктырып,
Тәрәзәсе безнең бу заманга
Сәерсенеп карый, ятсынып.

Бердәнбер бу җыйнак тәрәзәгә
Кергән күпме таңнар яктысы.
Монда килеп күпме егет баккан,
Күрермен дип күңел аккошын.

И булган бит ерак үткәннәрдә
Ак келәтнең шанлы чаклары!
Ул чакларның изге хатирәсен
Рәхмәт, тарих безгә саклады.

Бу нигездә кызлар бик күп үскән,
Һәрберсен дә буйга җиткәчтен
Күчергәннәр җәйгә ак келәткә,
Зурлап шулай яшьлек иртәсен.

Бу келәттән очкан һәр кыз бала
Бик бәхетле торган кияүдә.
Татарлыгын һич тә җуймаганнар,
Торсалар да хәтта Мәскәүдә.

Ак келәттә мине моңнар сара,
Җанланалар үткән еллары;
Чытлыкланып көлү тавышына
Кушылып китә чулпы чыңлавы.

Кашагада торган сөлгеләрдә
Чәчәк ата чиккән гөлләре,
Тыйнак кына җыйнак бер җыр килә,
Бергә туплап бөтен серләрне.

Борынгыдан килгән нигеземдә,
Ап-ак бәхет, ап-ак көн теләп,
Бүгенгечә җылы нурлар чәчә
Сафлык тулы якты ак келәт.

Кызлар нәфислеген һаман саклый
Ак келәтнең эчке аклыгы.
Һәр карышта алар кул җылысы,
Һәр карышта алар сафлыгы.
*Әләли – сөенечне белдерә торган ымлык.*
26.08.2013

**Тарланма ла, җаным**

---

*Юк, түбән калмас бу җан: фитратта гали булган ул.*
***Г.Тукай***

Тарланма ла, җаным, һич зарланма,
Кунак кына бит син тәнемдә.
Әлмисакта ничек бөек булсаң,
Кал син һаман шундый хәлеңдә.

Раббың сиңа тырышып яшәү өчен
Фанилыкта биргән барсын да:
Синең өчен якты кояш балкый,
Гөлләр чәчәк ата каршыңда.

Синең өчен һава шундый иркен,
Үзеннән-үзе алына һәр сулыш.
Ә күңелгә бөтен дөнья сыя,
Акыл белән матур бу тормыш.

Бар җаннарны Раббың гадел сыный
Һәр гамәлдә, хистә, һәр эштә.
Һәр кешегә аерым билгеләнгән
Ике иңдә ике фәрештә.

Зарланма ла, җаным, һич тарланма,
Шөкерләр ит берүк Раббыңа:
Кайтасылар бар бит бакыйлыкка,
Җавап бирәселәр барсына.
*Фитратта – яратылганда, әлмисакта*
*Гали – бөек*
24.08.2013
**Динә Гарипова**

Ул һаман да шулай җырлый иде,
Һаман шулай иде тавышы,
Яшел Үзән моңа күнгән иде,
Гаҗәпләнми иде бер кеше.

Ләкин кинәт хәйран бер хәл булды:
Ул җырлады барып Мүскәүгә
Шул ук тавыш белән һәм күмелде
Көтелмәгән данга-мактауга.

Алай гына түгел, Динәбезне
Чакрып алды үзенә Аурупа.
Тавышына илләр таңга калды,
Даны китте дөнья буйлата.

Үз җирендә кеше солтан түгел,
Дан-дәрәҗә алу бик авыр.
Чын талантны дөнья барыбер күрә,
Татар кебек булса нык, сабыр.
03.09.2013

**Муллаларга мөрәҗәгать**

*Өч әйбер диндә юк, әмма динне саклый: берсе – милли тел, икенчесе милли гореф, өченчесе – милли кием.*

***Шиһабетдин Мәрҗани***

Без, муллалар, зинһар, бердәм булыйк,
Яхшы аерыйк акны карадан;
Шигырьләрне, җырны тоташ тыймыйк,
Хикмәт эзләп алыйк алардан.

Хикмәт тулы затлы шигырьләрне
Пәйгамбәр дә бирелеп тыңлаган,
Кеше җанын назлап сафлый торган
Якты аһәңнәрне тыймаган.

Болгар бабалар да “Бәдәвам”ны
Шигырь белән бәян иткәннәр,
Коръәндәге изге мәгънәләрне
Көйгә салып, дөнья көткәннәр.

Без, муллалар, нәфес колы булмыйк,
Мал байлыгы булсын чамалы,
Тулы иман, гүзәл әхлак кына
Аклый ала безнең чалманы.

Без, муллалар, зинһар, бердәм булыйк
Адаштыргыч фани дөньяда,
Иң әүвәле үзебез адашмыйча
Намус белән яшик һәркайда.

Без, муллалар, зинһар, уяу булыйк,
Тигез җирдә түмгәк ясамыйк,
Шәйтан бакчасына ялгыш кереп,

Җимешләрен урлап ашамыйк.

Без, муллалар, үрнәк затлар булыйк,
Аллаһыга гына сыеныйк,
Аллаһ кушканнарны бердәм үтик,
Тыйганнардан бердәм тыелыйк.

Дин белән фән бердәмлеген яклап,
Без, муллалар, булыйк зыялы,
Фәннәр казанышын кире каксак,
Халык күрер аның зыянын.

Алгарышның алгы сызыгында
Дин иреген саклыйк кадерләп.
Без – Кол Гали, Мәрҗаниле халык,
Югалмасын безнең хәтерләр.

Татар телен саклыйк изге итеп,
Телебезгә итмик хыянәт.
Туган телдә булса вәгазь-дәгъвәт,
Илебезгә иңәр бәрәкәт.

Без, муллалар, кардәш вә туганнар,
Сәламләшик күзгә-күз карап;
Ышанычын яулыйк халкыбызның,
Сүзебезне тотыйк кыскарак.
27.11.2012

**Гомеремнең кышы**

Гомеремнең кышы нинди гүзәл!
Үткәннәрдән күңел канәгать:
Аклык, сафлык белән туп-тулы ул,
Миңа җиткән шушы бәрәкәт.

Табигатьтә кышлардан соң тагын
Яңа язлар киләалмашка.
Минем язым булып, оныкларым
Җыры белән гөрләр бакча.

12.08.2013

**Шигырьгә**

*Сүзләр, сүзләр! Нигә кирәк иде*
*Сезнең белән мондый танышлык?*
*Хәзер миңа сезнең аршын белән*
*Үлчәнмәгән аваз, тавыш юк.*
***Әнвәр Давыдов***

Гомерем буе озата бардың мине,
Хисләремә исем табып.
Югыйсә бит, дөнья көтәр өчен,
Берни булмый синнән алып.

Бары сүзләр генә, сүзләр генә,
Сүзләр генә бар байлыгың.
Үзеңә бөтен дөнья сыеп бетә,

Чәчәк ата татарлыгым.

Күрсәтәсең яшерен хикмәтләрен
Гади генә нәрсәләрнең
Һәм ачасың олы, зур мәгънәсен
Бу дөньяда яшәүләрнең.

2013

**Чакыру**

(2013 елның 30 июнендә Мулла Илендә яңа мәчет ачу тантанасында сөйләгән шигырем)

*Кил, кил, кем булсаң да, кил,*
*Безнең рухи мәктәп өметсез түгел,*
*Йөз тәүбәңне бозган булсаң да, кил.*
***Җәләлетдин Руми** (бөек шагыйрь һәм хикмәт иясе)*

Раббыбызга мең-мең шөкер, җәмәгать,
Кабул булды безнең теләк һәм ният:
Яңа мәчет – каршыбызда, ниһаять,
Корган өчен халкыбызга зур рәхмәт.

Мәчет салу – иң җаваплы, изге эш,
Әҗерләре барыр гомерең буена,
Үлгәчтен дә һич киселмәс, өзелмәс,
Ирешеп торыр мәрхүмнәрнең рухына.

Мәчет ачу – һәйкәл ачу түгелдер,
Син мәчетне шунда йөреп сөендер.
Мәчет, көн дә анда намаз укылса,
Төннәрендә тәрәзендә ут булса,

Хәер-дога кылып торыр авылга,
Рәхәтләнеп йөрер халык хак юлда.
Аллаһыны монда зикер итсәләр,
Бер Аңардан рәхимлекләр көтсәләр,

Яннарына фәрештәләр җыелыр,
Шулар өчен кылыр алар догалар,
Аллаһыдан ярлыкауны сорарлар,
Җиңеләеп китәр шунда бар җаннар.

Мәчет ачу – һәйкәл ачу түгелдер,
Күренешкә корылмады бу бина.
Без булмасак көн дә монда намазда
Мәчет рәнҗер аңа, сиңа һәм миңа.

Кил, кардәшем, кил мәчеткә, тартынма,
Кил бәхеткә – Аллаһының йортына,
Аллаһының әмерен үтәү өчен кил,
Пәйгамбәрнең шәфәгате өчен кил.

Кил дә күркәм сәлам белән сәламлә,
Китәр тавышың барлык галәмгә.
Әйт, кардәшем: “Әссәләмүгаләйкем!”
Раббың бирсен хәерле, якты көн.

Дөнья  зәвыкларын тышта калдыр да
Кер, чордашым, дустым, Аллаһ йортына.
Монда пакьлек, монда тынлык, иминлек,
Монда эреп юкка чыга мин-минлек.

Итагать кыл мөнбәрдәге затка син,
Дикъкать белән тыңлап утыр һәр сүзен,
Әүлия дип уйла аны эчеңнән,
Ихтирамны һич чыгарма исеңнән.

Итагать ит мөнбәрдәге затка син,
Аллаһ аңа шундый хикмәт бирәдер:
Ул, Раббының нуры белән нурланып,
Без күрмәгән нәрсәләрне күрәдер.

Монда иңгә-иң торып тыгыз бер сафта
Сөюең артыр кешеләргә карата,
Кешеләр дә сине шулай яратыр,
Кеше сөйгәннәрне Аллаһ ярата.

Кил, чордашым, кил мәчеткә, тартынма,
Кил бәхеткә – Аллаһының йортына.
Үсмерме син – яңа яши башлаган,
Аксакалмы – тормыш читкә ташлаган,

Кил әле син, кил мәчеткә, кардәшем,
Кем булсаң да, йомшак итеп дәшәрмен.
Син башлыкмы – дәрәҗәле урында,
Син дәрвишме – авыр тормыш юлында,

Дүрт ягыңны кайгы-хәсрәт алганмы,
Өмет утың тәмам сүнеп калганмы.
Кил, кардәшем, кил мәчеткә, бүген кил,
Киләчәгең бүгеннән үк күреп кил.

Кил, кардәшем, замандашым, мәчеткә,
Бу юл илтәр сине олуг бәхеткә.
Уйланырсың, сафланырсың, кардәшем,
Кем булсаң да йомшак итеп дәшәрмен.

Йөз тәүбәңне бозган булсаң да син,
Бер кирәксез кеше булып калсаң да син,
Мәчеткә кил тәвәккәлләп син бүген,
Монда йөргән кеше өметсез түгел,
Яктырып калыр ул тутыккан күңел.
29.06.2013

*****

Вәгазь сөйләү артык кыен түгел,
Китапларым, шөкер, җитәрлек.
Китаплардан күп мисаллар табам
Кешеләргә тәэсир итәрлек.

Иң кыены шунда: изгелеккә
Үзем мисал була аламмы?
Гомеремдә ни гамәлләр кылдым
Аклый алыр хәтле чалмамны?

*********
Гашыйк булу – тулы бер могҗиза,
Гашыйк булу – Ходай бүләге.
Шул бәхетне җуймый саклау өчен
Күпләр белми нәрсә кирәген.
*********
Әллә ничә күке, күзгә күренеп,
Озын гомер миңа күкелди.
Һәркайсына күңел рәхмәт әйтә:
Әле сез бар җирдә, шөкер, ди.
**Ник булмасын җирдә хакыйкать!**
Ник булмасын җирдә хакыйкать!
Зөя һаман Иделгә коя.
Ана күке һаман күкәен
Басарга дип чит кошка куя.
01.09.2013
**Әтәч тавышы**
Бүген тынлык шундый тансык нәрсә,
Бүген тавыш патша дөньяга.
Эфир гүли, миллион мотор гөрли,
Кеше гөҗли кая карама.

Бертуктаусыз хәтсез җыр агыла,
Вакыт әйтә хәтсез дикторлар...
Әтәч тавышын кешеләр онытканнар,
Пульс үлчәп чаба докторлар.
06.05.2013
**Әгәр Тукай...**
Әгәр Тукай озын гомер кичкән булса,
Инкыйлабтан соңра ул да
Гафурича
Кызыл шигырь язган булыр иде,
Үзен мичкәдәге дары белән тиңләп
Зур сүз әйткән бөек юлбашчыны мактап.
Ул чагында менә бу урында
Һәйкәл булып Тукай түгел,
Башка берәү торыр иде
Инкыйлабка кадәр
Үлгәннәрнең арасыннан.
12.05.2013
**Кыска белән озын бер түгел**
Мең яшәгән затлар барбер үлгән,
“Кайда Карун, кайда Локман?!” – дибез.
Ләкин барбер мең яшәргә тели күңел,
Кыска белән озын бер түгел.
01.02.2013

**Патша үзе өйгә керә**
Хәзер рәхәт:
Патша үзе өйгә керә,
Халык мәнфәгатен сөйләп бирә,
Бөтен кеше үз патшасын күреп белә,
Ара фәкать ике адым гына.
26.12.2007
**Бик кыен булса да ялгызың**
Син күргән, син белгән кешеләр
Берсе дә намазда түгелләр.
Мәхәлләң туп-тулы ир-атлар
Кайчан соң мәчеткә йөрерләр?!

Бик кыен булса да ялгызың,
Туктаусыз намазга чакыр син.
Чын иман, хакыйкать – бер генә,
Кешеләр күңеле яктырсын.
03.09.2013
**Күктә һаман кояш йөри**
Тоелганча, күренгәнчә без яшибез,
Алай түгеллеген белсәк тә.
Офыкларга һаман барып җитәлмибез,
Җирләр тора яссы түшәктән.

Безнең өстә тора зәңгәр күк гөмбәзе,
Ерак түгел кебек күренә.
Аяз төндә аны хәтсез йолдыз сара,
Җидегәннең суы түгелә.

Әйләнүен җирнең бер дә сизмибез без,
Кояш һаман йөри күк буйлап.
Ай бер тула, тагын кими, нигә шулай?
Юк, торасы килми күп уйлап.

Тоелганча, күренгәнчә без яшибез,
Шуңа кызык, серле бу тормыш.
09.08.2013
**Мәңге яшәү уе**
Картаймыча мәңге яшәү уе
Биләп алды бүген күңелне.
Ләкин, шундый татлы булса да ул,
Мондый уйдан бик тиз сүрелдем.

Бүгенче көн, менә шушы вакыт,
Җанның-тәннең шушы халәте,
Мәңге яшәү уе биләп алган
Гомеремнең шушы сәгате

Һәм күкләрнең мондый аяз чагы,
Мондый җилсез чагы җирләрнең
Әгәр үтмәс булып, мин чыннан да
Мәңгелектә калсам нишләрмен?

Картаймыча мәңге яшәү уен
Кудым шунда тизрәк башымнан,
Хәрәкәттә генә бәрәкәт, дип,
Иртәгесе көнгә ашыгам.
02.09.2013

**Бәхет кошы**

Киләчәк ул – шундый бәхет кошы:
Алдап тотар өчен халыкны,
Уйлап тапкан аны хакимият,
Яшереп күздән чынны, хаклыкны.

Балачактан бирле мин шул кошка
Барып җитәр өчен ашкынам.
Ә кош һаман мине көтә сыман
Мин белмәгән офык артында.

Мин китәмен, син каласың миннән,
Ялтыравык якты киләчәк.
Миннән соң да синең белән алдап
Күпме түрә сафа сөрәчәк,
Һәм миндәйләр җәфа чигәчәк.өтәгә
02.09.2013

**Картайдык дип һич кайгырмыйк**

Кышлар тау-тау кар яудыра,
Язлар дымлы торсын өчен;
Язлар бердәм яфрак яра,
Җәйләр яшел булсын өчен.

Җәйләр ялкынланып балкый,
Көзләр алтын яксын өчен;
Көзләр җирне чишендерә,
Кышлар юрган япсын өчен.

Кышлар язны куып килә,
Язлар – җәйне, җәйләр – көзне.
Картайдык дип һич кайгырмыйк,
Яшьләр куып килә безне.
23.01.2008

**Хөрмәтем зур**

Тыштан миңа матур күренгәннәр,
Мин яратам сезне, яратам.
Матур күренү өчен
Күпме тырышырга кирәк,
Хөрмәтем зур сезгә карата.

Эчтән миңа ачу саклаучылар,
Мин яратам сезне, яратам.
Ачу саклау өчен
Күпме сабырлыклар кирәк,
Хөрмәтем зур сезгә карата.
22.05.2013

**Дәрестән кер эзләүчегә**
Мыскыллап көлмә, тешең ыржайтып,
Гаеп, кер эзләп минем дәрестән.
Яхшы-яманны язып баралар
Ике иңемдә ике фәрештә.

Аларда фәкать хаклык-хакыйкать,
Мин шул хакыйкать һәм намус колы.
Синең язганың – ялган уйдырма,
Үч, кенә, гайбәт, хөсетлек тулы.
02.08.2013

**Гаҗәпләнү**
Карап баксаң, бөтен нәрсә кызык.
Менә бармак башы. Күпме сызык
Тезелешкән анда сыр-сыр булып.
Иң гаҗәбе аның әле шунда:
Җиде миллиард кеше арасында
Бу рәвешле сырлар миндә генә.
08.06.2012

**Нәрсә соң ул бәхет?**
Нәрсә соң ул бәхет? Сабый чакта
Әти һәлак булган сугышның
Безгә килеп җиткән ачлыгыннан
Мине йолып калган язмышмы?

Нәрсә соң ул бәхет? Өч баласын
Яуда җуйган газиз әбиемнең,
Елый-елый сукыр калгачтын,
Соңгы өмете булып үсүемме,
Булып өйдә соңгы ир заты?
2012

**Беренче театр**
Малай чак, сугышлар барган чак.
Тәүге кат клубка кердем мин,
Тәүге кат сәхнәне күрдем мин,
Театр ләззәтен белдем мин.

Мин күргән беренче театр –
“Беренче театр” иде ул.
Халыкның күңелен күтәрде,
Клубның салкынын җиңде ул.

Аннан соң мактаулы пьесалар
Күп күрдем зур гомер юлымда,
Әмма тик “Беренче театр”
Тора гел беренче урында.
10.06.2012

**“Яр” дигән бу хикмәтле сүз**
Сулар ага, җирне яра-яра,
Ике яклап ярлар кала бара.
Күпме җаннар тәннәренә иңеп,
Кеше дигән затны хасил иткән,

Бик күп еллар шулай үтеп киткән.

Нинди ерак калган тәүге парлар –
Адәм-Һава дигән тәүге ярлар!
Ерак калган тәүге яратышу,
Күпме язлар үткән ярдан ташып.

Яратышу һаман дәвам итә,
Үз чираты һәркемгә дә җитә.
Ярсу агымсулар ярларына
Килеп баса тора яңа парлар.

Яңа язлар һаман килә бара,
Ярда таллар яңа яфрак яра.

Ярда таллар яңа яфрак яра,
Йөрәкләрдә һаман шул ук яра.
Ага сулар, җирне яра-яра,
Ике яклап ярлар кала бара.

12.05.2013

**Үземнеке – үзәктә**
Галәмнәрнең миңа иң газизе
Үзем яшәп яткан бу галәм.
Уем гизә аның киңлекләрен,
Һәр тарафка сәлам җибәрәм.

Бу галәмдә күпме галактика!
Бөтенесен хуплый акылым.
Тик үз галактикам җанга якын –
Газиз миңа Киек Каз юлым.

Галактикам тулы хәтсез йолдыз,
Һәрберсенә карыйм ис китеп.
Ләкин үз йолдызым Кояш кына
Карый миңа көлеп, үз итеп.

Кояш хозурында әйләнүче
Һәр планета миңа сөйкемле.
Ләкин Җирем минем бердәнберем
Газиз миңа әни шикелле.

Җирдә төрле-төрле кавемнәр күп,
Һәрберсенә зурдан хөрмәтем.
Үз кавемем – татар тик бердәнбер
Үзәгемне өзгән милләтем.

Җирдә төрле-төрле илләр бик күп,
Һәрберсен дә сөям, яратам.
Ләкин Татарстан өчен яшим янып,
Аның өчен генә җан атам.

Космополит та мин, шул вакытта
Чикләнмәгән ватанпәрвәр дә.
Ватанпәрвәр булып, бар галәмгә
Авылымнан сәлам җибәрәм.
2013

2013
**Шөбһәләнү**
Нинди камил, нинди нәфис килеш,
Мең- мең төрле шау чәчәктә килеш,
Хаҗәт тапмый кулланыштан төшеп,
Фәкать китапларда гына калып,
Безнең күз алдында кебек
Үле телгә әверелә бармыймы соң
Гасырларны кичкән бөек татар теле?!
03.09.2013

**Горурлану**
Мулла Илендә табигый таулар юк,
Ләкин моннан күтәрелеп, еcompleted ерактан ук
Күренеп торган, хөрмәт иткән һәр татар
Гомәр Саттар дигән гыйлем тавы бар.

Мулла Илендә табигый чишмә юк,
Ләкин, моннан башланып һәм көч алып
Ургып аккан, сибеп якты моңнар,
Гомәр Саттар дигән шигъри чишмә бар.

Мулла Илендә мәшһүр биналар юк,
Ләкин җирдә безнеңчә Колшәриф бар.
Әтиседәй моннан илһамнар алып
Иҗат иткән аны Айвар Саттар.
2013

**Васыять**
Китәр вакытларым килеп җитте,
Котылгысыз бу хәл алдыннан
Барлык уйларымны бергә туплап,
Васыять итеп сезгә калдырам.

Сез булганга миңа шундый рәхәт,
Һәм сезгә дә рәхәт мин барга.
Бу рәхәтләр кала сагынырга,
Борылып карап үткән елларга.

Варисларым минем, күз нурларым.
Дәвамнарым җирдә сез генә.
Сезгә кала торган бар байлыгым,
Бар мирасым бары бер генә.

Бар мирасым – менә шушы нигез,
Сигез гасыр безнең бабалар
Бу туфракка берегеп гомер сөргән,
Мондый байлык тагын кайда бар?!

Борынгы бу изге нигезебез –
Барчагызга уртак хәзинә.
Яшәгез сез бер дә бүлешмичә,
Тап төшерми нәсел йөзенә.

Иң зур мирас, иң зур байлык итеп
Калдырамын сезгә мин тагын
Гомерем буе җыйган һәм укыган
Меңнәрчә том татар китабын.

8.10.2013

**Халыкка хезмәт иткән йорт**

Авылдагы исән дүрт йөз йортның
Һәммәсен дә бердәй яратам.
Менә монысы тынгы бирми торган
Үзгә хисләр миндә кузгата.

Дәверләрне кичкән иске йорт бу:
Ас кат – таштан, өсте – агачтан.
Мин аңарга көн дә карап узам,
Гүя җаным шуңа тоташкан.

Серләр тулы зур-зур тәрәзләре
Бик үз итеп миңа багалар.
Ерак калган чорлар һәрберсеннән
Яшертен моң булып агалар.

Бизәкләрен җилләр өтсәләр дә,
Бу йорт һаман биек, мәһабәт.
Үзе шундый тирән уйга баткан,
Күңелендә күпме җәрәхәт.

Күпме михнәт, хәсрәт кичерсә дә,
Ул һаман да төзек, нык тора.
Аны салган кеше тырыш булган,
Гомер сөргән баеп, ялтырап.

Шуның өчен канлы инкыйлабта
Себер җибәргәннәр хуҗасын.
Ул хуҗасыз калып, ятим килеш
Тарткан бөтен авыл нужасын.

Көн-төн хезмәт иткән халык өчен
Сыендырган авыл Советын,
Монда почта, сельпо, медпункт булып,
Кабул иткән яшен һәм картын.

Сугыш вакытында детсад булып,
Сыендырды бу йорт мине дә,
Яуда әти үлгәч, ул юатты,
Ул сыйпады нәни иңемнән.

Әнә теге текә баскычлардан
Сугыш беткән көнне мин ничек

“Гитлер капут!” дип йөгереп төштем,
Иптәшләрем белән җилпенеп.

Аскы катның тимер ишекләрен
Ул көн безнең өчен ачтылар.
Монда иде бөтен колхоз малы,
Яз көнендә хәтта алма бар.

Безгә шунда алма өләштеләр,
Бәйрәм итте ятим балачак.
Шул чактагы тансык алма исе
Мәңге минем белән барачак.

Тәүге сөюемне тыңлады ул
Әнә теге купшы веранда.
Мин кыз белән кергән идем шунда
Адаштыргыч төнге буранда.

Бер ул түгел, төнге каравылчы
Тыңлап торган ишек артында.
Мыштым гына кинәт килеп чыкты,
Сәлам бирде яшьләр халкына...

Мин бу йортка көн дә карап узам,
Тып-тын гына тора чал тарих.
Тәрәзләре моңсу елмаялар,
Үткәннәргә безне кайтарып.

16.11.2013

**Бүләк сәгать**

Үлеп гашыйк иде миңа ул,
Аңлатуы моны бик авыр.
Беркөн шулай чыгып юлыма,
Сәгать тагып китте кулыма.

Үлеп гашыйк идем үзем дә,
Тик аңарга түгел – башкага.
Шул сәгатькә карап ярымның
Килүләрен көттем бакчада.

Сәгать безгә бәхет юллады –
Гөрләп узды яшьлек туйлары.
Сәгатьнең дә моңсу иясен
Бик бәхетле килде итәсем.

Өзелеп-өзелеп теләк теләдем,
Я Ходаем, раббым, булыш, дип,
Үзен үлеп сөйгән егеткә
Үлеп гашыйк булсын бу кыз, дип.

Кабул булды изге теләгем:
Безнең туйлар белән Ул бергә
Утларында янган Мәҗнүнгә

Бүләк итте үзен гомергә.

Күпме генә еллар узмады,
Сәгать кулда бер дә тузмады,
Бәлаләрдән безне саклады,
Дөрес йөрде һәрчак уклары.
7.11.2013

*****

Гыйлем алдың, гыйлем бирдең
Мәктәптә һәм мәчеттә.
Бар да илнең файдасына,
Бар да безнең бәхеткә.

Шәкертләрең авыл тулы
Бар да сиңа рәхмәтле.
Син күтәрдең, син зурладың
Безнең мәчет-мәктәпне.

2013

**Кунак кызына**

Таулар артларыннан,
Идел ярларыннан –
Таңнар туа торган тын яктан
Әкияттәге кыздай,
Серле бер йолдыздай
Килдең дә син безгә кунакка.

Зөяләрдә йөздек,
Тауга менеп йөрдек,
Урманнарны гиздек, тугайны...
Әй син, Идел кызы,
Иттең мине кызык:
Хушлашмый да китеп югалдың.

Син нишләттең мине?!
Бар әйләнә-җирне
Үзең белән киттең тутырып.
Сөйләшәбез кебек,
Серләшәбез кебек,
Зөя ярларына утырып.

Тау башында үскән,
Гасырларны кичкән
Күп парларны күргән имәнгә
Ник калдырдың, көлеп,
Ал яулыгың элеп,
Җилдерәсен дипме җилләрдә?

Көн дә карыйм шунда,
Күңелем тоташ монда
Күңелем синең белән тоташкан.

Синең кебек балкып,
Таңнар килә атып,
Сәламеңне алам кояштан.

Идел белән Зөя
Бер-берләрен сөя,
Бергә кушылыр өчен агалар.
Идел кызы бит – син,
Зөя егете – мин,
Очраштырыр безне елгалар.
21.12.2013

**Сан һәм сыйфат**
Сан ягыннан караганда
Татар – азчылык милләт.
Руслар белән чагыштырсаң,
Ул бик кечкенә, димәк.

Сыйфат ягыннан алганда,
Зур милләттән ким түгел.
Теле гаҗәп бай: булса да,
Бәхетләре тиң түгел.
2014

**Лаеклы ялда**
Бүгеннән мин үз иркемдә –
Лаеклы ялда.
Шаян дулкыннарга карап,
Утырам ярда.

Гомрем буе йортлар салдым
Ачык һавада.
Безгә күпме һәйкәл тора
Күпме калада.

Мине рәхәт ял иттереп
Уйный дулкыннар.
Ләкин шундый тын аулакта
Нидер юксынам.

Ирексездән үргә карыйм:
Анда – еракта,
Күр, яңа йорт ничек калка,
Тик миннән башка.

Анда бүген миннән башка
Эшли дусларым.
Бу лаеклы ялдан шунда
Очты уйларым.

Бүгеннән үк шашкын сагыну
Басты күңелне.
Бу лаеклы ялга ничек
Күнәрмен инде.

27.05.2014

**Өметеңне бары өзмә генә**

Бер болытсыз шыр ялангач күктә
Ялгыз кояш кызып бузарган.
Кызулыктан уңган күк зәңгәре,
Җирләр корып баткан тузанга.

Бер тамчы да яңгыр яуганы юк.
Җиребездә тоташ корылык.
Хәтта күлләр кибеп бетеп бара
Бар игеннәр килә куырылып...

...Аксакаллар, җыелып, кырга чыкты,
Яңгыр сорап, Хакка ялварды,
Намазлыкка күздән яшьләр тамды,
Чәчләр тагын күбрәк чаларды.

Үзем күрдем, үз күзләрем белән:
Офык өсте ничек яшәрде,
Сабырлыгын җуймый өмет иткән
Саф күңелләр ничек яшәрде.

Менә бит ул ничек күз алдымда
Аллаһының чиксез рәхмәте,
Өметеңне бары өзмә генә –
Килә бит ул бәхет сәгате.

Күр, кабарып, күпереп, тау-тау булып,
Безнең өскә килә болытлар,
Кояшны да каплап үтте алар,
Җитте нинди хозур минутлар.

Кызган җирне рәхәт салкынайтып,
Җилпенделәр яңгыр җилләре,
Шаярдылар очрып тузаннарны,
Сыйпадылар кипкән битләрне.

Офыклардан офыкларга сузылып,
Уйнадылар ялт-йолт яшеннәр.
Гөлдердәде күкләр, чытырдады,
Гөрселдәде дәһшәт эчендә.

Тансык бәхет булып шыбырдады
Эре-эре тәүге тамчылар,
Һәм чиләкләп койды, гөрләвекләр,
Күлдәвекләр ясап каршымда.

Көнбатышта менә күк ачылды,
Кояш чыкты болыт артыннан,
Гигант прожектор яктысында
Яңгыр ява җем-җем ялтырап.

Даһи кояш, бөек рәссам кебек,
Буяуларның салып күп төрен,
Узып киткән болыт өсләренә
Корып куйды салават күперен.

Могҗизалы зур тантана күктә –
Аллы-гөлле хәйран көянтә,
Әкияттәге кызны искә төшереп,
Матур булып балкый бигрәк тә.

Могҗизаи зур тантана күктә:
Галәмәт зур дуга нурлана,
Әкияттәге атны искә төшереп,
Күз алдында Алып җанлана.

Могҗизалы зур тантана күктә:
Җиде катлы җәя тартылган,
Һәм Таңбатыр килеп чыгар төсле
Карамалы таулар артыннан.

Могҗизалы зур тантана күктә:
Аллы-гөлле ярымәйләнә
Чакрып тора безне теге якка –
Әкияттәге серле бәйрәмгә.

Теге якта гүя әбелхәят,
Тоташ бәхет, тоташ сәгадәт,
Бар хыяллар чынга ашар кебек,
Шулай була менә чын сәнгать.

Гүя күренә безгә ахирәти
Сират күперенең мисалы –
Тәмуг белән оҗмах арасында
Гаделлекнең бөек мизаны.

Җирем бүген гүя яшел бишек
Бөгәҗәсе күкне иңләгән.
Бар яшеллек, татлы ширбәт эчеп,
Хуш ис сулап, рәхәт тирбәлә.

Шул бишектә мин дә сабый бала кебек
Бар дөньямны онытып елмаям.
Тирбәләмен бәү-бәү, елмаям.
Әниемнең бишек җыры килә
Бик еракта калган еллардан.

20.06.2014

**Коксартроз** *(1)*
Үтеп китте йөргән чагым җил-җил атлап,
Барып кердем табибыма мин аксаклап.
Әйтте табиб: “Аягыңда, дип, коксартроз,
Бот башыңа дыңгычланып утырган тоз

Ни кызганыч, моңарга юк һичбер дәва,
Таяк кына сиңа ярдәм итә ала.
Яшәгәнсең аягыңны аямыйча,
Авыр эштән, салкыннардан сакламыйча.”

Күз алдымнан үтте шунда узганнарым,
Сугыш чорын кичеп чыккан балачагым.
Кар китүгә яланаяк кырга чыгып
Бата-чума “липушки” лар җыйганнарым.

Аякларның сеңерләре өзелгәнче
Уфалланы өстерәвем тауга каршы,
Бергә җыйсаң, мең чакрымнан артып китәр
Минем арттан калган печән покослары.

Аркам сыгылып бишәр потлы капчыклардан
Күпме мендем биек-биек баскычлардан.
Аякларны чыныктырды урта мәктәп,
Йөрдем көн дә унбиш чакрым җәяү таптап.

Кигән килеш җүләр галуш, эрҗин итек,
Җанны өтте салкын быкрак лач-лоч килеп.
Ягылмаган классларда селкенмичә
Алты сәгать парталарда утырулар.

Ә аннары чиксез фидакарьлек белән
Гомрем буе баскан килеш укытулар.
Көрәк белән гектарлаган җир сөргәнем,
Колхоз кырын иңләп суган үстергәнем.
Җилкәләрдән үткән күпме бүрәнәләр
Йөзәрләгән йорт салганда өмәләрдә.

Мин кибеткә кереп алдым кул таягы,
Шулай итеп, булды минем өч аягым.
Барам менә авыл буйлап өч аяклап,
Таягыма рәхмәт укып, кат-кат мактап.

Дуслар мине чын ихластан бик жәллиләр,
Йөрмә болай азапланып, аксап диләр,
Рәхәтләнеп өйдә, диләр, утыр гына,
Лаек булып яшә, диләр, картлыгыңа.

Ә мин йөрим үҗәтләнеп, чөнки беләм:
Рәхәтләнеп һаман өйдә утыру белән
Билем сызлар, әйтер дуслар чын йөрәктән:
Утырма, дип, тик ят кына тын түшәктә.

Ята-ята арып бетсәм, дуслар тагын
Жәлләр мине һәм әйтерләр бөтен яктан:
“Кайгырма, дус, фани дөнья үтәр-китәр,
Ахирәттә йөрү язсын җил-җил атлап.”

Ә хәзергә йөрим әле авыл буйлап
Ак өметләр белән якты уйлар уйлап.

Ялгызыма тугры юлдаш, таянычым,
Куанычым, бердәнберем, юанычым,
Мең-мең рәхмәт сиңа, әй өченче аяк,
Нык тоткалы, ышанычлы күндәм таяк.

Кая куйсам, шунда тып-тын нык торасың,
Серләремне саклап, мин чыкканны көтеп.
Түрәләргә иелмисең, бөгелмисең,
Төз, туры син, хакыйкатьнең үзе кебек.

Кара төндә, томаннарда калган чакта,
Хәтәр юлда, бозда-туңда тайган чакта,
Ектырмыйча алып бардың, нурлы маяк,
Таянып ял иттем сиңа, әй култаяк.

Ишан-шагыйрь (2) ике гасыр элек моннан
Таягына мәдхияләр язган булган.
Бер дә үзгәрмәгән бугай җиһан-заман,
Мин дә шулай таягымны мактап язам.

03.11.2014

1. *Коксартроз* – буыннар авыруының бер төре
2. *Ишан-шагыйрь* – Һибатулла Салихов

**Мулла Иле китапханәсенә**

Әлифбаны тәмам итү белән
Сиңа килдем, китап сарае.
Ничек сөеп каршыладың мине –
Сугыш чорының ятим баласын.

Төрле заман, төрле кыйтгалар
Монда урын алган һәр әдип.
Киштәләрдән миңа эндәштеләр:
“Мине укы, мине укы!” – дип.

Сайлап-нитеп тормый, комсызланып,
Кулга кергән берен укыдым.
Шулар булды ихлас юлдашларым,
Шулар булды рухи докторым.

Әй авылның рухи мәгарәсе,
Әй мөкатдәс гыйлем сараем!
Сигез яшьтән алып сиксәнгәчә
Гомрем юлын син бит нурладың.

Күпме сарайларны мин күрмәдем,
Күпме хәйран калып йөрмәдем,
Тик аларның берсенә генә дә
Алыштырмый сине йөрәгем.

Син, киңәйтеп авылым офыкларын,
Бар дөньяны ачып күрсәттең;
Үткенләтеп акыл күзләремне,
Йолдызларга мине үрләттең.

Китап тәмен иңдер балаларга,
Яраттырып җирне, илемне.
Китапларың, кулдан-кулга күчеп,
Берләштерсен барлык күңелне.
08.12.2014

**Китаплар исемнәре**

“Кичке шәфәкъ” “Бәхет үзәне”нә
Сирпегәндә соңгы нурларын,
“Яшьлек яши безнең йөрәктә” дип
Көйлим “Мулла Иле моңнары”н.
2014

***

Фани дөнья беткәнгә ник кайгырырга –
Беткән төшкә көтеп тора теге дөнья.
2014

***

Идеал эзләп үтте гомер,
Ярый әле тапмадым.
Тапкан булсам җуйган булыр идем
Яшәвемнең максатын.
2014

**Ак биләүдән ак кәфенгә чаклы**

Җитмеш елның җитмеш язы миндә,
Бар ташкыннар бергә кушылып
Ургып ага гомер үзәненнән
Яшәвемне җирдә хуш кылып.

Җитмеш елның җитмеш җәе миндә,
Бар чәчәкләр бергә җыелып,
Гомер аланымны балкыталар,
Күңелемне рәхәт җылытып.

Җитмеш елның җитмеш көзе миндә,
Бар яфраклар бергә коелып
Түшәләләр гомер юлларыма,
Күңелемдә шуңа моң тулы.

Җитмеш елның җитмеш кышы миндә,
Бөтерелә ап-ак карлары...
Ак биләүдән ак кәфенгә чаклы
Мин шулардан алам дәваны.
2014

**Зөя каласы**

Бар дөньяны үзенә җәлеп итә
Утраудагы серле бу кала.
Чиркәүләрнең купшы гөмбәзләре
Ялтыр-йолтыр суда чайкала.

Гүзәллекне күреп таңга кала
Һәр тарфтан килгән туристлар.
Ташпулатлар асларында ләкин
Күзгә күренмәгән тарих бар.

Бу чиркәүләр әле һич булмаган,
Яңа Әмин дигән зур авыл
Балкып торган монда тыныч кына,
Мәчет нурларына уралып.

Мулла Иле белән Яңа Әмин
Кыз бирешеп яшәп ятканнар.
Кинәт афәт килгән. Сулар гына
Берни булмагандай акканнар.

Күңел әйтә бүген: хаклык өчен
Ачыгыз, дип, казып нигезен,
Уртасында шушы тыюлыкның
Яңа Әмин авылы музеен.

Тыюлыкта бу эш тыелмасын,
Янәшәдә торсын мәчет тә.
Турист халкы күрсен: нәрсә илтә
Татулыкка безне, бәхеткә.
13.01.2015

**Төннәр буе бездә таңнар тора**

Төн йокламый Зөя – һаман ага,
Мин дә төнен басып ярларга,
Уйларыма батып карап торам
Тып-тын йоклап яткан тауларга.

Төн буена бездә таңнар тора,
Бер дә сүнми таңнар яктысы.
Таңнар булып күренеп тора шулай
Казан утларының балкышы.

Төн буена тибри тын Зөядә
Шул балкышның алсу шәүләсе.
Төннәремә рәхәт тынгы биреп,
Чал Казаным мәңге яшәсен.

Өметнең дә төне булмый, диләр,
Өмет уты җанда яшәсен.
2015

**Тәндә җаным**

Тәндә җаным тагын күпме
Кунак булып торасын
Синнән сорап булмый, күке,
Бу тик халык йоласы.

Тәндә җаным бар чагында

Нинди гамәл кылганым
Аллаһ кына белә бары,
Юлдаш булсын иманым.
2015

**Мәчет бар чагында**

Мәчет бар чагында түбән калмас бу җан
Караларга батмас, керсез калыр вөҗдан.
Көн дә сөенеп йөргән мәчет бар чагында
Дөнья алдый алмас чуар кочагында.
Бөек Раббысына Әлмисакта биргән
Вәгъдәсен җан җуймас – саклар хәтәр җилдән.
Раббысына сыенып, Аңа тик таянып,
Сынауларын кичәр, түзем-сабыр кылып.
2015

**Кат-кат уйла**

Кеше алдында сөйләү өчен
Яраклымы шигырең?
Башың тотып кат-кат уйла:
Мәгънәлеме фикерең?

Тыңлаучылар игътибарын
Әрәм итеп бер юкка
Салдырмыйсың микән сөйләп
Ата каздан йомырка?
2015

**Бер төнлек кабер**

Һәр үткән көнең – үзе бер гомер,
Таңда ул туа, ә кичен сүнә.
Төн, йомгак ясап, шушы бер көнгә
Кабер тормышын искә төшерә.

Үкен, тәүбә ит, бер дә соң түгел,
Барлык хатаны төзәтеп була.
Бу әле бары – бер төнлек кабер,
Ак өмет булып, яңа көн туа.
2015

**Шаһитлар**

Атабыз Адәм, анабыз Һава
Җәннәттән төшкәч бу җир йөзенә,
Күкләр, нәкъ бүген без күргән кебек,
Күренеп торган алар күзенә.

Бу тәүге парга кояш елмайган,
Иркәләп-назлап кочып җылыткан,
Имин төн биреп, йолдызлар баккан,
Якын дус булып, ак ай калыккан.

Бу йолдызларга, айга, кояшка
Түгелеп калган алар күз нуры.
Шул нурлар безгә мең-мең ел аша
Килеп торалар якты моң булып.

Атабыз Адәм, анабыз Һава
Йөргән эзләрне җир йоткан күптән.
Шаһитлар булып, безгә нур коя
Ай белән кояш, йолдызлар күктән.
2015

**Казан университеты**

Татар халкын алга сөргән чорың
Бар иде бит, Университет.
Рәсәйдәге вузлар арсында
Күрдек сине Гулливер итеп.

Татарлыгын горур саклап, синдә
Гыйлем җыйган Каюм Насыйри.
Китапханәң аның хезмәтләрен
Күз карасы итеп асырый.

Кырык дүрттә, сугышка үч итеп,
Чынга ашырып галим теләген,
Ачтың зурлап чын татарча бүлек,
Куандырып халык йөрәген.

Мин дә канат чыныктырдым синдә
Җепшеклек дип йөргән елларда.
Саф татарча горур сөйләшүләр
Яңгырап торды синең залларда.

Үзәк – үзәк инде ни әйтсәң дә,
Урамы да үрдә, биектә.
Бер башында Син – гасырлар даны,
Бер башында Кремль, Сөембикә.

Янда гына, татфак белән ярышып,
Гомер сөрде матбугат йорты,
Чәчәк атты фәннәр академиясе,
Милли китаплар ташпулаты.

Татфак өчен моннан да кулайрак
Бер урын юк изге Казанда.
Бу үрдә бит йөргән Колшәрифләр,
Ханнар йөргән теге заманда.

Монда – тарих. Пъедесталда тора
Ашкынулы горур Ульянов.
Ә без башка юлга кереп киттек,
Аннан утырып уйлар уйладык.

Мин Казанга килгәч, озак-озак
Моңсуланып утырам каршыңда.
Монда миңа Сибгать Хәким җитми,
Латыйф Җәләй җитми җаныма.

Татар халкын алга сөргән чорың

Сагындыра, Университет.
Рәсәйдә бар татарлар сине
Күрә иде Гулливер итеп.

2015

**Җиңү бәйрәмендә**

Мин җитмеш ел чыктым бу бәйрәмгә,
Исән булсам, тагын чыгармын.
Монда чыгып, күңелемне басам,
Чыгалмасам – ничек чыдармын.

Бу бәйрәмдә хакым зур минем дә,
Чиксез нәфрәт орып фашистка,
Сәйфетдиннең гаярь өч улы да
Батырларча үлгән сугышта.

Исемнәре монда – ташта тора
Өч йөз шәһит белән беррәттән.
Өч йөз ветеран килә иде монда –
Бөтенесе бүген зиратта.

Мин яшәдем, эти кебек күреп,
Башым иеп ветераннарга.
Балаларын укытып, полк улыдай
Доклад сөйләп йөрдем аларга.

Сәйфетдиннең гайрь өч улының
Гүрләре юк безнең зиратта.
Бер тезләнеп алар яткан җиргә
Дога кылыр идем дә кана –
Каберләре бездән еракта.

Рухларына көн дә Коръән укыйм,
Шәһит киткәннәрнең җаннары
Яныбызга кайта җыйнаулашып,
Без күрмибез генә аларны.

Шәһит киткәннәргә киртәләр юк,
Шәһит китү – иман билгесе.
Ватаныңны сөю – иманыңның
Иң мөкатдәс рәүшан көзгесе.

Шушы җиңү соңгы җиңү булсын,
Сугыш башка мәңге булмасын.
Бу балалар үсеп йөзгә җитсен,
Тыныч хезмәт илне нурласын.

4.05.2015

**Май нигъмәтләре**

Тыңлап калыйк әле, тып-тын калып,
Май күгенең тәүге күкрәүләрен;
Карап калыйк әле аллы-гөлле
Салават күпере сурәтләрен.

Тыңлап калыйк әле урман эчен
Моңсулатып кәккүк кычкырганын,
Карап калыйк әле сыерчыкларның
Оялардан бала очырганын.

Тыңлап калыйк әле сандугачның
Төнге бакчадагы чутылдавын;
Карап калыйк әле ландышларның
Чыклы энҗеләре елтыравын.

Тыңлап калыйк әле аулак күлдә
Бакаларның кубыз чиерткәнен.
Иснәп калыйк әле шомырт карын,
Ел буена җитсен сихәтләре.

2015

**Гомәр Саттаров**

Тарих катламнарын көн-төн актарып,
Үткәннәрне бүгенгегә кайтарып,
Табышларын җыйды галим бөртекләп,
Һәр ачышын бәян итте җентекләп.

Чытырманнар аша кыю юл салып,
Ул үзенә һәйкәл салды – фән тавын.
Монда аның гомеренең дәвамы,
Соң чиккәчә халкын сөеп зурлавы.

Җир йөзендә һәр кыйтгада татар бар,
Кайда татар, шунда безнең Саттар бар.
Яңа туган һәр балага исемне
Саттар китабыннан алып кушалар.

2015

**Татар сүзләре**

Сүзләр никадәрле төрләнсә дә,
Тамырлары үзгәрешсез кала.
Күндәм кушымчалар җайлы гына
Ялганышып бер-бер артлы тезелеп бара.

Берлек, бердәм, бердәй, берәгәйле,
Берәмтекләп, берәү, беректерү,
Беренчелек, берүк, берәм-сәрәм,
Берләштерү, берсе, беркеттерү.

2015

**Мулла Иле**

Тау ягында, Зөя тугаенда,
Алтмыш кына чакрым Казаннан
Җәйрәп ята гүзәл Мулла Илем,
Муллык белән шөһрәт казанган.

Ул да Казан кебек чал тарихлы,
Гасырларга кертеп өлешен,
Мең яшәгән Казан белән ярышып,
Сигез йөзгә җитеп килеше.

Әрә буйлап килеп тын Зөягә,
Ә Зөядән чыгып Иделгә,
Безнең халык, каекларда йөреп,
Казан белән булган гел бергә.

Төннәр буе тора безнең күктә
Казан утларының балкышы,
Һәм таңнар да бездә шуннан ата,
Кояш чыга, сибеп яктысын.

Безнең тарих булып Зөя ага,
Явыз Иван йөзгән сулар бу,
Мең башларны өзгән шул явызның
Казасына түзгән сулар бу.

Нинди гүзәл бүген утрау-кала!
Безнең якта нинди тарих бар!
Гүзәллекне күреп таңга кала
Һәр тарафтан килгән туристлар.

Ыгы зыгы килеп шаулап торган,
Тынгысызлык тулы дөньяда
Яшәп ятам иркен авылымда,
Чиксез рәхмәтлемен аңарга.

Гомер сөрәм Олы Урамында,
Борынгыдан килгән нигездә.
Гасырларга басып йөрим көн дә
Җиде бабам белән бер эздән.

Бакчам артындагы имән кебек,
Минем дә бит туган туфракта
Тамырларым, хәтсез тармакланып,
Бик тирәнгә киткән, еракка.

Яратам мин, нәкъ бабамнар кебек,
Утырырга капка төбендә
Оныкларның сөйләшүен тыңлап
Нәкъ безнеңчә – татар телендә.

Оныкларны алып кырга чыгам,
Күз күреме җитми арбашка.
Тук башаклар, назлы кыштырдашып,
Барысы бергә үрли кояшка.

Тимер юлдан ашыгып поезд чаба,
Машиналар агыла кыр аша.
Мулла Иле илдә ялгыз түгел,
Бөтен Рәсәй белән тоташкан.

Бездә әле кыргый әрәмәләр

Нәкъ борынгы хәлдә саклана.
Кыргый кошлар йөзгән тып-тын күлләр
Төнбоеклар белән каплана.

Әрә суы, ераклардан килеп,
Зөя белән бездә кавыша,
Кавышуны котлап бии таллар,
Сайрый кошлар, шаулый камышлар.

Нинди хозур, тау башына менеп,
Карап тору ерак-еракка!
Биниһая иркен киңлекләрне
Күңел ала шунда кочаклап.

Чакрымнарга сузып урамнарын,
Иркәләнеп тигез үзәндә,
Җәйрәп ята шанлы Мулла Илем,
Рәхәт биреп безнең күзләргә.

Үтсәләр дә баштан авыр хәлләр,
Булсалар еллар болгавыр,
Бирешмәдең, газиз Мулла Илем,
Син Рәсәйдә һаман зур авыл.

Зур авылда алтын куллы халкым
Яши бердәм, тыгыз тупланып.
Үз теленә зур тыюлык булып,
Бер-берсеннән куәт-нур алып.

Җуя күрмик сигез гасыр корган
Зур тарихны – рухи байлыкны.
Үкенүдән зар еламас өчен,
Тормышларын көйлик халыкның.

Казаннардан якты нурлар алып,
Матур даның белән ил гизеп,
Гасырларда яшә, Мулла Илем,
Биш йөз йортка утлар тергезеп.
*27.08.2015*

**Кар яктысы**

Рәсемдәге кебек хәрәкәтсез
Тып-тын тора кечке манзара.
Салкын шәфәкъ тып-тын сүнә бара,
Шәрә агачларны моң сара.

Караңгылык каплап китә алмый
Ак карларның тоныч яктысын.
Картлыгыма рәхәт җылылыкны
Кар яктысы бирә, ахрысы.
2015

**Кендек**

Әллә ниләр белеп үткән гомере,

Әмма үзендәге кендекнең
Ни икәнен һаман белми яши
Кирәксез бер нәрсә шикелле.
2015

**Түрәлектән киткәч**

Түрәлектән пенсиягә киттем,
Әйтте шунда дустым дөресен:
“Хәзер беркем дә түгел син,
Шуны менә үзең күрерсең.”
2015

**Илең барда һич кайгырма**

Мең йөрәккә аерым-аерым
Кагылса да мең җәрәхәт,
Ил тулаем тыныч, имин,
Ил тулаем сау-сәламәт.

Аерым-аерым кайгыларга,
Үлемнәргә тарыган чакта
Алып җылы киң кочакка
Ялгыз башны ил юата.

Шундый илең булган чакта
Каберең дә гел кадердә.
Чыпчыкка дә рәхәт монда,
Мин ялгыз дип әйтмә бер дә.
2015

**Диалог**

– Ник язасың шигырь сиксәндә дә –
Гомрең ахырына җиткәндә дә?
– Чөнки әле мин кояшны күрәм,
Нурларыннан һаман шигырь үрәм.
Кояш, көн дә хәлләремә кереп,
Илһам бирә яшь чактагы кебек.
2015

**Без – мөселман, төрки-татарлар без**

Без – мөселман, төрки-татарлар без,
Тугры калып бөек иманга,
Гасырларны кичтек пакьлек белән
Бердәнбер хак диндә – Исламда.

Иманыбыз Әбү-Хәнифәнең
Мәзһәбеннән китми бер карыш.
Әүлиябез Әхмәт Ясәвине
Дәвам итә безнең яңарыш.
2015

**Кеше булу фәне**

Иң бөек фән – кеше булу фәне,
Бар кешегә уртак, мәҗбүри.
Формулалар, трактатлар түгел,
Кеше белән алдан ул йөри.

Мескеннәрне җәлли беләсеңме,

Киләсеңме теләп ярдәмгә,
Иң әүвәле шушы нәрсә кирәк
Ия булу өчен бу фәнгә.

2015

**Математика укытучысына**

Йөрәк җылың кушып укытканга,
Иң катлаулы, авыр мәсьәлә,
Барып җитеп бала зиһененә,
Әверелә гади нәрсәгә.

2015

**Шагыйрь дустым Роберт Тимершинга**

Юбилееӊ белән ихлас котлыйм,
Шагыйрь дустым Роберт Тимершин.
Тимер кебек чыдам, шигырь кебек
Киң күңелле, нурлы кешем син.

Тимершиннар нәселе – бер легенда,
Ил бурычлы атаң-анаңа –
Сигез бала баккан өчен генә
Мәрмәр һәйкәл кирәк аларга.

Атаң, яуга улы белән китеп,
Батырларча үлгән сугышта;
Улы, илгә Җиңү яулап кайтып,
Дан казанган тыныч тормышта.

Геройга тиң анаң, ирсез калып,
Кеше иткән сигез баланы.
Шул сигезнең берсе – ул син, дустым,
Яшьләй белеп үстең дөньяны.

Һөнәрләрең санап бетергесез,
Түгел бугай җитмеш биш кенә!
Кеше булган кеше генә шулай
Гомер үткән саен җилкенә.

Кайнадың син кеше арасында,
Директор да булдың, монтёр да.
Тарихчы да, оста педагог та,
Философ та, атлет, шахтёр да.

Кешеләрне ихлас яратуың,
Кеше өчен янып йөрүең,
Шатлыкта да, кара кайгыда да
Кичекмичә җавап бирүең –

Барлык яхшылыгың үзеңә кайтсын,
Озын гомер бирсен Ходаем.
Туктаусыз ян иҗат ялкынында,
Шигырь укы миңа көн саен.

2015

**Юбилейның була мондые да**

Икегез дә бер үк көнне туган,
Икегез дә төгәл яшьтәшләр.
Утырасыз гаҗәеп пар булып,
Сез – җитмеш биш яшьлек сердәшләр.

Мәгарифнең биек күкләрендә
Пар йолдыздай балкып яндыгыз.
Күпме шәкертләрнең күңелендә
Гомерлек нур булып калдыгыз.

Мәктәпләргә илткән сукмаклардан
Ярты гасыр бергә йөрдегез.
Кешеләрнең күңеленә кереп,
Зарны куып, шатлык бирдегез.

Нинди гүзәл сезнең бу юбилей,
Тулган ай күк якты, түгәрәк.
Ходай биргән гомер агышында
Тигез яшәдегез бергәләп.

Узган көннәр һич тә юкка чыкмый,
Узган көннәр яши йөрәктә.
Әллә кайчан үтеп киткән язлар
Гел әйләнеп кайта ерактан.

Гел җилкетеп, очар канат куеп,
Озатып барды сезне шигърият.
Мул уңышлар бирде ошбу җиргә
Шигърияттән туган мәгърифәт.

Еллар сезне бер дә үзгәртмәде,
Сез елларны үзегез бизисез;
Көзләр сезгә бер дә кагылмады,
Сез язларда һаман яшисез.

Бер-берегезне һәрчак сүзсез аңлап,
Бер фикердә булып, бер уйда,
Барлык балаларны, оныкларны
Чыгардыгыз дөрес зур юлга.

Илгә хезмәт иткән вөҗүдләрне
Ил җылысы торсын җылытып.
Халык өчен биргән хәләл көчләр
Йөрәкләрдә калсын җыр булып.

Сугыш чоры балалары өчен
Картлык килә үзенә бертөрле:
Алар һаман йөри балалыкта,
Алар һаман бала күңелле.

Икегез дә бер үк язмыштан сез:
Әтиләрне күреп белмисез.

Алар һәлак булган Ватан өчен,
Каберләре һаман билгесез.

Бер үк көндә туган пар яшьтәшләр,
Нинди күркәм сезнең юбилей.
Акъәби һәм аксакалга карап,
Бар күңелне җылы хис били.

Гомер – елга, сулар юкка акмый,
Хәрәкәттә генә бәракәт.
Таулар гына гомер буе йоклый,
Сезнең акыл сизгер, сәламәт.

Үзегез белән бергә – йөрәкләрдә
Язгызның җитмеш бише дә.
Көзге байлык булган көмеш чәчләр
Бик килешә сездәй кешегә.

2015

**Нәрсә соң ул шигырь?**

Мәшрикъ ягы нәкъ Тукайча нурда,
Нурга төренеп тып-тын таң ата.
Ал таң күңелемдә йоклап яткан
Хисләр өермәсен кузгата.

Хисләр таңның буяулары белән
Җанлы сурәтләргә төренә.
Рәсем итеп кенә ясар идем –
Нидер җитмәс кебек күренә.

Хисләр, былбылларга әверелеп,
Моң дәрьясы булып агыла.
Көй чыгарып кына калыр идем –
Сүзсез көйне күңел азсына.

Шигырь җене барыбер өстен чыга,
Татар теле итә патшалык.
Сүз артыннан сүз тезелеп килә,
Кала күрмим диеп адашып.

Хисләр сүзләр белән гәүдәләнә,
Сүзләр әверелә хикмәткә.
Шигырь, хикмәт булып, кеше белән
Мәхшәргәчә барыр, әлбәттә.

2015

**Заманабыз мохтаҗ Тукайлыкка**

Хәвеф белән өмет арасында
Калган чакта каушап, адашып,
Өй түремдә кара җил җыласа,
Илдән авыр хәбәр, шом ташып,

Кояш кебек балкып, Тукай чыга

Һәм дәвалый боек җанымны;
Дөрләп китә шунда идеал утым
Шикләремне куып, кайгымны.

Яшимен мин Тукай дөньясында,
Каршылыклар аша барамын.
“Хөр мәмләкәт, хөр Русия” өчен
Төшмәс кулдан Тукай байрагы.

Хөр бул, Рәсәй, нәкъ Тукайча хөр бул,
Шуны тели синең татарың.
Хөрлек барда шау чәчәкле булыр
Рус-татарның уртак Ватаны.

Уртак Ватан бергә төзегәнбез,
Саклаганбыз уртак дошманнан.
Шулай булгач, бөек Тукай теле –
Ватан теле әллә кайчаннан.

Һәр төбәктә синдә татарлык бар:
Кар диңгезе – ерак төньякта.
Көнчыгышта Татар бугазы бар,
Каф тавы бар шанлы көньякта.

Чын татарча: Енисей һәм Дон, Мәскәү,(1)
Байкал, Урал, Уфа, Казаннар.
Һәр төбәктә урыс белән бергә
Сайрашучы минем татар бар.

Чын дөресе ничә миллиондыр,
Тукай әйткән әнә – егерме.
Санап бетергесез булган чакта
Инкыйразлар безгә килерме?

Бу бүленмәс, бердәм Русиядә
Татарлар да бердәм, бүленмәс.
Җир-су уртак икән, Ватан – уртак,
Хакыбыз күп, хаклык җиңелмәс.

Тукай хыяллары чынга ашсын,
Мәскәү торсын хөрлек сагында.
Һәр милләтне тигез яратып, ул
Үстерсен чын дуслык багында.

Һәр төбәкне Мәскәү күзләп торсын,
Яхшы яшиме дип татарлар,
Милли аңны чәчәк аттырырга
Җитәме дип ирек һәм шартлар.

Татарлыкның хакын кыю хаклап,
Яшик әле, яшик Тукайча,
Ә Тукайсыз вөҗдан, иман, әхлак,

Тулы була алмас беркайчан.

Заманыбыз мохтаҗ Тукайлыкка –
Тугры сүзгә, ак усаллыкка!
Ялагайлык түгел, бу дөньяны
Тик хакыйкать илтер сафлыкка.

Мин яшимен Тукай дөньясында,
Патша монда – куәтле үзаң.
Монафикълык монда керә алмый,
Сакта тора намус һәм вөҗдан.

2016

1. Мәскәү елгасы – Мәскәү шәһәре аша ага торган елга. Мәскәү – татарча атама. Татарларда элек-электән Мәскәү дигән кеше исемнәре булган. Мәсәлән, безнең Мулла Иле зиратындагы 1768 нче елгы кабер ташында фәндә бик яхшы билгеле булган атаклы “Шәехби” шәҗәрәсе уеп язылган. Шәехби балаларының берсенең исеме – нәкъ менә Мәскәү.

**Коръәнгә иярүләр**

*Мәкам белән Коръән укыганда,*
*Һәр аятьтән чыккан тәфсирләр*
*Йөрәгемдә татарчага күчеп*
*Ясый миңа гаҗәп тәэсирләр.*

I

Какшамас нык иман белән керсез яшәп,
Коръән белән изге гамәл кылучылар –
Бер-берләрен сөеп, хакыйкатькә өндәп,
Аллаһының рәхмәтендә булучылар.

Ә гафилләр хәсрәт арты хәсрәт урыр,
Заман җиле йөртер алдап, адаштырып,
Алар һаман заманәны гаепләрләр,
Шайтан көлер теш ыржайтып, саташтырып.

II

Үлем ишеге мәхшәргә чаклы
Гел ачык тора,
Дөньяга килгән һәрбер бәндәне
Чакырып тора.
Әҗәле җиткәч, үлем ачысын
Татый һәр бәндә,
Мең хикмәт белгән Локман Хәким дә
Калмаган җирдә.
Иманлы булып яшә син, бәндә,
Бу фанилыкта.
Монда ни чәчсәң – шуны урырсың
Син бакыйлыкта.
Бу дөнья – бөек сынау мизгеле –
Үтә дә китә.
Бакый тормышның ничек буласын
Тик ул хәл итә.
Яшәү шикелле үлем дә – бер хак,

Ул да – бер нигъмәт.
Яшәгән чакта үлем турында
Күп уйлау кирәк.
Үлгәчтен тәнең туфрак булса да,
Бер күзәнәгең –
Пәйгамбәр үзе Хәдистә әйткән
“Газбүз зәнәбе”ң
Һич үлмәс, калыр мәңге гел тере
Ходай иркендә,
Үлемсез җаның шуңарга иңәр
Кыямәт көндә.
Икенче тапкыр туарсың шунда,
Һәм кубарылып
Яткан җиреңнән торып басарсың,
Хәйраннар калып.
Үткән дөньяның халкы берьюлы
Килер Хөкемгә,
Ничек яшәгән, шуның чын хакын
Алыр һәркем дә.

III

Әй син – бәндә! Хәтта динне онытып,
Бутап бергә хәләл-хәрамны,
Ничек үҗәтләнеп, комсызланып,
Ашкынып җыйдың хәтсез малларны.
Ничек хозурландың, горурландың
Һәм масайдың булып тәкәббер.
Маллар калыр, ахирәткә бармас,
Бар байлыгың булыр буш кабер.
Хәрам маллар җыю үҗәтлеге
Гафил итте сине, алдады.
Андый малдан өлеш чыгарсаң да,
Була алмый әҗер-савабы.
Кабереңдә чиксез үкенерсең,
Үкенүдән ләкин ни файда?!
Күренеп торыр үзеңә яп-якында
Кызган газап уты... һәм анда
Бу дөньяда типтереп яшәүләрнең
Нәтиҗәсен ачык күрерсең.
Хак Тәгалә – гадел хөкемдар ул,
Мал өчен дә җавап бирерсең.
2016, 26 март

**Татар шигыренә**

Дөнья көтәр өчен хәзинәңнән
Булмаса да берни алып,
Гомрем буе озатып бардың мине,
Хисләремә исем табып.

бе генә, сүзләр генә,
Сүзләр генә бар байлыгың.
Үзеңә бөтен дөнья сыеп бетә,
Синдә – иң саф татарлыгым.

Күрсәтәсең яшерен хикмәтләрен
Гади генә нәрсәләрнең
Һәм ачасың олы, зур мәгънәсен
Бу дөньяда яшәүләрнең.
2016
**Авыл белән Казан арасы**
Авылым белән Казан арасы –
Дүрт елганы чыгып барасы:
Әрә, Зөя, Идел, Казансу –
Дүртесе дә шөһрәт алган су –
Күперләрен сузып каршыга
Сәламнәргә безне ашыга.
Бертуктаусыз агыла машина,
Имин юллар булсын барсына.
Җанга якын шушы хәрәкәт
Биреп тора безгә бәрәкәт.
Авылым белән Казан дуслыгы!
Тормышларны нурлап, син ныгы!
Ара шундый якын булганга,
Безгә якты язмыш бирелгән;
Авылым белән Казан тарихы
Борынгыдан бергә үрелгән.
Мең яшәгән Казанга карап,
Сигез йөзен тутыра авылым,
Авылым белән Казан арасы
Ямьгә төрә тормыш агымын.
Борынгыдан килгән табигать
Озатып бара безне бу юлда,
Саклап ята кыргый халәтен
Әрәмәләр Әрә буенда.
Авылым халкы борын-борыннан
Әрә, Зөя, Идел буйлата
Каекларда йөзгән Казанга –
Таңнар ата бездә шул яктан.
Җәйрәп ята рәхәт тынлыкта
Тугайлары иркен Зөянең,
Үзебезнең бу Швейцарияне
Бар нәрсәдән артык сөямен.
Зөя буйлап баскан тауларга
Соклanудан туймам ахыры.
Чорлар серен саклап тын тора
Шаһитлары безнең тарихның.
Тау башына менеп җитүгә,
Аска карап хәйран каласың:
Дәрья уртасында – утрауда
Балкып утыра Зөя каласы.
Даны аның бүген дөньяга
Торган саен күбрәк тарала.
Нәрсә эзли анда туристлар,
Нинди яшерен серләр бар анда?
Биргән Ходай монда барсын да:
Урманнарны кичеп барасың,

Тирән-тирән сихри чокырлар
Сискәндереп ала карашың.
Юл, ниһаять, төшеп түбәнгә,
Килеп чыга иркен Иделгә.
Аръяк ярдан Казан башлана –
Горур хисләр туа күңелдә.
Шәһәр чите матур булса да,
Чын Казанга күңел ашкына.
Казансудан чыккан чагында
Бөек тарих ачыла каршыда.
Биек үрдә балкый, зур булып,
Сөембикә белән Колшәриф.
Шулар аша якты нур сибә
Бүгенгегә безнең чал тарих.
Биек үрдә горур җилферди
Халкым улы Тукай байрагы.
Ул байракның нуры яктырта
Чиксез Россиянең бар ягын.
Халкым хакын кыю яклаучы
Тукайчылар яши кайда да.
Тукай теле уртак Ватанда
Ватан теле әллә кайчаннан.
2016, март

**Уртак шатлык**

Кыш уртасы, шундый салкын тышта,
Ничек түзә кошлар бу көндә.
Без торабыз җылы, тук тормышта,
Кошлар – тоташ язмыш иркендә.

Тәрәзәмә песнәк шакылдатты,
Бөтен тәне дер-дер калтырый.
Соңгы өмет белән миңа бакты,
“Зинһар, коткарчы”, – дип, ул сорый.

Мин, бакчама чыгып, бичарамны
Пилмән эче белән сыйладым.
“Кереп сыенырга урының бармы,
Күрсәт әле”, – диеп сорадым.

Кошкай шунда рәхмәт дигән сыман
Иңгә кагылып пып-пыр йөрде дә
Кереп китте сыерчык оясына,
Бер рәхәтлек туды күңелдә.

Хуҗаларын сагынып, язны көтеп,
Моңсу гына торган оя да
Җан иясен сөенеп кабул итеп,
Шатлык белән бакты дөньяга.

Кышлар үтәр, песнәк исән калыр,
Сыерчыклар оя башында
Бу шатлыкны бергә уртаклашып

Сайрашырлар әле каршымда.
26.01.2016

**Телебез, бәлки, латин теле кебек...**

Телебез, бәлки, латин теле кебек
Төшеп калыр җанлы тормыштан,
Ул сакланыр ләкин китапларда,
Интернетта, кабер ташында.

Эфирлардан әле мәшһүр телнең
Хәзинәдә калган байлыгы
Бер тарихи моңсу ретро булып
Тетрәндерер илнең бар ягын.

Бөек урыс теле белән бергә
Безнең мәшһүр татар теле дә,
Эфир аша кереп, яңгырый алыр
Барлык йортларның да түрендә.

Тыңлыйлармы, юкмы – әмма ләкин
Дәүләт рөхсәт иткән күләмдә
Ул яңгырар бөтен сафлыгында
Иң югары камил кимәлдә.

Латин теле барлык даруларга
Исем кушар өчен яраса,
Кулланыштан төшкән татар теле
Дөнья буйлап йөрер җан сорап,
Сак-Сок булып йөрер аптырап.
04.06.2016

**Һәр нәрсәнең җирдә үз вакыты**

Гасырларны кичкән нигеземнең
Тын җирендә – аулак бакчамда
Шау чәчәктә чагы сиренемнең,
Карап туймам – күпме баксам да.

Минем кебек, күп кышларны үтеп,
Бу җиһанда озак торса да,
Ул нинди яшь бүген, кызлар кебек,
Нинди купшы, көяз һәм садә.

Сирень исен, сирень төсен күңел
Артык яратканга күрәдер,
Мин романтик булып калдым һаман,
Гел матурга таба үрләдем.

Балкортларның сырышып һәр чәчәккә
Гөҗелдәве серле бер көйгә,
Аңкып торган тәмле бал исләре
Ничек рәхәт бирә күңелгә.

Баш очымда – сирень кочагыннан
Күтәрелгән колга башында

Ничек гөрләп тора кош оясы
Шундый җылы кояш каршында.

Әти-әниләрнең “урак өсте”:
Бәләкәчләр тизрәк үссен дип
Казганалар пыр-пыр азык ташып,
Нәселебез дәвам итсен дип.

Май бетүгә, сирень чәчәк кояр,
Сыерчыклар бала очырыр.
Сирень төссез, иссез, көйсез калыр,
Буш ояга сагыш-моң тулыр.

Һәр нәрсәнең җирдә үз вакыты,
Үзгәрмичә тормый берни дә.
Үзгәрешкә риза булып яшәү –
Безнең өчен алтын кагыйдә.
25.05.2016

**Әтәчләргә мәдхия**

Әтәчләрнең кычкыруы – нәрсә соң ул?
Уйлап баксаң, бу бит – безгә зур бер гыйбрәт.
Җир йөзендә һәр кыйтгада һәрбер әтәч
“Кикрикүк!” – дип аваз салып яулый шөһрәт.

Тереклекнең бу төренә Хак Тәгалә
Сәгать кебек вакыт әйтү гыйлемен биргән.
Хакның әмерен һәр әтәч тә катгый үти,
Җәйме-кышмы төн уртасы җитү белән,

Ялгышып та йоклап калмый, һич иренми,
Шайтани бер вәсвәсәгә һич бирелми,
Горур кагып канатларын, түш киереп,
Аккорд бирә төн карасын моңга төреп.

Мең-мең еллар буе һаман шулай бара,
Һич үзгәрми яшәешнең бу кануны.
Бер әтәч тә бозганы юк вазифаны,
Безгә зур бер гыйбрәт – уйлап баксаң моны.
04.06.2016

**Сәхәр**

Картлыгымда һәр сәхәрдә искә төшә
Ерак калган, сәхәр торган сабый чагым:
Әби белән әниемә тын табында
Бер юаныч – өмет булып утырганым.

Без күрмибез генә: сәхәр вакытында
Утсыз өйнең эңгер-меңгер яктысында
Яныбызда дога кыла фәрештәләр,
Безнең доганы да алар ишетәләр.

Фәрештәләр белән бергә безнең янга
Бик еракта – канлы сугыш барган яктан

Һәлак булган этинең һәм өч абыйның
Әрвахлары сагынышып очып кайткан.

Әбине дә, әнине дә һәм мине дә
Алар ачык күреп тора, без күрмибез,
Бер Аллаһка сыенабыз догабызда:
“Җәннәтеңдә күрештергел, Раббым”, – дибез.
25.06.2016
**Миннән хата эзләүчеләр**
Миннән хата эзләүчеләр һәм, чыннан да,
Меңнән бердә шул хатаны табучылар,
Зур табышка сөенешеп, шул хәбәрне
Колаклардан колакларга ташучылар!

Бер хатасыз калсам, нишләр идегез сез?
Белеп торам: бер дә болай сөенмәссез.
Хөсетлектән кара көеп, гел теләрсез
Хата ясавымны һәрбер көнемдә сез.
25.06.2016
**Мин җанатар булдым гомергә**
Сабантуйда яшьти – гел көрәшче,
Мин җанатар булдым гомергә.
Мин дә чыгыйм әле мәйданга дип
Уйлап карамадым шул бер дә.

Югыйсә бит көчем ташып торды,
Егәр тулып торды беләктә,
Ашкынулы, дәртле, якты хисләр
Тулышып торды һәрчак йөрәктә.

Яшьти җиңгән саен – горурландым,
Ә җиңелсә – барып янына,
Рухландырдым алгы җиңүләргә,
Яңа канат куйдым җанына.

Яшьтиемнең даны ерак китте,
Шул данда бар минем өлеш тә.
Риза булып яшә бу дөньяда
Өлешеңә тигән көмешкә.
25.06.2016
**Без тарихка кайтып берләшәбез**
Әй мөкатдәс иске төрки телем,
Син – борынгы бабамның теле!
Әүлиябез Әхмәт Ясәви бит
Хикмәт әйткән синең аркылы.

Меңьеллыкны кичкән хикмәтләрдә
Син калгансың төгәл сакланып;
Гомерем буе укыйм мин шуларны,
Бөек тарихыма сокланып.

Һәрбер төрки кеше минем кебек

Үз урынын эзләп исламда
Килеп чыга Әхмәт Ясәвигә,
Эзләгәнен таба ул анда.

Ул бит безгә бөек шәригатьне
Шәрехләгән үзебез телдә.
Шуннан күреп без”Бәдәвам” язган,
Рухын саклап бөек Иделдә.

Һәр төрки тел бүген, горурланып,
Ясәвидә таба асылын,
Һәр төркинең күңел чоңгылыннан
Бәрә уртак хисләр ташкыны.

Без тарихка кайтып берләшәбез,
Аерым-аерым тормыш корсак та,
Без – Исламда, уртак бер мәсләктә,
Без Ясәви белән бер сафта.

Ясәвигә төрбә булган кебек,
Безнең зиратта да төрбә бар.
Ята анда изге авылдашым –
Ясәвигә гашыйк бер пәрвәр.

Мәрмәр каберташта уелып калган
Шәҗәрәсе гасырлар аша
Хикмәтләре безгә килеп җиткән
Ясәвигә барып тоташа.

Мең яшәгән Казан ышыгында
Сигез йөзен тутыра авылым.
Үз тарихын сөйгән газиз халкым
Үз теленең белә тамырын.
14.07.2016
Искәрмә Әхмәт Ясәви (1080-1166) – иске төрки телдә иҗат иткән шагыйрь, дөньякүләм танылган “Хикмәтләр “ җыентыгы авторы. Төрекмәнстанда аңа куелган мәһабәт төрбә кадерләп саклана. Мулла Иле авылы зиратында да мәһабәт төрбә бар. Төрбә эчендәге мәрмәр каберташта 1768 нче елда вафат булган мәрхүмнең нәсел шәҗәрәсе уеп язылган. Шәҗәрә Әхмәт Ясәви яшәгән елларга барып тоташа.

**Рәсәйнең иң матур бер җирендә**

*“Йосыф зиндан эчендә бик озак булды...” (Кол Гали, “Йосыф кыйссасы”)*

Шигырьдә мин гомрем буе яздым
Матурлыгын туган ягымның,
Идел белән Зөя кавышуын,
Юлда машиналар агышын.

Бүген язам олы юлда торган
Үзебезнең зиндан хакында.
Без аңарга шундый күнеккәнбез,
Карап үтә-үтә якыннан.

Рәсәйнең нәкъ урта бер җирендә –

Матурлыкның үзе эчендә
Тора гигант зиндан пулатлары
Кешелеккә гыйбрәт өченгә.

Бөтен кеше күрсен дип төзелгән
Шундый ачык, шаулы бер җирдә.
Ирек кадерен күбрәк белсеннәр дип,
Каратканнар Идел җиленә.

Ул көн саен белеп, тыңлап тора
Казан белән Мәскәү арасында
Чапкан поездларның тавышын,
Гигант күпер салган аккордларны,
Идел, Зөя дулкыннары җырын,
Хәтсез машиналар агышын.

Рәсәй пульсын монда нык тоясың,
Барысын белеп тора бу төрмә.
Хагың-нахагыңнан сакла, Ходам,
Гаепсезне монда китермә.

Утырып чыкканнардан йөз чөермик,
Йосыф пәйгамбәр дә утырган.
Унсигездән утыз яшькә кадәр
Унике ел тоташ яшь гомерен
Зиндан тарлыгында уздырган.

Ә гаебе нидә булган аның?
Гыйшык белән янган Зөләйха,
Үзе белән уйнаш итмәгәнгә
Салган аны шундый җәзага.

Зиндан авырлыгын горур кичеп
Бирешмичә яман нәфескә,
Сафлык белән хаклык колы булып,
Чын бәхеткә Йосыф ирешкән.

Рәсәйнең нәкъ урта бер җирендә –
Матурлыкның үзе эчендә
Зиндан тора Яшел Үзәнемдә,
Кешелеккә гыйбрәт өченгә.

Нинди биек, таза коймалары
Чәнечкеле корыч челтәрдән,
Тәрәзәсез кара ташпулатлар
Күпме бәндәләрнең язмышларын
Яшереп саклый безнең күзләрдән.

Тоткыннарны кайчак чыгаралар
Зәңгәр күкле түбә өстенә,
Күрсеннәр дип Идел киңлекләрен,
Түзсеннәр дип зиндан эчендә.

Биек-биек коймалардан өстә
Ничә сакчы тора күзәтеп.
Яманлыктан илне саклау өчен,
Төрмәләр дә кирәк, нишләтик.

Гаепсезгә утыртылган затка
Хак Тәгалә бирсен сабырлык.
Хаклык тантанасын иткән көнне
Җиңелер ул яла – явызлык.

Бу зинданда хезмәт – төп юаныч,
Йөргәнем бар кереп мин анда.
Алар коойган чуен улакларны
Алып кайта идек фермага.

Минем дустым төрмә мәктәбендә
Гомер буе дәрес укытты.
Хакыйкатьне белдем аның аша,
Ни икәнен ирек юклыкның.

Бар күңелләр сафлык белән тулсын,
Изге булсын иде һәр кеше.
Хөкем ителерлек зат калмасын,
Гаделлеккә бар җир төрелсен.

Чынга ашсын иде бу әкият,
Шул чагында безнең бу төрмә
Урыныннан кубып юкка чыгар,
Тарих булып калыр хәтердә.

Идел буе тоташ матур булыр,
Балкып торыр тоташ иректән.
Ә хәзергә... зиндан чәнечкесе
Кадалып тора безнең йөрәккә.
12.07.2016

**Әгәр шагыйрь…**

Әгәр шагыйрь яза икән
Артык интеллектуаль
Язганын беркем аңламас,
Ләкин булыр актуаль.
2016

**Чын балалар шагыйре**

“Балык суда яши “, – диеп,
Шундый аңлаешлы итеп,
Артык гади яза белгәнгә,
“Чын балалар шагыйре!” – дип,
“Җырлап тора шигыре!” – дип,
Мөһер сукты тәнкыйть Галләмгә.
2016

**Картайгачтын һәркем дә акыллы**

Ах, хәзерге акыл яшь чакта ук

Булган булса кана башымда,
Гомер йомгагымда нәтиҗәләр
Күркәм булыр иде барсы да.

Бу санаулы, соңгы көннәремнең
Һәр минуты ничек кадерле.
Акыл йомгак ясый гомеремә,
Эшкә җигеп бөтен хәтерне.
2016
**Салават күпере**
Салават күперен
Тотам дип йөгермә:
Ул хыял шикелле
Тоттырмый беркемгә.

Салават күпере –
Күп төрле төсләрнең
Нурланып балкуы,
Иркәләп күзләрне.
2016
*******
“Сөям” сүзен әйтәлмичә
Кайгырып йөргән егет!
Кызның мәхәббәтен яула
Син әйтүдән элек.

“Сөям” диеп әйтергә дә,
Бәлки, туры килмәс:
Сиңа тутырып карар күзләр,
Бу серне беркем белмәс.
2016
**Татар зыялылары**
Без яңадан җиттек шундый хәлгә:
Татар теле мөгаллимнәре,
Татар артистлары, шагыйрьләре
Үзләренең туган телләрен
Кулланалар бары дәресләрдә,
Сәхнәләрдә һәм матбугатта,
Калган җирдә русча җибәрәләр,
Кухняда да, хәтта ятакта.
2016
**Халикъ һәм халык**
Халикъ Әрәсе янында
Халикъ талы бар бездә.
Халык ел да, җыелышып,
Печән бүлә шул җирдә.

Йөз ел электә дә шулай
Халык бирегә килгән:
Староста Халикъ монда
Печәннәр бүлеп биргән.

Гадел итеп бүлгән өчен
Халык аны яраткан.
Халикъ маяк итеп монда
Тал агачы утырткан.

Халикъ йөзгә җитеп үлгән,
Елгасы бар, талы да,
Елга булып, шул тал булып
Яши халык аңында.

Күз алдына килә Халикъ:
Аршын таягын аскан,
Талы, меңгә тармакланып,
Зур тарих булып баскан.
13.07.2016

**Изге Касыйм бабай чишмәсе**

*Күренекле дин һәм җәмәгать эшлеклесе, шагыйрь Ибраһим улы Касыйм әл-Казани (1520-1590 еллар арасында яшәгән) Норлат авылында туып үскән. Казан ханнарының ререзеденциясе Норлатта да булган. Зирәк һәм гаярь Касыйм ханнарның якын кешеләре белән аралашкан һәм бик җаваплы урыннарда эшләгән. 1551 нче елда Казан хөкүмәте Касыйм мулланы Мәскәүгә, сөйләшүләр алып бару өчен, илче итеп җибәрә. Мәскәү белән Казан арасындагы мөнәсәбәтләрне тыныч юл белән хәл итү өчен, Касыйм шәех зур көч куя. Мәскәү Казанга яу белән килгәч, кулына корал тотып, батырларча сугыша. Казан алынгач, татарларга яшәү өчен мөмкинлекләр оештыра. Халыкның сөекле җитәкчесенә әйләнә. Туктаусыз табиблык белән шөгыльләнә. Үзенең васыяте буенча, үлгәч, аны туган авылы Норлат төбәгендә – тау аралыгындагы аулак бер җирдә – гөбердәп чишмә бәреп торган урында җирлиләр. Бу урын изге җир булып санала. 450 ел буе бу урынга халык сукмагы өзелми.*

Норлат, Норлат... Аның чал тарихы
Риваятьләр белән уралган.
Казан ханнары да, монда килеп,
Чишмәсеннән сихәт, көч алган.

Норлат, Норлат... Касыйм атлы улы
Ханнар йөрәгенә юл тапкан.
Мәскәү белән сөйләшергә Казан
Илче итеп аны озаткан.

Мәскәүдән яу килгәч, Касыйм мулла,
Корал тотып, батыр сугышкан,
Бер могҗиза белән исән калып,
Халык дәваларга тырышкан.

Дәвалаган күпме җанны, тәнне
Дога белән, дару белән дә,
Һәм уятып өмет киләчәккә,
Яшәү бүләк иткән меңнәргә.

Норлат, Норлат... Тауларың бик серле,
Чокырларың серле, кадерле.
Иң серлесе – изге Касыйм улың

Соң урынын тапкан каберлек.

Таулар арсында – аулак җирдә
Соң урыны Касыйм бабаның.
Бөтен яктан халык монда килә
Өмет итеп соңгы дәваны.

Бу чишмәгә иң беренче тапкыр
Килгәнемне мәңге онытмам:
Әти яуда һәлак булган дигән
Хәбәр килгән көнне фронттан.

Мин, әбигә ияреп, монда килгән идем,
Әбиемнең ачы күз яшен
Елый-елый юды һәм юатты
Изге Касыйм баба чишмәсе.

Бу чишмәгә мин кышын да киләм
Бар җир туңып, катып торса да,
Нәкъ җәйдәге кебек гөберди ул,
Бар дөньяга җылы пар чыга.

Тау куйныннан чишмә ургып тора –
Изге Касыйм баба чишмәсе.
Бу чишмәнең сихәтләре серен
Чишәсе дә әле, чишәсе.
31.07.2016

**Соңгы чәчәкләр**

Мин, сиксән яшьлек аксакал, гомер кышын татып яшим. Аллага шөкер, бакчадагы соңгы чәчәкләр кебек, гомерем кышын шатланып каршы алдым һәм шул турыда мондый шигырь дә яздым:

Соңгы гөлләр шау чәчәктә чакта
Өсләренә тәүге кар ява.
Тәүге карлар бик вакытлы ява,
Һич үпкәләп булмый аларга.

Язмышлары шулай булгангадыр,
Бакчадагы соңгы бу гөлләр
Ак карларны сөеп каршылыйлар,
Һич кенә дә боек түгелләр.

Алар әнә шау чәчәктә килеш
Ак карларга күмелә баралар,
Әйтерсең лә, карлар кочагында
Тынычлык һәм бәхет табалар.

Соңгы гөлләр безнең күңелләрдә
Шау чәчәкле хәлдә яшиләр.
Кыш салкынын сизмичә дә кала

Бу бакчада йөргән кешеләр.
Ноябрь, 2016 ел

# Поэмалар

## Тугры Тукай

*(публицистик поэма)*

Һәр кавемгә Тәңре тарафыннан
Бер пәйгамбәр бирелгән кебек,
Татарларга тугры Тукай килгән,
Илаһи саф нурга төренеп.

Имансызлар аңа теш ыржайткан:
 - Синең сазың түгел Тәңредән,
Ышандырмак булып алдашасың,
Үрнәк алып, Пушкин тәреңнән.

Алданмаган , алдашмаган Тукай,
Ходайсызга биреп ак кулын.
Кара төннәр буе йокламыйча,
Халкы өчен яккан ялкынын.

Милли хисләр белән ялкынланып,
Сызылып-сызылып чыккан җырлары.
Бөтен Рәсәй буйлап җәелеп киткән
Иңли-иңли татар кырларын.

Тукай хакны күзгә бәреп әйткән,
Котырганнар мәлгунь шайтаннар;
Татар була торып, эттәй һаулап,
Ук атканнар аңа куштаннар.

Әй, сипкәннәр кат-кат яла, хурлау,
Почмакларда гайбәт сатканнар,
Хәтта зыялылар аңламыйча
Такмакчы дип корым якканнар.

Тукай очкан иңләп Ил күкләрен,
Куып инкыйраз болытларын,
Карап тормый кәефен түрәләрнең,
Ялтыраткан яшен утларын.

Ә бит мөмкин иде зәңгәр күктә
Ак кул белән йолдыз чүпләргә,
Күкрәгеннән былбыл очырырга,
Азат булып милли йөкләрдән.

Күзләренең гаярь карашыннан –
Коты алынып якты яшеннән –
Төнгә яшеренгән кара көчләр
Лаф органнар Тукай гарьшенә.

Тукай арыгач алар сөенгәннәр,
Аңа бармак төртеп күрсәтеп,
Балаларга гыйбрәт укыганнар,
Шулай булмаска дип кисәтеп:

- Нинди беткән, ничек арыкланган,
Зәгыйфьләнгән, кадер күрмәгән;
Фәкыйрьләнгән, ничек таланган ул,
Өсте-башы ничек керләнгән.

Тәңресенә сыенып, бөек шагыйрь
Тугры булып калган антына,
Керләнсә дә, упкыннардан саклап,
Яшәү көче биргән халкына.

Тукай җаны Әлмисактан Гали,
Пәйгамбәрен ничек сынаса,

Тукаен да Тәңре шулай йөрткән
Мең газаплы авыр юл аша.

Шул газаплар , кимсетүләр аша
Тугры калган шагыйрь Тәңрегә.
Ходай билгеләгән биеклектә -
Сөелүдә калган мәңгегә.

Газапларны сөеп ләззәт белән,
Тапкан үзенең бәхете ачкычын;
Җиденче кат күкләргәчә ашкан
Максатына илткән баскычы.

*****

Илебез бүген безнең тоташ базар,
Кемдер алдый, кемдер алдана.
Вөждан белән сату итүчеләр
Үрнәк кеше булып дан ала.

Гөнаһлылар җирдә җәннәт кора,
Вөждансызга кала җәһәннәм.
Хак сагында торган затларга да
Байтак өлеш чыга хәрамнан.

Вөжданыннан шайтан кебек качып,
Хакыйкатьне яшерүчеләр,
Эчтән динсез, тыштан тәкъва булып,
Хаклык сөйгән булып йөрүчеләр –

Алар, хаксыз артык өлеш сосып,
Җирдән чыккан уртак байлыктан,
Изге бер зат булып, урлаганны
Яшереп саклый белә халыктан.

Замананы баскан имансызлык,
Монафикълык керә һәр эшкә,
Фәхеш тулы күпме бүлмәләрдә
Дини китап тора күренешкә.

Капиталга карап чукыналар
Хаклык сөйгән булып йөргәннәр,
Каршысында дога укыналар
Кәп-кәкрене туры, дигәннәр.

Урлап җыйган хәрам малларыннан
Саркып тора мескеннәр яше.
Кем күтәрер ачык хакыйкатьне
Каплап торган ялган пәрдәсен?

Заманыбыз мохтаҗ Тукайлыкка –
Тугры сүзгә, ак усаллыкка!
Ялагайлык түгел, бу дөньяны
Тик дөреслек илтәр сафлыкка.

Татарлыкның хакын кыю хаклап,
Түрәләрнең төкереп сыена,
Кем Тукайча бүген гавамының
Хәсрәтенә барып сыена?

Кирәк баймы, фәкыйрь я түрәме –
Аермыйча бер дә аларны.
Я, кем кешеләрнең күз алдында
Гаепләрен әйтә шуларның?

Куркак кеше шагыйрь булса – бәла;
Кизәнә ул мифик дошманга.
Тукайның бит һәрбер аткан угы
Барып тигән мәгълүм бер җанга.

Күпме җаһил астыртынлык белән
Золым, җәбер кыла милләткә,
Исе китеп тышкы зиннәтләргә,
Байга сатылып, укый ләббәйкә.

Шундый авыру белән авырый милләт,
Киләчәге күксел томанда,
Ничек булсын Тукай телен галим
Кирәксез тел, диеп торганда.

Татарлыгын тарсынганнар тукый
Тукайсыз да яшәп була дип.
Иманын да, вөжданын да сатып,
Рәхәтлеккә чума яңа тип.

Нигә катле нәфес итүчеләр,
Эчеп үлүчеләр гел арта?
Милләтемне кирәк дәваларга –
Даруларын аның кем сата?

Тукай кирәк җанны дәваларга,
Җанда якты идеал булмаса,
Җан бозыла, сүнә бар изгелек,
Зиначылар җиһанны баса.

Күр: хөсетлек, үчлек, кинә белән
Үзен-үзе буа татарлык.
Чәчәк аткан нилеш гүргә кертте
Татар Пәйгамбәрен бу тарлык.

Кат-кат "халык-халык!" дип кабатлап,
Матур күренүче депутат
Тукайлыкка яшерен киртә кора,
Мескеннәрне уза ул урап.

*****

Яшимен мин Тукай дөньясында,
Каршылыклар аша барамын.
“Хөр мәмләкәт, хөр Русия” өчен
Төшмәс кулдан Тукай байрагы.

Хөр бул, Рәсәй, нәкъ Тукайча хөр бул,
Шуны тели синең татарың.
Хөрлек барда шау чәчәкле булыр
Рус-татарның уртак Ватаны.

Җиреӊ иксез-чиксез булган кебек,
Күңелләр дә булсын иркен, киң.
Баш булмасын дуслар бер-берсенә,
Иш булсыннар - чәчәкләргә тиң.

Үз төсендә балкып торсын милләт,
Уртак күктә әнә һәр йолдыз.
Эресе дә, хәтта бик вагы да
Бик дустанә яна ызгышсыз.

Бу Рәсәйне ничә гасыр буе
Без саклаган уртак дошманнан,
Шулай булгач, гүзәл Тукай теле –
Ватан теле әллә кайчаннан.

Бер бөек зат юкка әйтмәгән бит,
Чын тарихка саклап тугрылык:
Кайсы русны ярып карасаң да,
Татар каны чыгар ургылып.

Картайсам да, җанны гел яшәртеп,
Өермәле еллар аркылы
Күкрәгемдә, бер дә сүрелмичә,

Дөрләп яна Тукай ялкыны.

Хәвеф белән өмет арасында
Калган чакта кайчак адашып,
Өй түремдә кара җил еласа,
Илдән авыр хәбәр, шом ташып,

Кояш кебек балкып Тукайгача
Һәм дәвалый Бөек җанымны.
Дөрләп яна шунда идеал утым,
Шикләремне куып, кайгымны.
2006

**Мәңгелек хәзинә**

**1**

Матур Идел ярында
Урнашкан бер авылда
Бер бакчачы торган, ди,
Бик шәп тормыш корган, ди.
Эшләгән, ди, тырышып,
Кояш белән ярышып.
Шуңарга бакчасында
Үскән ди барчасы да:
Алмалар пешкән тулып,
Кило ярымлы булып,
Җиләкләр эре-эре –
Булмаган нинди төре.
Менә шушы кешенең -
Алтын куллы кешенең
Улы бар: ата ялкау:
Үгездәй таза, көчле,
Егермегә җиткән ул.
Мәшәкатьне, бар эшне
Әтисенә җиккән ул.
Эшләгәндә әтисе,
Бернигә китми исе,
Күләгәдә тик ята,
Торып күбәләк тота.

2

Ата кеше картайды,
Тәмам ул хәлдән тайды.
Бакчачы торалмады,
Аяклар тыңламады.
Бакчаның яме китте,
Агачлар корып бетте.
Күрсә дә моны улы,

Эшкә бармады кулы.

Ләкин менә ашарга

Хәзер кайдан табарга?

- Әткәй, әткәй, әйтсәнә,

Зинһар ла өйрәтсәнә?

- Синнән башка нишләрмен,

Кайдан азык эзләрмен.

Күрим икән ни чара?

(Егет елый бичара).

Бала бала шул инде,

Карт аңа киңәш бирде:

- Көч барында беләктә,

Дәрт барында йөрәктә

Һич эштән карышмадым,

Кояштан калышмадым.

Бушка узмады гомер,

Үкенмим, риза күңел.

Мин тыныч үләм, бала,

Замана сиңа кала.

Бу җирдә кылган эшем

Бирде миңа җимешем.

Һәм мин хезмәт хакымны –

Чүлмәк тулы алтынны

Күмеп куйдым, тик бер дә

Хәтерләмим кай җирдә.

Хәзинәмне эзлә син,

Бик тырышсаң табылыр,

Бәхет таңың кабыныр.

Яшәрсең хөр рәхәт чигеп,

Миңа гел рәхмәт әйтеп,

Кайгы-хәсрәт белмичә,
Хурлыкларны күрмичә.

3

Ата үлгәч, Нургата

Бик озак елап ята.

Алтынны кайсы җирдән

Табарга дип баш вата.
Нургата көрәк алды,
Йорты каршына барды,
Һәм тотынды эшләргә,
Байтак казып ташлады.
И казыды, казыды,
Буыннары язылды.
Кояш батты. Тир акты –
Тик хәзинә чыкмады.
Төн үтте план корып,
Кояштан иртә торып,
Бакчачы егет чыкты
Үләннәр әле чыклы.
Көн буена тырышып,
Кояш белән ярышып,
Ул эшләде, эшләде.
Ул хәзинә эзләде.
Шунда кинәт көрәге
Бер әйбергә терәлде.
Үзе каты, үзе нык –
Әти яшергән байлык...
Казылып бетте бакча
Чыкмады ләкин акча.
Шулай да безнең егет
Өзмәде әле өмет.
«Сай казыдым, хәзинә
Тирәндә булса кирәк”, -
Дип ул тагын да җиргә
Батырды ныклап көрәк.
Чокыр казыды егет
Илһамланып, бирелеп.
Ул арыды. Талчыкты –
Ниһаять, бер таш чыкты.
Чыкса чыксын инде таш,
Бетмәгән бит әле баш!

Тәгәрәтте зур ташны –
Таш бер читкә урнашты.
Аннан тагын казыды,
Буыннары язылды.
Көч артты беләгендә,
Дәрт артты йөрәгендә.
Җир йомшарды. Күперде,
Җиргә көч-куәт керде.
Тик хәзинә егеткә
Табылмады ничек тә.
Ял иткәндә Нургата
Үзен болай юата:
“Шулкадәр җир казыдым,
Никадәр таш ташыдым,
Әрәм китмәсен хезмәт,
Җиргә күрсәтим хөрмәт,
Утыртыйм виноград,
Үстерим аны карап.”
Егет эшли тырышып,
Кояш белән ярышып,
Көч тулы беләгендә
Дәрт тулы йөрәгендә.
Һәм, ниһаять, бакчада,
Кемнәр карап бакса да,
Сокланырлык бар эшләр,
Тәлгәш-тәлгәш җимешләр.
Тулылар һәм эреләр,
Кайсы кирәк – төрлеләр.
Нургатаны күршеләр
Мактап кына йөриләр.
Юкка гына син, диләр,
Казымадың җир , диләр,
Төштең бәхет эзенә,
Таптың бик зур хәзинә.
Елмая безнең егет:

Мин әтинең мәңгелек

Хәзинәсе серенә

Төшендем инде, диеп.

1970

**Һади Такташка хат**

***(“Киләчәккә хатлар”га пародия)***

“Киләчәккә хатлар”ыңа каршы
Җавап язам, Такташ әфәнде.
(Ачуланма болай диюемә:
Эндәшүләр хәзер үзгәрде).

Бишьеллыкның гигантлары белән
Чын күңелдән сөенеп йөргәнсең.
Башларыннан аның без яшисе
Коммунизм кырын күргәнсең.

Ләкин килмәде ул коммунизм,
Җитмеш еллап төзедек югыйсә.
Хәзер бездә кыргый бер кризис,
Кесәләрдә безнең җил исә.

Бишьеллыклар бетте, хәзер базар
Кибетләре күккә үреләә.
Башларыннан инде мул тормышлы
Капитализм кыры күренә.

Без үткәннең каты җиңелүе,
Бүгенгенң җиңеп килүе
Көрәшендә
Артык ашкынулы
Хисләр уты белән янабыз.

Без – фермерлык,
Бизнесменлык өчен
Илдә зур дау алып барабыз.

Без бит күмәк томыш ярларыннан

Хосусыят ягына күчәбез.

Син белмәгән ваучер-маучер белән
Барлык проблеманы чишәбез.

Әгәр сезнең чакта Мохтар абзый
Оештырган булса колхозны,
Безнең авылныкы – Фәттах абзый
Ул колхоздан чыкты бу язны.

Шул эш өчен аны кочагыннан
Мәхрүм иткән “сөйгән карчыгы”.
Ләкин көзен алты гектар җирдән
Тутырган ул акча капчыгын.

Килешкәннәр алар, тик шулай да
Караклар шул куркып тормаган:
Көпә-көндез абзыйларга кереп,
Барлык акчаларын урлаган.

Бездә һәр гаилә хәзер каршылыклы,
Бик күп кешеләр икегә бүленә.
Фәттах абзый сөйли:
 - Мин, - ди, - менә
Дошман булып чыктым үземә.

Элек чакта мин бер кеше идем,
Хәзер, малай, миндә ике мин.
Берсе аның менә фермер яклы,
Икенчесе – коммун, сукин сын!

Канга сеңеп калган иске гадәт,
Иске караш, иске йолалар
Яңа кешенең туып үсүенә
Киртә булып чыгып торалар.

Безнең чорда, әйе, социаль яклау
Зур бер нәрсә итеп карала,
Чөнки күпләр айлык хезмәтенә
Ярты чалбар гына алала.

Хәзер инде нәни сабыйлар да
“Миллионерлар” булып уйныйлар.
Алыпсатар абзыйларның бүген
Миллион эшли торган урны бар.

Хыял – безнең өчен чит бер нәрсә,
Һәрбер теләк – якын киләчәк.
Һәр акция,
Һәрбер коммерция
Яшәү көче безгә бирәчәк.

Базарларның ялтыр ларёклары
Һаман үсә,
Һаман күккә таба үреләә.
Башларыннан инде мул тормышлы
Капитализм кыры күренә.
1993

**Вәисиләр турында хикәят**

Мулла Иле – минем туган авыл,
Чал тарихта аның үз даны.
Бу бит – шагыйрь Баһаветдин белән
Аның улы Гайнан ватаны.

Монда йөргән бөек Каюм бабай,
Каберташтан сурәт алдырып.
Мәдрәсәдә Тукай кунып киткән,
Стенада шигырь калдырып.

Монда килеп Такташ, коммунистлар
Язмаган бит, дигән, диненнән.
Илдар Юзеев та шигырендә
"Мин дә, дигән, Мулла Иленнән".

Толстой да белгән Мулла Илен,
Кунак иткән сөеп Гайнанын.
Хәтта Ганди белеп Һиндстанда
Горур йөрткән Сардар байрагын.

Ник хикәят миңа сөйләмәскә
Безнең Вәисиләр турында.
Сөйләмәсәм, Мулла Иле рәнҗер,
Бер үкенеч калыр рухымда.

Горурланып монда туганыма
Һәм сөенеп монда яшәүгә,
Сөйлим Вәисиләр хикәятен
Истә тотсыннар дип яшьләргә.

Мин мәктәпкә йөрдем гомерем буе
Урап Вәисиләр урамын,
Уйлап ар баштагы буш нигездә
Шагыйрь Баһаветдин торганын.

Бу нигездә булган чарлаклы йорт,
Мулла йорты. Менә шушында
Шагыйрь үскән иркен табигатьтә,
Иркен уйлар йөртеп башында.

Хәмзә мулла үз улына яшьтән
Яшәү хикмәтләрен сеңдергән.
Бакча артындагы Кирәмәттә
Серләшкәннәр алар гел бергә.

Кирәмәт ул – шундый изге урын:
Түгәрәк күл, куе камышлар,
Ап-ак төнбоеклар арасында

Йөзеп йөри пар-пар аккошлар.

Әчкелтем ис бөркеп, йон яудырып,
Тып-тын тора биек тупыллар.
Ата белән бала зикер әйтә,
Зикер әйтә барлык былбыллар.

Изге җир бу...
Кирәмәт ул – изге агач исеме,
Исем генә калган аңардан;
Нәкъ шушында туктап нигез салган
Мулла бабай килеп Болгардан.

Зикер әйтеп дога кылгач, ата

Алып керә улын зиратка.
Биек агачларның кочагында
Кирпеч төрбә тора бер якта.

Яшел мүкле кызыл кирпечләрдән,
Ак мәрмәрдән изге хәрефләр
Монда, диләр, Вәисиләр нәселе,
Ата бирә барсын шәрехләп.

Ихлас белән малай сәждә кыла
Барлык әрвахларның рухына.
Алар нәселе гади нәсел түгел,
Лаек булсаң иде шушыңа.

Шәҗәрәсе алар нәселенең
Пәйгамбәргә барып тоташа.
Малай моны яхшы белеп үсте,
Фикер йөртте гасырлар аша.

Ата мәдрәсәсе яшь гакылга
Күпме гыйлем, сафлык иңдергән!
Уналтысы тулгач, Баһаветдин
Чыгып китте Мулла Иленнән.

Ул өйрәнде изге Бохарада
Дәрвишләрнең хикмәт серләрен,
Нәкышбәнди(1) суфи тәрикатен(2),
Руми, Хафизларның(3) телләрен.

Ун елдан соң тормыш өйрәнергә
Чыгып китте Рәсәй буйлата.
Ә тормышта хаклык, хакыйкать юк,
Утырып-утырып уйлар уйлата.

Йөргән чакта шулай дөнья гизеп,
Кулаткыда(4) – Сембер җирендә
Җәгъфәр(5) ишан аны таң калдырды,
Урын алды йөрәк түрендә.

Хөр фикерле Җәгъфәр мәдрәсәдә
Өр-яңача гыйлем укыта.
Шәкерт булып калды Баһаветдин,
Күңелләрен хөрлек яктырта.

Хисләр ташый, уйлар ургый баштан,
Язарга да хәзер язарга.
Кырык яшьлек шагыйрь Баһаветдин
Яшәү өчен килде Казанга.

Мәһабәт ир, олпат гәүдәле ир,
Давылларга түзем нык бәдәм,
Мәрҗани һәм Насыйрига менә
Тиң булырлык яңа чын адәм.

Вәис дигән тәхәллүс тә алды,
Вәис – изге гарәп ул булган.
Рәсүл үлгән чакта үз чапанын
Шул суфига биреп калдырган.

Колшәрифтән соң менә Казанда да
Татарлардан булды бер шагыйрь.
Чын безнеңчә милли академны –
“Дәүләт гыйрфан йорты”н(6) ачкан ир.

“Милләтемнең асыл галимнәре!
Тупланыгыз, әйдә, бу йортка!
Бу тарлыктан ничек чыгу юлын

Өйрәтегез, әйдә, халыкка!

Котылыйк без явыз түрәләрдән –
Мәзлумнарны талый ул этләр",
Һәм "Коткару фиркасе"нә(7) менә
Илһамланып керә мөритләр.

Үз йортын ул шулай дәүләт итте,
Мөһере бар һәм нәшрияты.
Ул китаплар шунда бастыра да,
Мөритләре йөри таратып.

Кара костюм, галстук һәм ак күлмәк,
Сары кәвеш кигән аякка.
Вәис мөритләрен кабул итә,
Сакчылары тора ян-якта.

Җиңнәрендә ярым ай аларның.
Бәйләвечләр көмеш йолдызлы,
Шагыйрь йөрәгендә тик бер теләк:
Үзгәрергә кирәк тормышны.

Баһаветдин үзенең тәхетендә
Аяк катлап менеп утырган.
Тоткан тәсбих – атасыннын калган,
Бер кулында – калын зур Корьән.

Ак чалмадан, кара мыеклары,
Шундый тигез итеп кырылган.
Акыл көче бәреп тора эчтән,
Йөзе балкый илһам нурыннан.

Рус Казаны уртасында әнә
Ул бердәнбер татар шагыйре.
Мең сорау һәм өзгәләнү белән

Ташып чыга һәрбер шигыре.

Ильминский(8) һаман тукып тора:
“Ислам белән көчле татарлык!
Шул исламнан кирәк биздерергә -
Татарлыкны ватып атарлык!”

“И, галимнәр! Булып изге һәм дә гадел,
Ияртегез, җитәкләгез бар халыкны!
Тик “Фиркаи Наҗия”гә кереп
Җиңәр алар явызлыкны, усаллыкны.

Шигырьләрем, сез яшендәй кабыныгыз,
Явызлыкны көйдерегез, яндырыгыз!”
Баһаветдин! Алып чык син Казаныңны
Милли шигъриятьнең олы язларына.
Кайнасын ул әверелеп милләтеңнең
Һич тә тынмас, көче бетмәс казанында.

---

Хатлар язды шагыйрь Баһаветдин,
Шигъри хатлар язды патшага,
Хатынына, ничә министрга,
Дошманнары янап ятса да.

“Галиҗәнаб патша хәзрәтләре!
Хак сагында торган хөкемдар!
Татарларың хөрлек өмет итә,
Татарларга нигә урын тар?

Рәхимең киң, изгелекләр эшлә,
Татарларның моңа хакы бар”.

Хатлар, хатлар... Алар өчен күпме
Эләктерде җирле түрәләр.

Шул түрәләр, азатлыкны буып,
Халык талап рәхәт күрәләр.

---

Петербургка килде Баһаветдин,
Өермәләр дулый эчендә:
Сарайлары олуг падишаһның
Татар сөякләре өстендә.

Шигырьләрен бирде цензурага,
Шигырьләре дөнья урасын.
Ник бер шигырен басып чыгарсыннар –
Ул бит явыз татар урдасы.

Ул шигырьләр әле һаман шунда,
Петербургта ята – подвалда.
Татар сөякләре сыкрый төндә,
Ирек даулый җырлар һаман да.

---

“Надан муллаларың утыра түрдә,
Корьәнне дә бозып аңлатып;
Тамакларын кырып,башны иеп,
Буш сүз чәйнәп, хөсет таратып.

Күзләрендә - минлек сукырлыгы,
Телләрендә - сәүдә хәйләсе.
Җыелып ашый алар илнең хакын,
Хурлап хакны,
Медаль алды ничәсе”.

---

Мәзлумнарның аһы яна илдә,
Ялкыннары уйный калебтә.
Бәрәкәтләр иңеп ил өстенә,
Хөрлек килсен иде халыкка.

Яна Казан, Сембер, Уфа, Рымбур,

Дәрдмәндләрнең яна аһ-ваһы.

Яна көлли(9) Рәсәй, яна Галәм,

Бигрәк авыр, авыр чыдавы.

Алам, имди, каләм, язам сәлам,

Гарип күңелләрне сауларга.

Менәм, имди, атка, алам кылыч,

Чыгам аждаһалы юлларга.

---

Ә бер төнне...

Кара йөзләр килделәр дә

Туздырдылар “Дәүләт гыйрфан йорты”н...

Үтерделәр сөйгән хатынын...

Үзен алып киттеләр

Акылсызлар йортына.

Китаплары калды янып...

Кәхкәхә белән көлде битараф халык.

Бәрәкәтләр нидән очкан? Нидән

Дөнья тулы тарлык, кахытлык?

Хаклык өчен җанын биргәннәрнең

Белерлрме кадерен бер заман?

Аһ, белсәләр кадерен газизләрнең

Булыр иде төзек бу җиһан!

---

Акылсызлар йорты.

Баһаветдин “комиссия” уза.

“Саташкан бу!” – диләр докторлар.

(Шагыйрь җанын килеп кем яклар?)

О, докторлар!

Кайда сезнең Гиппократ анты?

Акча өчен антны сатамсыз?

- Ялган!!!

Күзләрендә яшен яшьнәп,

Күкрәгендә күкләр күкрәде,

Шагыйрь үзенең шигырь төргәкләрен

Күзләренә китереп терәде.

– Тикшерегез!

Мондый шигырьләрне

Юләр кеше яза аламы?!

Бөтен Казан буйлап өне китте:

– Хаклык уты җирдә янамы?

---

Казаннарга килсәм, борылып керәм

Мин юләрләр йорты янына.

Бу йорт һаман элеккечә сары,

Кыен монда, кыен җаныма.

Тимер челтәр аша тәрәзләрдән

Сары йөзләр күзли дөньяны.

Тәрәзләрдән йөрим тәрәзләргә,

Бер тотармын кебек мин аны.

Шагыйрь миңа һаман шунда кебек,

Тәрәз аша танып алыр да

Тимерләрне ватып чыгар кебек,

Әйтер кебек: Саумы, авылдаш!”

Явыз дөнья өчен ул кадерсез,

Явыз дөнья иткән каберсез.

Таш диварлар булып өне килә:

- Кала күрмәгезче хәтерсез!”

Ун ел буе минем хәтеремне
Шушы йортка бикләп тоттылар
Һәм сүндереп йөрәк ялкынымны
Җәсәдемне утка яктылар.

Бөтен Казан буйлап өне килә:
- Хаклык уты җирдә янамы?
Тикшерегез! Мондый шигырьләрне
Юләр кеше яза аламы?

Мең сорау һәм өзгәләнү белән
Баһаветдин яши күңелдә.
Сары йортка улы Гайнан килә,
Насыйп булмасмы дип күрергә.

*1 Нәкышбәнди Баһаветдин – XIV гасырда яшәгән күренекле шәрыкъ философы.*
*2 Тәрикать – Нәкышбәнди тәгълиматы.*
*3 Руми, Хафиз – бөек шәрыкъ шагыйрьләре.*
*4 Кулаткы – Сембер өлкәсендәге посёлок (Ульяновск).*
*5 Җәгъфәр Салихов – XIX гасырда яшәгән күренекле татар педагогы, Б.Вәисовның остазы.*
*6 “Дәүләт гыйрфан йорты” – Б.Вәисов тарафыннан 1862 нче елда Казанда ачылган уку йорты.*
*7 “Коткару фиркасе” (“Фиркаи Нажҗия”) – Б.Вәисов тарафыннан Казанда 1862нче елда төзелгән фирка (партия).*
*8 Ильминский – рус миссионеры.*
*9 көлли – бөтен.*

2000, февраль

**Безнең Сабантуй**

Хәтфә җәеп Әрә буйларына,
Тагын җитте җылы җәйләрем,
Тагын чыктым Сабантуйларына –
Балачакка кайттым әйләнеп.

Балачакта безнең дүрт ел рәттән
Сабантуйны халык күрмәде.
Ир-атларсыз калдырып авылымны.
Сугыш туе җирдә дөрләде.

Яшь кызларның чиккән сөлгеләре
Сандыкларда калды тилмереп;
Безнең атлар китеп яу кырына.
Ут эченә керде илереп.

Без тәүге кат Сабан туен күрдек,
Сугыштан соң – кырык алтыда.
Мәйдан тулы кулсыз-аяксызлар,
Җөйле йөзләр иде каршымда.

Ләкин шунда бер могҗиза булды:
Аһ-зарларга баткан халыкның
Сабантуйда аккан сихри моңнан
Мең хәсрәтле йөзе яктырды.

Сабан туе юды кайгыларны,
Йомшак җилләр үпте маңгайдан.
Ак болытлар күзне иркәләде,
Тәмле исләр килде тугайдан.

Без, малайлар, чың-чың, дөп-дөп иткән
Кәмит атларына атланып,

Әй әйләндек гаҗәп орбитада
Бар кайгыны онытып, шатланып.

Сабантуй ул шулай була икән:
Бар дөньяны итә түгәрәк.
Халкың белән барлык хәсрәтләрне
Җиңеп була икән бергәләп.

Яшьлектәге Сабантуйлар истә:
Күкрәкләрдән тора көч ташып,
Җитмеш егет бергә кочаклашып,
Зур түгәрәк булып тоташып,

Сызгырышып, башны артка чөеп,
Җырлап үттек мәйдан тирәли.
Шул чактагы тальян кире кайтса,
Бирер идем бүген әллә ни.

Калды яшьлек түп-түгәрәк булып,
Калды артта моңлы җыр булып.
Юк, калмады – һаман үзем белән
Йөрәгемне яши җылытып.

Бүген тагын чыктым Сабантуйга,
Һаман шулай шаулый бу мәйдан.
Өн килә күк тәүге Сабантуйдан –
Бик еракта калган малайдан.

Яшь киленнәр чиккән сөлгеләрнең
Җилфердәгән чагы җилләрдә.
Дәртләренә дәрман – сөлге бәйләп,
Мәйданнарга чыккан ирләргә!

Сабантуйлар –безнең уртак тарих,
Сабантуйлар – халкым тарихы.

Сабантуйда аның бөтен халкы,
Шигърияте, ирке һәм рухы.

Сабантуйлар халкым кебек сабыр,
Халкым кебек тыйнак, ягымлы.
Халкым кебек олы, киң күңелле,
Халкым кебек дәртле һәм моңлы.

Татар җаны шәфкать белән тулы:
Миһербанлы изге әбиләр,
Күр, ахырдан килгән атка җәлләп,
Дога укып яулык бәйлиләр.

Сабаннарга җиһан табыныр һаман,
Сабантуйлар булыр һәр заман.
Җир туфрагын снарядлар түгел,
Назлый-назлый йөрер тик сабан,
Халкым яшәр көләч, мул һаман.
2005

**Аксакал монологы**

**1**

Без белмәгән серле чиксезлектә
Җир дә, Күк тә әле юк чакта
Мәңге тере барлык – бөек Ходай
Үз нурыннан нурлар яраткан.

Яратылыш! Нинди гүзәл бу хәл!
Әлмисак дип аны атыйбыз.
Җан хәтле җан иҗат итүчене –
Аны гына фәкать мактыйбыз.

Әлмисактан бирле мин мөселман,
Әлмисакта минем җаным да,
Бар иткәне өчен рәхмәт укып,
Сәҗдә кылган Раббы каршында.

Бар иткән Хак юктан Җиребезне,
Җирдән хасил иткән Кешене,
Аңа тиеш җанны иңдергән Ул,
Кушып Адәм дигән исемне.

Урнаштырган аны Җәннәтенә
Һәм Һаваны аңа пар кылган,
Сынар өчен тәүге кешеләрен
Иблис дигән затны бар кылган.

Тәүге гөнаһ – хәрам җимеш өчен
Адәм-Һава җиргә сөрелгән.
Шуннан бирле кеше сыналуга –
Нәфес коллыгына бирелгән.

Кеше дигән олуг бәндәсенә
Мулдан биргән Ходай байлыкны.
Җан идарә итә тәне белән,
Аң яктырта бөтен барлыкны.

Җан язмышы Аллаһ хозурында,
Аңның көчен акыл билгели.
Акыл белән бәндә фикер кыла,
Гыйлем җыя, теләкләр тели.

Бөтен нәрсә парлы, капма-каршы,
Көн-төн, мәхәббәт һәм нәфрәт бар.
Ходай безне сыный бертуктаусыз,
Ә кабергә кадәр ара тар.

Шөкер, Ходай үзебез арабыздан
Пәйгамбәрләр җиргә иңдергән.
Алар аша Бөек Хакыйкатьне –
Яшәү серен безгә сеңдергән.

Пәйгамбәрләр инде башка килмәс,
Иң соңгысы безнең Мөхәммәт
Шәфәгатьче булыр мөэминнәргә,
Тик ул гына кылыр мәрхәмәт.

**2**

Диварымда менә җир картасы,
Өстәлемдә - йомры глобус.
Бик зур да бу дөнья, бик нәни дә,
Җиде миллиард кеше булабыз.

Җиде миллиард бер Кояшны күрә,
Бер һаваны сулый һәр төштә.
Ләкин кеше ничек төрле-төрле,
Җиһан яши этеш-төртештә.

Җиде миллиард кеше бу дөньяда,
Күпме миллиард ята бакыйда.
Һәркемнең бар эчке үз дөньясы –
Кабатланмый торган беркайда.

Минем дә бар үзем корган дөньям,
Керә алмый анда беркем дә.
Глобусны кеше әйләндерә,
Ә җир шары – Аллаһ иркендә.

Глобуста мин яшәгән кыйтга
Күңелемне йомшак иркәли.
Мулла Иле дигән изге нокта
Галәм гизә Кояш тирәли.

Шул ноктада гомер сөреп ятам
Һәм кояшка карыйм сөенеп,
Бер төчкерү белән күкрәкләрем
Рәхәтлеккә китә тиенеп.
2005

## Иман нуры

Галәмнәрне яратудан әүвәлдә,

Күкләр, җирләр әле бер дә юк мәлдә,

Бөек Аллаһ – мәңге тере хак Барлык,

Үзенең хозурыннан бер ак нур алып,

Аны Гареш[1] шәрифенә юллады,
Исемләде “Мөхәммәд” дип ул аны.
«И нур, - диде, - син хәбибем[2] бул минем,
Бар галәмгә рәхмәт булыр бу исем”.

Нур Гареш тә тәваф[3] кылды көн саен,
Бар иткәнгә бик олылап Ходаен[4],
Хәмед[5] әйтте раббысына һәрдаим:
“Әлхәмдүлилләһи Раббил-галәмин[6]”.

Хәмед әйтте шулай биш йөз ел... һәм дә
Ирешелде Нур Атабыз Адәмгә[7].
Шул Нур хөрмәтенә барлык фәрешгтә
Атабызга сәҗдә кылды Гарештә.

Узды чорлар, туфрак булды шәһәрләр,
Килеп китте күпме нәби, пәйгамбәр.
Ә Нур, шулар аша кичеп чорларны,
Мостафаның[8] үзенә килеп уралды[9].

Галәмнәрне нурлап туган баланы
“Мөхәммәд” дип исемләтте Аллаһы.

Менә кемгә бирде Ходай Коръәнен,
Раслап аны бик тә якын күргәнен,
Менә кемне Мигъраҗга ул ашырды,
Менә кемгә хөкемнәрен тапшырды.

Камил акыл, күркәм холык иясе,
Гүзәллектә һич булмады тиңдәше,
Вөҗданы пакь, Рәүшан нурлы күкрәге,
Бер дә тапсыз чын сафлыкта йөрәге.

“Син булганга, бар иттем, дип, Галәмне” –

Ирештергән Ходай шундый хәбәрне, -
“Әлхәмдүлилләһи Раббил-галәмин –
Бар дөньядан артык моны сөям мин”.

“Әлхәмдүлилләһи Раббил-галәмин –
Һаман шулай хәмед кылды Әл-Әмин[10].
Ул Аллаһтан тиңсез гүзәл сан алды –
Нурланып күренү белән данланды.

Коръән, Сөннәт[11] – исбатланган хакыйкать,
Коръән, Сөннәт – бар сорауга хак җавап.
Бөек илче, сәлам сиңа, салават,
Инсаннарга маяклы юл, үрнәк зат.

Сине бәяләрлек үлчәү юк җирдә,
Кимчелегең, хаталарың юк бер дә,
Җибәрелдең барлык-барлык кавемгә,
Мөэмин синнән шәфкать көтә кабердә.

И кавемем – Ислам әһле татарым,
Иҗтиһат ит, булчы гүзәл әхлаклы,
Фанилыкта урның булыр мактаулы,
Сыналудан узарсың син лаеклы.

Расул шәригате – соңгы шәригать,
Башка Расул килми, килми бер Китап.
Барлык галәм өчен, барлык халыкка
Соңгы хөкем, соңгы канун чынлыкта.

Бу шәригать – камил, сөннәт нурлары
Кыяматкә чаклы бөтен дөньяны
Керсез иман белән торыр балкытып,
Инсаннарга дөрес юлны яктыртып,

Аллаһ иҗат иткән чиксез барлыклар,

Әйтә гүя: фикерләгез халыклар!
Күр, гөлләрне – мең-мең төстә ачылып,
Аллаһыга зикер әйтә ашыгып.

Әмма бәндә һич аңламый – азына,
Барлыкларга шөкер итми – азсына,
Өлгерергә теләп малның барына,
Төшә бара төпсез гөнаһ базына.

Гомер сөрү – ул бит чәчү, үстерү,
Ахирәткә урыр уңыш күчерү.
Гомер сөрү үкенечкә калмасын,
Игенебез ахирәткә мул барсын.

Купшы кием киеп кенә яшәмик,
Ул бит туза, гомер уза – нишләтик.
Киик Аллаһыдан иңгән киемне –
Аллаһыдан курку дигән киемне.

Хәмед әйтик – ул да, син дә, һәм дә мин:
“Әлхәмдүлилләһи Раббил-галәмин”.
Бар күңелләр көннән-көнгә яхшырсын,
Пәйгамбәрнең нуры белән яктырсын,

Әлхәмдүлилләһи Раббил-галәмин,
Кичер, Раббым, күп гөнаһлы бәндәң мин.
Аллаһүммә, салли гәлә Мөхәммәд,
Насыйплар кыл Расулеңнән шәфәгать.

1.Гареш – югары күк.
2.Хәбибем – дустым.
3.Тәваф кылды - әйләнде.
4.Ходай – Аллаһы Тәгалә.
5.Хәмед – мактау.
6.Әлхәмдүлилләһи Раббил-галәмин – “Фәтиха” сүрәсенең беренче аяте.

7.Атабыз Адәм – Пәйгамбәр Адәм г.с.

8.Мостафа – Мөхәммәд г. с. нең өстәмә исеме – “сайлап алынган”.

9.Югарыдагы бу риваять “Пәйгамбәрләр тарихы”ннан
алынды. “Пәйгамбәрләр тарихы”, Казан, 2003нче ел, 342нче биттә.

10.Әл-Әмин – Пәйгамбәребезнең өстәмә исеме.

11.Сөннәт – шәригать хөкемнәре.

2009

**Пәйгамбәрдән килгән сәхабәләр**

**(*Җанга якын риваятьләр)***

*“2009нчы елның 13нче июнендә егерменче мәртәбә Изге Болгар җыены үткәрелде. Бу юбилей Идел буе Болгарстанында ислам дине кабул ителүнең 1120 еллыгы, Болгар бабаларыбызның җиренә Мөхәммәт пәйгамбәр сәхабәләре килүнең 1420 еллыгы буларак зурлап уздырылды. Әлеге өч сәхабәнең берсе шушы туфракта мәңгелек йортын тапкан.”* “Ватаным Татарстан” газетасы, 16нчы июнь, 2009нчы ел

*“Бу мулла Иленең асылы бик күптәндер. Монда бер Муллагол дигән кеше Болгардан килеп утыргандыр.”* Каюм Насыйри

*I*

Болгар бүген халык белән тулы!
Бар ягыннан килеп Рәсәйнең
Татар дигән кавем нәрсә эзли
Хозур бер мәлендә бу җәйнең?

Ә мин үзем эзлим Муллаголның
Тапмаммы дип бер-бер ядкярен.
Хәрабәдән күчәм хәрабәгә,
Чал тарихны ядтан үткәреп.

Монда шәһәр чәчәк атып торган,
Еракларга данын таратып.
Шул Муллагол монда азан әйткән,
Идел киңлекләрен яңгыратып.

Җәмигъ мәчет нигезендә ташлар
Саклый кебек аның эзләрен;
Зур манара тәрәзеннән гүя

Күрәм кебек нурлы йөзләрен.

Гөлчәчәкле җиргә ятып тыңлыйм –
Ишетәм кебек аның сулышын;
Күз нурлары сеңгән диварлардан
Милли моңнар ташый тулышып.

...Монда мәхшәр булган, шәһәр тузган,
Шул дәһшәттән качып Муллагол
Килеп чыккан безнең аулак якка,
Сыену урыны тапкан монда ул.

Авылымны корган, үз янына
Туплаган да йөзләп качакны.
Салган мәчет, салган мәдрәсә дә,
Хезмәтләре булган тау чаклы.

Ул Муллагол, авыл исеме булып,
Гасырларга калган балкырга.
Авылымның чишмә башы – Болгар,
Серләр тулы хикмәт бар монда.

II

Егерме мең татар, саф-саф булып,
Атлап бара изге җирләрдән.
Хәзрәт кулындагы яшел байрак
Әй җилферди иркен җилләрдә.

Җанланалар ак таш хәрабәләр,
Тере булып атлый хәтерләр.
Ә кылганнар – ап-ак чәчле тарих
Озата бара безне кадерләп.

Ошбу җирләр җанга якын булган
Риваятьләр белән үрелгән:

Нух оныгы Алып, монда килеп,
Чабатасын кагып йөрегән.

Кулын болгый-болгый елаганга,
Болгар исеме кушкан улына.
Улы, үсеп җиткәч, Болгар дигән
Кала салган Идел буена.

Сахра тулы тәмле әрем исе,
Идел җиле шундый ягымлы;
Күкләр шундый биек, рухи сафлык,
Яшәү көче били җанымны.

Күңел кошым заманнарны урый,
Бүгенгедән бик тә риза ул.
Мин Муллагол булып атлыйм гүя,
Һәм мин булып атлый Муллагол.

Монда мәшһүр тарих тыюлыгы
Үзенә тарта, үзенә чакыра.
Безнең кавем кыйбласын тапкан
Бу туфракта күңел яктыра.

Килеп җиттек кече манарага
(Менгәнем бар аңа минем дә,
Шунда менеп Тукай, Толстой да
Карап баккан булган Иделгә).

Чал сакалын чилдә җилфердәтеп,
Үр-мөнбәрдә сөйли Таҗетдин:
«Пәйгамбәрнең исән чагында ук
Килеп җиткән монда безнең дин,

Пәйгамбәрдән безнең ошбу җиргә
Алты йөз дә утыз икедә

Өч сәхабә килеп болгарларны
Өйрәткәннәр безнең хак дингә.”

Һәм Таҗетдин шунда сәхабәнең
Кабер урынын безгә күрсәтте.
Бу хикмәттән күзгә яшьләр килде,
Изге икән болгар шулхәтле!

Җиргә рәхмәт итеп җибәрелгән
Пәйгамбәрне күргән сәхабә,
Аның нурын монда ирештереп,
Бабаларга биргән мәртәбә.

Йөрәкләрдән ургып-ургып чыга
Пәйгамбәргә сәлам-салават.
Ул нурлады Бөек Болгар җирен
Ул бердәнбер безгә үрнәк зат.

Хикмәтләрдән рухым канатланды:
Нинди гүзәл безнең узган юл!
Гүя янәшәмдә тере булып
Басып тора безнең Муллагол.

Муллагол бит үзен пәйгамбәргә
Ерак кардәш итеп санаган.
Бу риваять бөтен тарих буе
Авылым хәтерендә саклanган.

Риваятькә бүген ышандым мин:
Безнең җиргә килгән сәхабә
Бер кардәше, димәк, пәйгамбәрнең,
Аннан калган нәсел-нәсәбә.

Авылымны корган Муллаголның
Шәҗәрәсе гасырлар аша

Җиргә рәхмәт итеп җибәрелгән
Пәйгамбәргә барып тоташа.

Бу туфракта соңгы йортын тапкан
Сәхабәнең рухы шат булсын.
Гүре бакый ахыйрәткә чаклы
Изгелеге белән балкысын.

Ирештер гел, Раббем, догабызны
Болгар бабаларның рухына;
Алар каршында без зур бурычлы
Илткән өчен ислам юлына.

Пәйгамбәргә әйтик салаватлар,
Көннән-көнгә әхлак яхшырсын.
Күңел Пәйгамбәрне сөю белән,
Шәфкать нуры белән яктырсын.

III

Мулла Илем! Мәчетең бит һаман
Шул Муллагол корган нигездә!
Тәү мәчетне монда ул корган бит,
Имам булган – иман тергезгән.

Мин – бүгенге имам – бик үз итеп
Калебемдә йөртәм гел аны.
Мин аңарга лаек булса идем –
Аллаһ йорты – ошбу бинаны

Ул күрергә теләгәндәй итеп
Исән-имин саклый алсамчы!
Муллаголның изге васыятьләрен
Киләчәккә алып барсамчы!

Мин мөнбәрдә аны күрәм төсле,

Ишетәм күк аның вәгазен –
Динне, телне мәңге үзгәртмичә
Нык сакларга чакыру авазын.

Сөйләгәндер хәзрәт хикмәтләрен
Нәкъ хәзерге авыл телендә.
Татар теле дә бит – Аллаһыдан! –
Яңгырасын мәчет түрендә.

Тәүге имам Муллаголдан алып
Соңгы имам – миңа кадәрле
Узган чорлар хәтерләрдә яши,
Хәтер исә чиксез кадерле.

Безнең тарих эзле, бик тирәндә,
Юк, югалмас безнең хәтерләр!
Халкым рухын, телен, динен
Саклар авылым, саклар кадерләп.

Мин берьяклы мулла була алмыйм,
Коръән укыганда төннәрен
Нечкәрә дә күңлем саф яшь белән
Яд итәдер әллә кемнәрен.

Мин – җирнеке. Аллаһ биргән хәтле
Дөньялыкның алдым гыйлемен,
Үз телендә укыйм Гётене мин,
Рус телендә - Пушкин шигырен.

Изге Коръән Аллаһ тарафыннан
Иңдерелгән гарәп телендә,
Иншә Аллаһ, мин дә гарәп телен
Йөртәм һәнүз күңел түрендә.

Мәкам белән Коръән укыганда,

Һәр аятьтән чыккан тәфсирләр
Йөрәгемдә татарчага күчеп
Ясый миңа гаҗәп тәэсирләр.

IV

Зиратыбыз... Изге туфрагында
Борынгылык йоклый, болгарлык.
Монда ташлар, җилгә бирешмичә,
Дәверләрне кичкән, чорларны.

Шул үрдәге ташка нәселемнең
Шәҗәрәсе уеп язылган.
Унбишенче бабаң Муллагол дип
Бик ерактан сөйли гасырлар.

Килер бер көн: мин дә Муллаголдай
Гүр иясе монда булырмын
Нәселем килер, рухым яд итәрләр,
Шулар хәтерендә калырмын.

Дөнья үтәр, иң чын хөкем булыр,
Гаделлекнең Бөек Мизаны
Дөреслекнең ясар тантанасын –
Хисап көне дибез без аны.

Рәсулебез өммәтендә яшәп,
Савап җыйыйк дөнья йөзендә.
Пәйгамбәрнең шәфәгатен, Раббем,
Насыйплар кыл мәхшәр көнендә.

Кичер, Раббем, безнең гөнаһларны,
Тәүбәләрне, Раббем, кабул кыл.
Иман белән нурла җаныбызны,
Калеб күзебезне якты кыл.

***Сүзлек***

1.Һәнүз – мәңге

2.Мулла Иле Татарстан Республикасының Яшел Үзән (Зеленодольск) районындагы авыл

3.Муллагол – Болгардан күчеп килеп, Мулла Иле авылына нигез салган хәзрәт

4.Тәлгать Таҗетдин - Россия мөселманнарының баш мөфтие

5.Гёте, Пушкин Коръән аятьләренә нигезләнеп шигырьләр язганнар

6.Мизан – үлчәү

7.Калеб – күңел

2010

# Хикәяләр

## Бу кырлар, үзәннәрдә минем...

### ( нәни хикәятләр )

Без утырткан нәни наратлардан
Шаулап үсте калын зур урман.
Урман үскән чакта гомерләрнең
Үтүләре өчен кайгырмам.

#### Тимерче тимерче булып кала

Сугыштан соң Берлиннан тимерче Гафият абыйдан да бер-бер артлы посылкалар килеп төшә. Күлмәклектер дип өметләнгән хатыны Нәгыймә ачып караса - барысы да ялтырап тора торган тимер. Хат кисәгенә болай язылган: "Болар уникаль инструментлар, югалта күрмә. Кайткач, алар белән колхозны аякка бастырам".

Хәл белергә кергән күршесе Әсма әбигә әйткән Нәгыймә апа:

- Җәһәннәм тишегендә дә тимерче булып кала икән. Анда да уенда гел колхоз гына икән

#### Сүгенүгә каршы көрәш

#### "Ата дуңгызларны сатыгыз!"

Ферма каравылчысы Гариф абзый сүгенү буенча авылда беренче урында тора иде. Беркөнне фермага район башлыгы Данил Хафизович Хәялиев килеп төшә һәм күрә: Гариф абзый, озын торыгын селтәп, аргы баштан бер көтү дуңгыз балалары куып килә, үзе бертуктаусыз сүгенә:

- Кая барасыз, анагызны?! Дуңгыздан туган дуңгызлар, анагызны... Хәзер мин сезгә акыл тегәм!

Ферма мөдирен күргәч, әйткән ди башлык:

- Ата дуңгызларыгызны иртәгә үк сатыгыз. Сезнең монда аларны алмаштырырыга кеше бар икән. Экономия булыр.

**"Минем сакал белән уйнама!"**

Шуннан соң иптәш Хәялиев, "Искра" колхозының бөтен активын җыеп, киңәшмә үткәргән:

- Гариф абзый ярый әле бер дуңгызларга гына сүгенә. Калганнар һәр сүз саен кеше аналары белән сүгенәләр. Хәтта, әйтергә оят, хатын-кызлар да ирләр булып сүгенәләр. Сезгә бер атналык срок - бу әхлаксызлыкны бетерәсез.

Иртәгесен ферма мөдире Шәфигуллин, барлык коллективын җыеп, кимәшмә үткәргән.

Төрле чыгышлар булган:

- Сөекле шагыйребез Такташ та сүгенгән бит. Чемберленның сатыйм анасын дигән.

- Безнең эш шундый бит: сүгенмичә бармый.

- Әллә без теләп сүгенәбезме?! Үзеннән -үзе ычкынып китә бит, итиомать.

- Сүгенү нервыларга файдалы дип, язалар ич китапларда.

- Иптәшләр, элегрәк әйтмәдек бит бу турыда, - дигән иптәш Хәялиев. - Тормыш авыр чакта тыймадык бит. Ә хәзер коммунизмга җитеп килгәндә, сүгенмичә дә рәхәтләнеп яшәргә тиешбез. Озын сүзнең кыскасы: бер атна срок - сүгенүне бетерәсез.

Карт коммунист Шәйхетдин абзый рационализаторлык тәкъдиме кертте (үз гомерендә кеше алдында бер мәртәбә дә аракы эчмәгән зат):

- Җәмәгать, әгәр сүгенмичә бер дә тора алмыйсыз икән, әшәке сүз урынына матур сүзләр әйтегез. Ягъни мәсәлән, "Сакалыңны себерим!" дип җибәр, я булмаса русча "Ёлки палки!" дип куй, әдәпле генә итеп.

Иртәгесен ферма мөдире яңа тәртипне үзе башлады. Аңа иң беренче каравылчы Гариф абзый очрады.

- Гариф абзый, сакалыңны себерим, син нигә кичә җыелышка килмәдең?! Аң бул: сүгенүне бетерәбез, ёлки-палки! Иң элек синнән башлыйбыз, сакалыңны себерим!

Гариф абзыйның җан ачулары чыкты:

- Син, энем, анаңны!.. Минем сакал белән уйнама яме! Үзең дә картаерсың, итиомать.

**Ике көймә койрыгын тоталар**

Бер атнадан иптәш Хәялиев нәтиҗәне карарга килгән иде. Бөтен ферма территориясе "Сүгенмә, иптәш, нык бул!" дигән лозунглар һәм плакатлар белән бизәлгән иде. Авылның мәшһүр шагыйре Сәйфи сүгенүгә каршы гүзәл такмаклар язган, һәвәскәр композитор Хисами аларны көйгә салган, клуб каршындагы үзешчән хор бар тавышка җырлый, мәктәп директоры магнитофонга яздырткан, һәр бинада шул җыр, шул көй агыла. Беркемнең дә сөйләшкән сүзен ишетеп, аңлап булмый.

Иптәш Хәялиев, бик күңеле булып, болай дигән:

- Берьюлы ике көймә койрыгын тоталар болар. Беренчедән, музыка астында сыерлар сөтне күпкә арттыра, икенчедән, сүгенүгә каршы нинди үтемле чара уйлап тапканнар - бер генә әшәке сүз ишетелми.

Бер айдан ферма мөдирен партком секретаре итеп сайлап куялар.

**Китап искергән**

Туксанынчы еллар уртасында акча миллионнар белән исәпләнә башлады. Укытучыларга хезмәт хакына төргәк-төргәк купюраларны банктан капчык белән алып кайта идек.

Шул заманда икенче сыйныфта укучы бала укытучысыннан сорый икән:

- Апа, нигә безнең китаптагы мәсьәләдә икмәк 16 тиен тора диелгән, ә кибеттә 500 сумга саталар?

- Безнең математика китабыбыз искергән, укучылар, - дигән апалары.

**Хурлык киштәсе**

1985нче елның 18нче октябрендә Мулла Илендә дә "Эчүчелекне һәм алкоголизмны бетерү" чаралары турында КПСС ҮКның карарын тормышка ашыруга юнәлдерелгән гражданнар җыены булды. Җыен райпотребсоюздан Мулла Иле авылы кибетенә аракы кайтармауны сорарга дигән карарга килде. Дөрес, Шәйхи абый үз фикерен әйтеп карады:

- Аракы кибеттә булганда да аны алмаска була бит, иптәшләр. Торсыннар ул хәмер шешәләре кибет киштәләрендә, безнең күзләрне кызыктырып, ә без берне генә дә алмыйк, үзебезнең түземлекне, сабырлыкны сыныйк. Шешәләр торсыннар тилмереп, хурлык киштәсенә куелган кебек.

Ләкин район вәкиле Шәйхи абзый тәкъдимен карарга керттермәде.

**Мулла Иле авылына Иоһан Һоте килгән**

Элгәреге Төньяк Норлат районы газетасы "Ярыш"ның мөхәррире Шәңгәрәй Солтанов фронтта чакта да редакцияләрдә эшләгән. Аңа күп кенә шагыйрьләр, язучылар белән аралашырга туры килгән. Хәтта ул Твардовскийның үзе белән дә дуслашкан.

Берлинны алгач, Шәңгәрәй Солтанов та Мулла Иленә - әнисе Газзә апага бер-бер артлы берничә посылка җибәргән!

Газзә апа, чәй-шикәрдер дип сөенеп, посылкаларын ача икән, ләкин һәркайсыннан да алтын язулы, купшы тышлы ифрат матур китаплар килеп чыга икән. Хатында ул болай дип язган: "Әнием-бәгърем! Болар сөекле шагыйремнең кадерле китаплары. Күз карасыдай саклый күр".

Тәмләп чәй эчәргә өметләнеп кергән күршесе Гариф абзый сорый икән:

- Я, Газзә, улың нәрсәләр җибәргән?

- Һәй, Гариф, ул бит язучылар белән бергә сугышты. Бер дустының китапларын җибәргән.

- Яле, яле. Болар бит Иоһан Һоте дигән нимес кешесе китаплары.

- И бала, бала, - дигән Газзә апа, - нимес белән дуслашып та өлгерденмени?

**Салкын су эчкәнче**

Саранлыгы белән дан казанган Гыйрфан абзыйга бер капчык балык эләккән. Ничек алып кайтырга аптырап утырганда, моның янына Сабан туе батыры Рәхим килеп чыккан да, бар балыгын аркасына асып, күтәреп кайткан. Батыр тирләп пешкән. Капчыкны капка төбенә куйгач:

- Гыйрфан абзый, бер тустаган салкын су гына бир әле? - дип сораган.

- Инде бит, малай, кайтып җиттең. Салкын су эчкәнче, өеңдә кайнар чәй эч рәхәтләнеп, - дигән тегесе.

Файдалы киңәшкә рәхмәт әйтеп, батыр өенә китеп барган.

**Кем кушты?**

Мәктәпнең элекке директоры укытучыларның көндәлек дәрес планнарын тикшерергә һәм хаталар табарга ярата иде. Менә ул тиздән пенсиягә китәргә тиешле Камәрия апаның планын тикшерә икән.

- Педсоветта күпме мәртәбәләр әйтеп киләм: дәреснең мотивациясен кызыл фломастер белән әйләндереп алырга кирәк.

- Мин кызыл фломастер белән терәк төшенчәләрне әйләндергән идем шул.

- Кем кушты сезгә терәк төшенчәләрне кызыл белән әйләндерергә? Яшел белән әйләндерегез дип педсовет саен әйтәм ләбаса.

**Өч кешегә бер тун**

Туксанынчы еллар уртасында укытучыларга хезмәт хакын әйберләтә бирү галәмәте дә булды. Без, Мулла Иле укытучылары, автобуска төялеп, Зөя мех фабрикасына килдек һәм һәркем үзенең айлык акчасы бәрабәренә товар сайлый башлады. Укытучыларның берсенә яңа мода белән тегелгән тун ошады, тик бәясе өч айлык хезмәт хакы хәтле тора. Әмма ләкин склад мөдире җаен тапты:

- Тунны өч кешегә бүлеп алыгыз сез. Тун сезгә була, ә ике кешегә акчалата түлисез.

Акча күрергә бик аптыраган ике укытучының кулларына шул рәвешле тере акча керде.

**Идрис Туктар һәм кибетче**

1963нче ел, 19нчы декабрь. Идрис Туктар белән китап кибетенә кердем һәм шундый сөйләшүгә шаһит булдым.

- Сеңлем, алма китермәделәрме әле? Китерсәләр, егермене бирегез әле.

- Идрис ага, сез ялгышасыз: бу - китап кибете бит.

- Идрис абзаң алмаларын Сезгә җибәрәләр, сеңлем. Быел аның алмасы бик уңды.

Чыннан да, ул елны Идрис Туктарның "Алма" дигән китабы утыз мең тираж белән басылып чыккан иде.

**Укучылары жәл**

Гомеренең соңгы елларында Идрис Туктар "Җөмләләр" дигән баш астында бик кызыклы гыйбарәләрен бастыра башлады.

- Идрис ага, Сез ни өчен хәзер гел мондый жанрда язасыз? - дигән соравыма ул:

-Укучыларым ялыкмасын өчен, - дип җавап бирде.

**Ике Мәхмүт**

Безнең авылга килгән язучыларны кич кунарга Рокыя әби йортына кертәләр иде. 1976нчы елның июлендә биредә Мәхмүт Хөсәен кунак булып китә. Бер ай узуга, аңа тагын шуны алып киләләр. Хәйраннар калып, аңа карап тора да әйтә икән әби:

- Сез туп шикелле йомры идегез, әле кай арада аю хәтле булдыгыз?

Чынында бусы Мәхмүт Хәсәнов була.

**"Тегермәнеңне аша!"**

Мулла Илендә үтә намуслы коммунист Габдрахман абый бар иде. Сугыш бетеп, демобилизацияләнгәч, Горький шәһәреннән авылга кадәр араны җәяү кайткан. Чөнки батыр фронтовикның билет алырга акчасы булмаган, ә билетсыз кайтуны намусы күтәрмәгән.

Кайткач, намуслы булганы өчен, тегермәнче итеп куйганнар. Берничә айдан, өйдә бер дә он калмагач, ул, колхоз идарәсенә барып, он сораган:

- Үзегез беләсез: гаиләбез ишле, балалар күп. Үзем бер көн калмый тегермәндә эшлим. Ярдәм итегез, зинһар, - дигән.

Рәис, кырт кисеп:

- Тегермәнеңне аша!" - дигән. Өйгә кайткач, Габдрахман абый карчыгы белән киңәшкән. Тегермәнне ничек ашап була икән дип, баш ватканнар. Шулай да карчыгы, уйнап: "Стеналарга сырышкан онны сыпырып алырга кушкандыр", - дигән.

Чынлап та, иртәгесен шулай эшләгәннәр: стеналарын сыпыра торгач, берничә капчык он чыккан. Рәис килеп карагач, шаркылдап көлгән: "Минем сүзне менә син ничек аңлагансың икән!"

**"Түбән баш яна!"**

1964нче ел, 17нче июнь. Атбаш Шәйхетдин, тиз генә баш төзәтеп чыгыйм дип, кибеткә килеп керә. Ләкин кибет эче чират торучы халык белән шыгрым тулы икән.

- Җәмәгать! - дип кычкырып җибәргән шунда Шәйхетдин куркыныч тавыш белән. - Түбән баш яна!

Бар халык, өерелеп, кибеттән чыгып китә. Халык артыннан китәргә ашыккан кибетченең юлын бүлеп, әйткән Шәйхетдин:

- Тукта әле, туган, тукта. Түбән баш янмый, менә бу баш яна.

**Алдынгы буласы килми**

Халикъ абзый колхоз умарталыгында балдан югары уңыш ала. Тәҗрибә уртаклашырга дип, семинар үткәрәләр. Катнашучыларның һәрберсен мул итеп бал белән сыйлыйлар, күп итеп биреп тә җибәрәләр. Соңыннан умартачы колхоз рәисенә зарланган:

- Һәммә кеше шат, миңа гына күңелсез. Тәҗрибәм биреп бетте, кортларга да калмады. Зинһар, мине киләсе елга алдынгы рәткә куймагыз.

**Нинди әсәр өстендә?**

Бервакыт Мулла Иленә бер төркем язучылар килде. Араларында Мөсәгыйть Хәбибуллин да бар. Озата баручы кеше аңардан сорый икән:

- Мөсәгыйть абый, хәзер нинди әсәр өстендә эшләп ятасыз?

- Хәзер машина өстендә басып барам әле, - дип җавап биргән язучы.

**Чытыр өсте**

Апрель аенда Мулла Иленә язучы Галимҗан Гыйльманов килә. Күрә: бөтен кеше урамда, үзенең капкасы каршында балта белән чытыр (вак агач) турый. Әле газ кермәгән вакыт була бу. Кичен клубта очрашуда әйтә язучы:

- Мулла Илендә печән өсте, урак өсте генә түгел, чытыр өсте дә бар икән.

**Унбиш минут алда**

Янгын каравылы начальнигы Әхмәтша абзыйны, аның җитәкчелегендәге сүндерүчеләр янгынга соңга калып барган өчен, район җыелышында бик каты орышып кайтаралар. Әхмәтша абзый кайтуга кызган баш белән тегеләрне җыеп алган да катгый итеп болай дигән: "Моннан соң янгын башланганчы унбиш минут алдан килеп җитәсез!"

**Илһам Шакиров һәм администратор**

1987нче елның җәендә, август аенда булса кирәк, безнең төбәк авылларында концертлар куеп йөргән вакытында, "Искра" колхозы кунакханәсендә даһи җырчыбыз Илһам Шакиров яшәгән иде. Мин дә шул чакта аның белән яхшы гына танышып киттем һәм безнең мәктәп балаларына махсус бер концерт бирүен үтендем.

- Бик рәхәтләнеп, - дип шунда ук риза булды бөек артист. - Әмма ләкин администратордан рөхсәт сорап җибәрергә кирәк.

- Анысы инде вак мәсьәлә, анысын сорыйбыз! - дидем мин, шатлыкка тулып.

- Ул хәзер килеп җитәчәк, - диде яраткан җырчыбыз һәм Акъегет авылы кыр станына концерт куярга китеп барды.

Администратор килеп җитүгә, мин тиз генә шатлыгымны җиткерергә ашыктым:

- Сезгә зур сөенечемне җиткерәм, мин Илһам Шакиров белән сөйләштем: ул безнең мәктәп укучыларына да җырларга булды. Әмма ләкин бу турыда Сезгә дә әйтеп куярга кушты.

Шулай әйтүем булды - администратор коточкыч кыяфәткә керде: күзләре акайды, авызы чалшайды.

- Шакиров ул нәрсә әйтмәс! Шакиров та Сезнең кебек беркатлы деревенщина. Сабый бала сораса да ярар, ди. Шакиров минем кулда, ә мин администратор. Мин - хөкүмәт, ә хөкүмәт белән шаярырга ярамый. Понятно Вам?

Бөтен сөенечләрем минут эчендә коелып төште. Менә кем икән ул администратор.

**"Правда"га язып карагыз**

1978нче елның феврале. Чатнама суык. Мәктәпкә ягарга ташкүмер бетте. Аптырагач, тәвәккәлләп, беркатлылык белән Казанга - Ягулык министрына киттем. Министр бик әйбәт кеше булып чыкты: тиз генә кабул итеп, зарымны игътибар белән тыңлады.

- Менә монда карагыз әле, - диде, - графиклар күрсәтәм, Мәскәү беренче кварталда шуның кадәр күмер бирергә тиеш. Ә ул бүгенге көнгә кадәр чиреген дә бирмәгән.

Министр, миңа ялварулы күзләре белән карап, соңгы сүзен әйтте:

- Сез минем хәлгә керегез, зинһар. Минем үземә ярамый, сез бу хәлне "Правда"га язып карагыз әле.

Мин министрга башка бармадым. Күмерне "Сельхозтехника"да каравыл торучы абзый юнәтеп бирде.

**Җаныңны шутламас**

Гариф абыйның карчыгы Камилә апа бик карун, кысмыр кеше иде (урыны җәннәттә булсын). Кышкы чатырман суык көндә Гариф абый авырып ята икән. Ул вакытта өйне электр белән җылыталар иде. Камилә апа электр приборын әз-мәз генә эшләтә икән дә сүндереп куя икән. Гариф абый, түзәр хәле калмагач: "Шутласа акчаны шутлар, җаныңны шутламас", -дип әйткән ди.

**Образлы сөйләм**

Алтмышынчы елларда Мулла Иле мәктәбендә директор булып эшләгән Гарифҗан абый Шәрифҗанов гадәттән тыш образлы тел белән сөйләргә ярата иде. Шулардай берсе: "Иптәшләр! Укучыларның дәфтәрләрен төн буена керфек какмыйча тикшерегез, бер генә хата да төзәтелмичә калмасын, дәфтәр сугышып канга баткан әтәч төсле булсын!"

**Широка страна моя родная!**

1950нче елның беренче августы. Мәктәптә педсовет бара. Татар теле укытучысы Мәрфуга апа бер сәгатьтән бирле утыз укытучы каршында башын иеп басып тора. Бер сәгатьтән бирле мәктәп директоры аны, укыту нәтиҗәләре түбән булган өчен, каты тәнкыйть утына тота. Җир ярылса, җир тишегенә кереп китәргә торган Мәрфуга апаның, ниһаять, түземлеге бетә, тиз генә барып, ишеккә тибеп җибәрә, ишек шар ачылып китә, шунда ул, директога карап, соңгы сүзен әйтә:

- Әллә Сез СССРда Мулла Илендә генә мәктәп бар дип уйлыйсызмы? Әллә СССРда бер татар теле генәме? Аннары, авыз тутырып: "Широка страна моя родная", - ди дә ишекне каты итеп шапылдатып ябып чыгып китә һәм шул китүдән мәктәпкә әйләнеп кайтмый.

Урта Азиягә китеп, төрекмән теле укыта һәм атказанган укытучы исемен ала.

**Такташ хәтле булыйм әле**

1982нче елның март ахырында Мулла Иле клубында язучылар белән очрашу кичәсе бара. Сәхнә түрендә - Мәхмүт Хәсәнов, Фаил Шәфигуллин, Флюра Гыйззәтуллина һәм Рәшит Гәрәй.

Фаил Шәфигуллин үзе эшли торган "Чаян" журналы һәм егерменче елларда аның секретаре булып торган Һади Такташ турында искиткеч кызыклы итеп сөйләде дә бөек шагыйрьнең Мулла Иле турында язылган һәм "Чаян"ның 1931нче елгы гыйнвар санында дөнья күргән шигырен укып күрсәтте:

Мулла Иле авылы булсын да,
Коммунистлар динле булмасын...
Мулла Иленең һәрбер коммунисты
Алмашырлык авыл мулласын!

Ф. Шәфигуллин бик күп сорауларга җавап бирде.

- Сез үзегез Мулла Иле турында "Чаян"га язачаксызмы? - дигәненә:

- Такташ хәтле булыйм әле, аннары, әлбәттә, язармын.

**Фотога төшү**

Шул очрашудан бер мизгел фотода калган: автобус фонында дүртәү басып торалар, дүртесе дә ихлас елмайган - 1. Мәһабәт төз гәүдәле, зыялылык бөркелеп торган Фаил Шәфигуллин (җемелдәвек кырпы якалы аксыл курткадан һәм шундый ук төсле картузлы кышкы кепкадан, дипломатын җиргә куйган), 2. Фаилне култыклап басканы - курчак шикелле җыйнак Флюра Гыйззәтуллина (шагыйранә зәңгәрсу кышкы пальтодан һәм шундый ук төстәге тузгак бүректән, күзлек кигән, кулына сумка тоткан), 3. Ике кулы белән Бальзакныкы кебек легендар таягына таянып торучы аюдай гәүдәле, күзлекле Мәхмүт Хәсәнов (галәмәт зур кара мутон бүректән һәм үзенә шундый килешеп торган көзге соры пальтодан) 4. Тыйнаклык һәм гадилек үрнәге, урта буйлы Рәшит Гәрәй (кара якалы традицион кышкы пальтодан һәм бик тә популяр булган куян бүректән).

Бүгенгедәй истә: мөхтәрәм кунакларны озаткан вакытта авылның һәвәскәр фотографы Рәхим Гыйззәтуллин карточкага төшерергә килеп җитте.

- Автобус фонына тезелегез, - дип, аларны бик тырышып урнаштырып чыкты. Аннары, читкә китеп, озак кына крап торды да "пациент»ларын төзәтергә тотынды.

- Сез, - диде Фаилгә, - дипломатны җиргә куегыз. Менә шулай. Сез, ханым, аның култыгыннан алыгыз. Менә шулай. Сез, абзый, таягыгызны артка яшерегез, күренмәсен...

Фаил шунда бу төзәтүләрне туктатты:

- Мәхмүт абый таяктан башка Мәхмүт Хәсәнов булмый. Аерылгысыз юлдашын үпкәләтмәгез, зинһар.

Бу төзәтүләрдән кунакларның авызлары ирексездән ерык иде. Фотографка: "Елмаегыз", - дип әйтеп торырга туры килмәде.

**Ала каргада алачагың булсын**

Шиһап абзыйга да моннан 7-8 еллар элек җир паен бирделәр. Мулла Иленең бөтен кырларын үзебезнеке дип уйлап, бер кайгысыз яшәгән картның тынычлыгы бетте. Көтмәгәндә, аның үз җире булып куйды (әле кайчан гына ул коммунист иде, хосусыятнең дошманы иде). Хәзер аның кулында "Җир кишәрлегенә милекчелек хокукы турында таныклык" бар. Герблы һәм мөһерле документ. Анда язылган: ул - гомуми мәйданы 3,8 гектар тәшкил иткән җир кишәрлеге милекчесе.

Чыннан да,колхоз дигән нәрсә үзеннән-үзе бетте дә куйды - сизми дә калдылар. Сыра шешәләре этикеткаларыннан гына мәгълүм булган '"Кызыл Шәрык" дигән нәрсәгә әйләнде дә куйды ул. Егерме авылны берләштерделәр дә ачык акционерлык җәмгыяте дип атадылар (аның ачыгы белән ябыгы арасында нинди аерма бардыр). Аның башлыгын генераль директор диләр. Бу җәмгыятьне әле компания дип тә, ширкәт дип тә җибәрәләр. Шуннан да югарырагы департамент дип атала. Мулла Илендәге хуҗалык башлыгын хәзер управляющий диләр (татарчасын әлегә әйткәннәре юк). Шулай, колхоз бетте дә китте.

Шиһап карт хәзер мәчеткә йөри. Мәчеткә ремонт өчен такта сорап, ул "Кызыл Шәрыккә" мөрәҗәгать иткән иде дә, тегеләр:

- Без спонсорлар түгел, без инвесторлар - , дип кенә җибәрделәр. - Безнең бурыч - тиз һәм күп табыш алу.

Теләсә ничек аңла - бигрәк күбәйде шул ят сүзләр ( теге чакта партия укуларында алар шул ят сүзләр белән капиталистларны каһәрлиләр иде. Элек Шиһап карт кирәген, колхоз рәисенә кереп, аяк терәп сорый иде: колхоз үзебезнеке, колхоз кайгыртырга тиеш.

Көннәрдән беркөнне җир пайларын "Кызыл Шәрык"ка тапшырырга дигән фәрман килде. Хәтта срок та куйдылар - 31нче мартка биреп бетерергә. Аннары кабул ителми икән. Аннары җир кәгазең бәдрәфкә генә ярыйсы, ди.

Шиһап карт билгесезлек кочагында калды. Кайбер укымышлы кешеләр:

- Кулыңдагы җирне бирмә! - диделәр. - Нык тор! Җирсез калып, кабалага эләгәсең, батракка әйләнәсең.

Авылның бүгенге байлары, килеп:

- Син җиреңне безгә арендага бир. Һәр гектарына елына 500 сум исәбеннән, продукция белән түләп барырбыз, - диделәр.

Шәһәрдәге улыңны кайтар. Җир паеңны шәхси милек итеп ал, - дип киңәш иттеләр кайберәүләр.

- Син карт инде. Җир паеңны тот та сат - 15 мең акчага рәхәтләнеп яшәп кал, - диде кемнәрдер.

Ләкин Шиһап абзыйны ил тарихы җиңде. Колхозга кергәндә дә бит шулай билгесезлек һәм шөбһәләнү булган. Әтиләр бит колхозга кергәннәр. Ат биреп кергәннәр. Ә кермәгәннәргә көн күрсәтмәгәннәр.

30нчы мартта Шиһап абзый җир паен биреп калырга өлгерде. Конторада ул сорады:

- Кызым, мин бу пайны, кирәк булса, кире кайтарып ала аламмы?

- Юк, абзый, җир, устав капиталына күчкәч, моңарчыга кадәр хуҗа булган зат милкенә хокукын югалта. Ягъни акция нигезендә дивидент түләнә.

- Ул дивидент ни дигән сүз соң, кызым?

- Табыштан өлеш дигән сүз, абзый.

- Ә табыш булмаса?

- Шуның өчен тырышып эшләргә кирәк инде, абзый.

Әлеге кыз, җир паена хокук таныклыгын алып папкасына тыккач һәм берничә урынга кул куйдыргач, Шиһап абзыйга җир паен алганлык турында таныклык бирде.

- Мин, кызым, инде акционер булдыммы?

- Юк, абзый, бу таныклык Сезгә акция алырга хокук кына бирә.

- Ярар, кызым, хәерле булсын, - дигән Шиһап абзый, - Ала каргада алачагың булсын. Бабайлар дөрес әйткәннәрдер.

**Ишми чалуы**

***(Авылым тарихыннан бер кыйсса)***

Зөя белән Әрә елгалары арасындагы бихисап болыннар, әрәмәләр борын-борыннан Мулла Иленеке булып, күрше авыллар моңа гел кызыгып, көнләшеп һәм күпсенеп караганнар. Көнләшеп кенә калмаганнар, төрле юллар табып, бигрәк тә урындагы башлыклар белән бер булып, күп кенә чалуларны (печән участокларын) берәм-берәм үзләренә тартып та алганнар. Авыл аксакаллары, бу хәлгә ничек тә чик куярга теләп, җыелыш җыйганнар. Озак киңәшкәч, патшаның үзенә шикаять җибәрергә булганнар. Шикаять- прошениене Петербургка илтү эшен авылның бүрек тегү остасы Ишмөхәмматкә йөкләгәннәр.

Тәвәккәл кеше булган Ишмөхәммәт. Ул вакытта әле поездлар юк, ат белән бармалы заманнар. Ике йөз ел элек Александр патша вакытында булган хәл бу. Барып җиткән Ишми Петербурга, патша сарае янына килгән. Ничек керергә? Аның шикелләләр байтак икән монда. Менә берзаман Ишми янына бер алкоголик килеп акча сорый икән, бирсәң ярдәм итәм ди икән бу. Биргән Ишми бер яртылыкны. Теге әйтә икән:”Менә минем бер дустым бар – монда дворник булып эшли, сине шуның белән таныштырам, ул сиңа ярдәм итәр”.

Икенче көнне теге дворник әйтә икән Ишмигә:”Менә фәлән көнне патша ишек алдына прогулкага чыгачак. Син мин күрсәткән урынга барып утыр. Прошениеңне бүрек өстеңә куй да патшаның килгәнен көт”.

Шулай эшләгән Ишми. Аның шикелле утыручылар бик күп икән. Ләкин патша чыкмаган да чыкмаган. Көннәр үткән, атналар, айлар үткән. Ишми көткән дә көткән. Петербурда бүрек тегеп тамак туйдырган.

Берзаман үзенең күпсанлы хезмәтчеләре белән, чынлап та, патша чыккан, бүрек өсләрендәге язуларны берәм-берәм җыеп алып кереп киткән. Ләкин җавапны бик озак көтәргә туры килгән

Ишмигә - бер ел үткән. Менә беркөнне аңа патшаның әмере язылган язу чыгарып тоттырганнар. “Барлык алынган җирләрне Мулла иле кешеләренә кайтарып бирергә!” – дип язылган икән.

Кайткач, Ишмөхәмммәткә бу батырлыгы өчен болында бик зур чалу бүлеп биргәннәр. Бер ел чапкан, ике ел чапкан Ишми. Егермешәр кибән коя икән. Яхшы гына баеп киткән бу. Авыл агайлары бик көнләшкәннәр, кеше белән тигез булсын дигәннәр һәм тигезләгәннәр. Ишмигә кечкенә генә бер чалу калган. Шуннан соң әйтте ди Ишмөхәммәт:”Эшләмә икән миргә, эшлә икән иргә”, - дип. Күпме еллар үтсә дә, Ишминең бу сүзләрен авыл халкы гел мәкаль итеп әйтеп йөри, ә теге чалуның исемен һаман да Ишми чалуы дип йөртә.

**Икетеллелекнең зыяны**

1972нче елның февралендә, Мулла Иле мәктәбендә кичке мәктәптәге укытуның торышын тикшерү өчен, мәгариф бүлегеннән инспектор Фёдор Иванович Михеев килде. Бу - мәҗбүри урта белем бирүне тормышка ашыру чоры иде. 9, 10, 11нче классларның һәрберсендә 15-20шәр егет һәм кыз мәҗбүри укытыла. Дәресләр кичке җидедә башланып, алтынчы дәрес төн уртасында гына бетә иде.

Фёдор Иванович инде биш сәгать буе рәттән тарих укытучысының дәресләрендә утыра иде. Дәрес ахырына җиткәндә, укытучы укучыларга көтелмәгән бәхетле сүз әйтте:

- Укучылар, сез дә бик арыдыгыз, мин дә бик арыдым. Бүгенгә җитеп торыр. Алтынчы дәрес булмый, кайтып ял итәрсез. Сезнең дә, минем дә иртүк эшкә барасы бар.

Педсоветта Фёдор Иванович көтмәгәндә бу фактны фаш итте, аннары бөтен район күләмендә бичара укытучыны тәнкыйть утына тотты.

Укытучы моны гомергә оныта алмады, үкенеп, бик еш кына болай ди торган булды:

- Кем уйлаган Фёдор Ивановичны татарча беләдер дип. Икетеллелекнең миңа зыяны тиде.

**Химик шагыйрь**

1959нчы ел, март. Шагыйрь Әнвәр Давыдов безне, каләм тибрәтүче студентларны, Химиклар сараена халыкка шигырь укырга алып барды. Мин дә үземнең ике шигыремне укыдым. Сәхнә артына чыккач, шагыйрь, буыла-буыла шаркылдап көлеп:

- Ниһаять, татар поэзиясенә химик шагыйрь килде, - диде.

Минем шигырь болай тәмамлана иде:

Берсе анод, берсе катод булып,
Ут иреннәр бергә кушылыр.

**Математик Хатип**

Фермада терлекчеләр гәҗит карап утыралар. Депутатлыкка кандидатларның салым кереме турында язганнар. Быел пенсиягә китәсе Хатип үз фикерен әйтеп куя.

- Безнекенең миллион сум гына икән. Миңа бу керемгә ирешү өчен беләсеңме ничә ел эшләргә кирәк? Бер генә якшәмбене дә әрәм итмичә, тагын 60ел эшләргә кирәк.

**Сабан көпчәге**

Беренче комплекслы бригада бригадиры Шиһапның бер генә җыелышта да сөйләми калганы юк. Менә бүген дә ул трибуна артыннан тәнкыйть белән чыкты:

- Иптәшләр, көн тәртибендәге мәсьәлә бик урынлы ки, әйтер идем, бик вакытлы да. Дествительни, бездә җирдән файдалануга караш салкын. Салкын, иптәшләр. Фактлар дисезме? Кырда йөрмәгән кеше генә белми. Мин, номер бер комплекслы бригада бригадиры буларак, көн-төн кырда йөрим. Йөрәк әрни бит, иптәшләр. Утыз имән басуында бер сабан көпчәге ята. Елдан артык ята, иптәшләр. Ни өчен бу турыда уйлап караучы юк? Йөз процент ваемсызлык бу. Сабан көпчәген кем калдырган – берәү дә белми. Күпме зарар килә моннан колхозга. Кайда бездә экономистлар?! Кайда халык контроле6?! Уйлап кына карагыз, күпме зарар! Беренчедән, тулы бер сабан эштән чыккан дигән сүз, икенчедән, көчәк яткан урын буш, кысыр калган, өченчедән, анда чүп үләне үскән, басуны эштән чыгарабыз, дүртенчедән, күпме металл исраф булып ята, ә мартеннарга металл кирәк, металл, иптәшләр, бишенчедән, көпчәккә эләгеп, комбайн ватыла. Иптәшләр, тәкъдим кертәм: сабан көпчәген басудан алып кайту чарасын күрергә.

Шиһапның тәкъдимен бертавыштан якладылар һәм карарга керттеләр. Иртәгесен колхоз председателе, баш һәм баш булмаган агрономнарны җыеп, киңәшмә уткәрде. Сабан көпчәге мәсьәләсен детальләп анализладылар һәм аны кырдан алып кайту буенча чаралар билгеләделәр.

Өченче көнне баш агроном баш инженерга сабан көпчәген алып кайту буенча күрсәтмә бирде.

Дүртенче көнне баш инженер трактор бригадасы бригадирына боерды, ләкин тегесе бик эшлекле җитди фикер әйтте: «Бер көпчәк өчен трактор куып йөрү ярамый. Минемчә, эшне тизләтү өчен бу эш автомашиналар бригадирына тапшырылсын».

Автомашиналар бригадиры бишенче көнне әйтә куйды: «Анда керергә ат юлы гына бар бит. Иген таптап кая керәсең. Ат белән алып кайтырга кирәк». Шулай диде дә, тарантаска утырган яшелчә бригадасы бригадирын күреп, кычкырды:

- Анда Утыз имәнлектә сабан көпчәге ята. Салып кайт, яме.

Яшелчә бригадиры барды, ләкин көпчәк яшелчә җирендә түгел, биш метр читтә кырчылык бригадасы җирендә иде.

Ул җан-фәрманга идарәгә чапты һәм Шиһапка катгый итеп:

- Сабан көпчәгеңне алып кайт, - диде. Шиһап күркә кебек кабарынды.

Беренче комплекслы бригада бригадиры Шиһапның бер генә җыелышта да сөйләми калганы юк. Менә бүген дә ул трибуна артыннан тәнкыйть белән чыкты:

Иптәшләр, бездә үзләрен нәчәлник итеп санап йөрүче иптәшләр бар. Фактлар дисезме? Яшелчә бригадирының комплекслы бригада бригадирына наряд бирергә ни хакы бар?! Ул нинди вөҗдан белән миңа басудагы сабан көпчәген алып кайтырга куша?!

**Ак каеннар**

Томанлы иртәләрнең сихри караңгылыгында ак фәрештәләр булып күренүче каеннар арасында гөмбә җыеп йөрүчеләр!

Шәһәрләдән "Жигули"гә төялеп кайтып, агачларның рәхәт ышыгында саф һава чөмереп, мең дә бер төрле үләннәр арасында тәгәрәп аунаучылар!

Сез Фәйзрахман абыйны беләсезме? Ә менә биредәге һәр ак каен Фәйзрахман абыйны белә.

Сугыштан соңгы авыр елларда, ак каеннар турындагы уйлардан башка да мең төрле мәшәкатьләре булган җәрәхәтле елларда, безнең әниләр басу киңлегендә агач үсентеләре утырттылар. Аларны илһамландыручы, алар белән җитәкчелек итүче кеше авылыбызның бик тә тыйнак, юаш кына бер кешесе Фәйзрахман абый иде. Урман җене кагылган бу кешенең эшкә җәлеп итү куәте шундый көчле иде ки, көннәр буе ындыр табагында тәпәч белән бодай көлтәләре сугып беләкләре талган әниләр, кичләрен менә бирегә килеп, ай яктысында офыктан офыкка кадәр сузылган каен полосаларын утырттылар. Ә аннан соң һәр агачны бала тәрбияләгән кебек карап үстерделәр.

Шулай бер чакны, инде каеннар кеше буе кадәр булып килгәндә, бер саламторхан тракторчы исерек баштан җир сөргәндә йоклап киткән. Йөгәнсез калган трактор, урман полосасына килеп кереп, дөнья хәтле җирдә каеннарны сукалап барган. Таң алдыннан Фәйзрахман абый, бу хәлне күреп, башта сабый бала кебек ачыргаланып җиргә ятып елаган, аннары аңарда шундый ачу-нәфрәт ташкыны купкан: ул әлеге саламторханны ике тәүлек тоташ йоклатмыйча, барлык каеннарны утырттырып бетергән, һәрберсенең төбенә берәр мичкә су сиптерткән.

Ул чаклардан бирле бик күп еллар узды инде. Ак каеннарның яшел толымнарына Гулливерның да буе җитәрлек түгел. Тып-тын һавада да үзләреннән үзләре моңлы тавыш чыгарып шаулап утыралар алар.

Ләкин, арыш урагы өсте җитте исә, елның елында минем йөрәгемне бер нәрсә авырттырып телгәли: каеннарны мунча себеркесенә кисәләр.

Менә былтыр да август иртәсендә алдымда шундый аяныч күренеш: бил турыларыннан чәрдәкләп кисеп аударылган күпме ак каен җирдә аунап ята. Рәхимсез бәндәләр аларның яшел толымнарын ботарлап кисеп алганнар да, машинага төяп, мунча себеркесенә алып киткәннәр. Гомерендә бер агач та утыртмаган бу корткычлар Фәйзхрахман абыйның якты истәлеген мыскыл итәләр.

Минем үземә-үзем ачуым килә. Нигә без аларны күрмибез? Күрергә бик мөмкин бит. Ничаклы битарфлык бездә! Нигә соң без дә Фәйзрахман абый кебек булмыйбыз әле?! Матурлыкны яратабыз бит - әллә яратырга гына яратабызмы?

Былтыр көзен мин улларым белән урманның әнә шул шәрә калдырылган урыннарына яшь үсентеләр утырттым. Икенче башта да безнең кебек үсентеләр утыртып йөргән яшь-яшь бер егетне күргәч, миңа бик рәхәт булып, бөтен күңелләрем яктырып китте.

Каеннарның киләчәге якты. Каен утыртучылар каен кыркучыларның арт сабакларын укытырлар. Фәйзрахман абый кебек.

**Алма**

Кеше дөньядан китә. Ул исәннәрнең хәтерендә яшәвен дәвам итә.

Кырык бернең сентябре иде. Сугышка, сугыш китергән иксез-чиксез кайгыга үч иткәндәй, кояш безнең класска кергән дә бөтен бүлмәне якты нур белән тутырган.

Хәзер рәсем дәресе. Укытучы абый класска гадәттәгечә зур портфелен тотып керде. Йөзе болай кырыс күренсә дә, аңардан яшерен шәфкать, мөлаемлылык, мәрхәмәт бөркеп тора иде. Абыебыз сүзне табышмактан башлады:

- Алсу битле кыз үсте, туп итеп куактан сикереп төште.

Җавап эзләп шактый баш ваттык. Ниһаять, таптык. Кара соң ничек белми торганбыз, алма булмый ни булсын. Әлбәттә, алма. Табышмагы гаҗәп матур, алманың үзе кебек матур: ”Алсу битле кыз үсте, туп итеп куактан сикереп төште”. Бу - өлгереп җиткән алма була инде.

Аннары укытучыбыз мәзәк кенә сорап куйды:

- Сез алманы беләсезме?
- Беләбез! – дидек без хор белән, уйлап-нитеп тормый гына.

Укытучы зур портфеленнән дәү бер алма чыгарды.

- Менә минем кулымда алма. Яңа гына өзелгән иде ул.

Абый аны гомердә күрмәгән, дөньяда юк нәрсә шикелле өч бармагы белән бик сакланып кына тоткан иде.

- Салкынча. Салмак. Күрәсезме, тонык кына күгелҗем кунык белән капланган.

Ул, кесәсеннән дүрткә бөкләнгән яшел читле ап-ак кулъяулык чыгарып, алманы ипләп кенә сөртеп алды.

- Менә хәзер ялтырый башлады.

Аннары алманы иркәләгән кебек кадерләп кенә учына кысты. Тып-тын калган класста алманың кар кебек шыгырдаганы ишетелде.

- Сизәсезме, балалар, хуш ис, көзге сафлык тулы хуш ис бөрки.

Әллә ничек кенә булып китте миңа. Купшы алмагачлар янында йөргәнем булса да, алманың мондый хуш исен беренче мәртәбә тойган шикелле булдым. Бер алманың исе бөтен классны тутырды. “Көзге сафлык тулы хуш ис”.

- Тешләгәндә тыгыз тәне кырт кына шырт итә, тәмле су чатнап чыга, - диде абый, ак тешләрен җемелдәтеп.

Без ирексездән елмайдык.

Алманың бер ягы аз гына батынкы иде. Абыйның да, алсу йөзе елмайганда,
шул алмадай түгәрәкләнеп, батынкыланып китә, бик сөйкемле күләгәле чокырчык барлыкка килә иде.

Алмада бөрчек-бөрчек таплар – тимгелләр бар. Абыйның да алсу йөзендә шулар шикелле матур гына кара тутлар бар иде.

Абый алманы ясатырга ашыкмады:

- Һәр кешенең, һәр алманың үз тормышы бар. Берише алма җәй буе авырып үткәрә, аны корт ашый, кош тешли, малайлар таш атып яньчи, шуңа күрә ул, көз көнендә үзенең гариплегеннән оялгандай, яфраклар эчендә яшеренеп тора. Шуның күршесе исә алсуланып тулып пешкән. Матурлыгы белән горурланып, ап-ачыкта тора. Икенче бер тулып пешкәне тыйнак, яфраклар арасыннан тын гына, оялып кына карап тора. Бар шундые да: үзе яшел, үзе әче, ә үзен кагып та төшереп булмый, селкегәндә ботагын да үзе белән аерып төшә.

Киләсе дәрескә без төрле-төрле алмалар ясалган альбомнарыбызны алып килдек. Һәркемнең үз алмасы бар иде. Минем алма «утлырак» булып чыккан иде: күбрәк куе кызыл төскә буяган икәнмен.

Мин мәктәптән кайткан төшкә әтиемнән үле хәбәр килде. Мин кайгыдан нәрсә эшләргә белми ачыргаланып еладым. Кайгы сөреме эчендә, нәрсәдән юаныч табарга белмичә, шул алманы ясадым. Күз яшьләрем, альбомга тамып, буяуны куерттылар. Куе кызыл төс борчылу төсе икән. Аннары ялкынлы, ярсулы кешеләр куе кызыл төсне яраталар икән. Мин боларны соңрак аңладым.

Сентябрь ахырында абый, үзе теләп, сугышка китте. Мәктәптә ул ясаган рәсемнәр күргәзмәсе әле хәзер дә саклана. Алар барысы өч кенә рәсем. Чөнки абыйның гомере бик иртә - шау чәчәкле чагында сугыш кырында өзелеп калган.

Кеше дөньядан китә. Аннары ул яшәвен исәннәр күңелендә дәвам итә. Укытучы абыем минем хәтеремдә матурлык сурәте, нәфислек чагылышы булып яши, күңелемә хуш ис тулы мәңгелек көзге сафлык бөркеп тора.

**Бер сум**

Шәрифҗанның күршесеннән бер сум акча аласы бар. Уң кулына чытырдап торган берлек тоттырганына нәкъ бер ел булды. Менә бирер, менә бирер дип өметләнеп яшәгән иде ул баштарак. Хәзер инде көн кебек ачык: күршесе ул бер сумны бөтенләйгә онытткан. Ничек итеп исенә төшерәсе? Үзеңнең яраткан күршеңнән ул бер сумны ничек итеп вакланмыйча сорап торасың ди.

Шушы бер сум Шәрифҗан абзыйның йөрәген корт кебек кимерә, көннәр уткән саен баш миен ныграк бораулый барды.Сөеклесенә үзенең көчле мәхәббәтен белдерә алмый тилмереп, йөзенә сары суккан гашыйк хәлендә иде ул. Онытырга да тырышып карады. Кичләрен урынына яткач:”Юк, күршемнән бер тиен дә алачагым юк”,” – дип тәкърарлады ул. Ләкин төшендә шул бер сум белән җенләнде. Кайчак, авызын колагына кадәр җәеп, күршесе аңа берлек сузды. Бәхеттән очарга торганда гына уянып китте ул...

Файдасы тимәсме дип, җырлап та йөри башлады ул. Соң дәрәҗәдә кайгылы, сагышлы иде аның җыры:

Күзләремне тытырып карап калам
Син ерактан үтеп киткәндә.
Оныта алмыйм, күршем бурычың
Күзем төшми синнән бүтәнгә.

Әнә күршесе балтасын кыстырган да, гамьсез елмаеп, эшкә бара. Шәрифҗанның барлыгын белми дә.

Ләйләбану түтинең күңеленә корт төште.

- Әллә нишләдең, карт. Әллә яшерен гыйшык тотасың инде.

Газаплары, сагышлары Шәшрифҗан абзыйны китапханәгә алып килде.

- Кызым, миңа исеменә “бурыч” сүзе кергән берәр китап табып бирсәнә, - диде ул китапханәче Маһибәдәргә. Тегесе, үзенең кордашына нәрсә булды инде, дип аптырап, китап киштәләре буйлап китте. Берәр сәгатьтән Шәрифҗан абзыйның куенын Ремаркның “Жизнь взаймы» дигән романы иркәли иде(татарча китап тапмадылар).

Күңелдә өмет кошы тырпылдады. Тик менә бу китапны ничек күрсәтергә? Өйләренә керергәме? Ни өчен дип? Бәхеткә каршы, юлда күрше үзе очрады. Каршыга урамны тутырып елмаеп килә.. Бәхет борын төбендә.

- Пенсиянең кадерен беләсең, күрше, китап гомер озайта, ди. Яле, яле, ниндиерәге? Ә! Әле кайчан гына минем онык укып утырганы икән.

Пыр итеп очты-китте бәхет кошы.

Ләйләбану аңа күз агы белән карады:

- Әһә, тол Маһибәдәргә ияләштеңме, карт җен?!

Тешләрен кысып түзде Шәрифҗан.

Ә беркөнне, Шәрифҗан абзыйның күңел күзен балкытып, авылга “Түләнмәгән бурыч” дигән кинофилм килде. Картының баруы турында ишеткәч, Ләйләбану түти өнсез калды.

- Мәсхәрәләгән хәтле мәсхәрәлә карт көнемдә. Бар, әйдә, кит Маһидәбәдәреңә, - дип үксергә кереште.

- Яла якма, карчык, шаһитым бар. Күрше белән икәү барабыз.

Күршесе, никадәр гаҗәп тоелса да, аның бу тәкдименә шатланып риза булды.

Кинонык буеннан буена сөенеп-канатланып утырды ул.

Кайтышлый, күршесе кинодагы кызыйны тиргәп кайтты: “Ну, үзен дәүләт унбиш ел буе укыткан, понимаеш, ә ул, бурычын түләмичә, эштән кача, әрәмтамак!

Берлектән чиксез ерак иде күршесенең уйлары.

...Беркөнне Шәрифҗанның кәкре аяклы оныгы ишек алдыннан күгәреп беткән тимер берлек табып керде.

- Әнә бабаңа бир, - диде Ләйләбану, каударланып. - Кинога барырга булыр. Шул күрше былтыр кертеп биргән иде, мин сыер савып утырганда. Онытылып төшеп калган...

Шәрифҗан абзыйның авызы тыелгысыз шатлык белән җәелгәннән-җәелде. Күзгә күренеп яшәрде ул. Әлеге берлек аның үч төбен рәхәт кытыклады. Карчыгын кочаклап алды.

Ә онык, бармагын борын тишегенә тыккан килеш, әбисе белән бабасына карап катып калган иде.

**Хәмит**

1

Кояш офыкка якынлашып, койма күләгәләре ишек алдын каплап алсалар да. Хәмит кич җиткәнен сизмәде. Бу унике яшьлек малайның бөтен игътибары агач юнуда иде. Аның таралмаган кыска чәчләренә вак йомычкалар сырышкан. Иреннәре, кул йөрешенә ияреп, туктаусыз хәрәкәтләнә. Менә өй алдыннан әнисенең ачулы тавышы ишетелде:

- Тагын юк-бар белән маташасыңмы? Утын ярып бир, дип ничә әйттем, колагыңа да элмисең. Әнә күрше малае Исмайны кара. Үзе белеп эшли. Мәктәпкә барсаң да, һаман аны мактыйлар. Куяннарны яхшы караганы өчен нинди матур букча бирделәр үзенә. Ә син алып биргәнне генә туздыра беләсең.

- Әй, шул Исмай Исмай булмады инде, - дип куйды Хәмит. Гарьлегенә түзә алмыйча, тиз генә торды да ярсып утын ватарга тотынды. Ул арада әнисе, көянтә-чиләген алып, суга юнәлде. “Исмай имеш. Кем соң ул? Мин аны бар дип тә белмим ич. Ул бит куркак. Укытучылар ни әйтсә, шуны гына эшләп йөрүче. Ә әнисе үрнәк ал, ди. Хурлыгыңнан үләрсең.” Берничә минуттан соң кичә ук ясый башлаган әйбер тәмамланды. Ул әйбер ук белән җәя иде. Карама агачыннан бөгеп ефәк белән тарттырып куелган. Мондый җәяне, чыршы агачыннан шундый төз, шома итеп, башына ап-ак калай урап ясаган мондый укларны әнә Исмай эшләп карасын. Ул куяннарны сыйпап йөрүне генә белә.

Иртән ауга! Хәмит укларның берсен сынау өчен һавага атып җибәрде. Ул туп-туры очып китте дә күздән югалды. Бераздан башы белән кадалып җиргә төште. Сөенечтән Хәмитнең кара күзләре очкынланып балкыды... Ләкин кинәт ул уйчанланып китте. Иртәгә мәктәптә тимер-томыр җыярга куштылар. Нишләргә? Ауны калдырып өмәдә йөрергәме? Юк, Хәмит башкалар кебек тимерне берәмлекләп, тегеннән-моннан чүпләп йөрмәс. Ул, кызып китеп, ишек алдын актарырга тотынды, кызганычка каршы, ике тәгәрмәчтән башка әйбер табылмады. Аптырап калган вакытта, өйгә кичке

ашка чакырдылар. Табын янында үз уйларына батып, беркемгә дә карамыйча, сүзсез генә ашап утырганда, кинәт Хәмитнең авызыннан уйлаганы ычкынып китте:

- Әһә, табылды! – дигәнен ул үзе дә сизми калды.

- Безнең Хәмитнең уйлары әллә кайда йөри бүген, - дип куйды әтисе, мыек астыннан гына елмаеп.

Хәмит урыныннан башкалардан алда торды да, бакча артларыннан чыгып, кырга юнәлде. Инде караңгы ярыйсы гына төшеп өлгергән. Әңгер-меңгер аша әйберләрнең төсен аерып булмый. Ялангач аяклар башта чирәмнән, аннан камыллы җирдән атладылар. Менә Хәмит килеп тә җитте. Аның алдында төзәтү өчен сүтеп ташланган трактор. Күпме тимер монда! Хәмит кеше-кара юк микән, дип, як-ягына каранып алды да тимерләрне сайлый башлады. Үзенә ошаган ике сырлы тәгәрмәч, бер чылбыр башмагын күтәреп китте, көч-хәл белән аларны бакча артларына илтеп куйды. Яңадан ике тапкыр күтәреп килгәч, өстеннән тау-таш төшкән кебек, билләренә таянып, яңа гына чыккан йолдызларга карап торды. Аннан соң тимерләрне бәрәңге арасына ташырга кереште. Барысы да үз дигәнечә булып, күңел урынына утыргач, абзар башына йокларга ашыкты. Куначадагы тавыклар бүген, Хәмит соңга калып менгәнгә күрә, ятсынышып, тамак төпләре белән кычкырырга тотынганнар иде, "Кучмәгез, ахмаклар!" дигән таныш тавышны ишеткәч, шым булдылар. Хәмит хуш исле печән өстендә шактый гына йокыга китә алмый ятты. Аның күңелен иртәгә булачак ау маҗаралары кытыклады. Төшкә дә шул ау хикмәтләре керде. Әле ничек кенә! Хәмитнең кулында ике көпшәле мылтык. Ул кара урман эчендә озын гына бер агач башына менеп утырган да, шуннан торып җирдәге аюларга ата.

Әтәч уяу калды. Ул төн уртасы җиткәнен көтеп алды да, көр тавышы белән тынлыкны бозып, берничә тапкыр кычкырды. Аңарга Исмайлар әтәче дә, Барыйларныкы да, бөтен кешеләрнеке дә кушылды.

Йокыдан торганда, өйдә Хәмитнең әнисе генә калган иде, әтисе белән апасы эшкә китеп өлгергәннәр. Хәмит ашап тормады, кесәсенә ипи белән шикәр салды да, җәя белән укларын алып, өйдән чыгып тайды. Ашыга-ашыга барганда, әллә каян Исмай калкып чыкты.

- Хәмит! Кая барасың? – дип сорады ул бик эшлекле кыяфәттә.

- Барган җир алда, күрмисеңмени?

Хәмит бик мәгънәле генә итеп кулындагы җәяне селкетеп куйды.

- Бүген барыбыз да тимер җыябыз бит.

- Җыйсагыз соң. Ә мин инде күптән җыеп куйдым... Аннан соң миндә ни эшең бар соң әле синең?

- Ничек булмасын. – Исмай зур соры күзләре белән текәлеп, Хәмиткә якынрак килеп басты. – Син бит безнең класс укучысы.

- Һе... Булса ни! Әллә мин зыян китерәмме сезгә? Ярар, синең белән сөйләшеп торырга артык вакытым юк, әләкләсәң әләклә.

Хәмит, эре генә атлап, түбән очка төшеп китте.

Хәмитнең әтисе Хәбир абзыйга көтмәгәндә бәла килде. Тракторчы егет Барый: “Син үзең каравылчы, үзең детальләрне урлатасың”, - дип бәйләнә башлады. Хәбир абзый бөтен җаны-тәне белән әрнеде. Төшке ашы аш булмады. Фатыйма апа да Хәбир абзыйдан ким кайгырмады. Бәладән очраклы бер хәл генә коткарды. Фатыйма апа бакчага чыккан иде, буразнада нәрсәгәдер абынды. Караса – тимерләр, трактор детальләре. Детальләрнең болай тиз генә табылуына алар икесе дә сөенделәр. Ләкин бу сөенечнең икенче ягы аларның күңелләрен әрнетте. Бу бит Хәмит эше. Трактор детальләрен аларның уллары урлаган. Юк, Хәмит детальләрне генә түгел, әти -әнисенең тынычлыгын да урлаган.

3

Камышлы күл буйларында күпме генә йөрмәсен, ялгышып та бер үрдәк күренмәде. Кәеф кырылып кайтып барганда,тагын Исмай очрады. Менә сиңа кирәк булса, хәзер фәлән хәтле үрдәк атып кайттым дип класс алдында сөйләнеп тә булмый.

- Я, аучы, юкны бушка әйләндереп бетердеңме?

- Көлмә кешедән, авызың өшегән, - диде Хәмит, ачуы тәмам чыгып.

- Бүген күпме тимер җыйдык, син генә юк идең.

- Әллә мине җыймаган дип беләсеңме? Ышанмасаң, өйдә минем арбага төягәнне карап тор. Ике күзең дүрт булмасмы!..

Малайлар бакчага үттеләр. Хәмит, үз күзләренә үзе ышанмыйча, буразналар арасына карап катып калды. Тимерләрдән җилләр искән. Кем алган аның тимерләрен?! Исмайның “Кайда тимерләрең?” дип соравына каршы ул берничек тә җавап бирә алмады.

- Хәмит! Кил әле монда.

Хәмит бөтенләй югалып калды. Ул, нишләргә белмичә, башын аска иеп, кыяр-кыймас әтисе янына атлады.

**Юл турында кыйсса**

**(Уены-чыны бергә)**

Юлтөзәргә сабый чакта ук юл төзү җене кагылган иде. Бу тикмәгә түгел, чөнки ул

Авылны нәкъ урталайга аерып ике чакрымга сузылган Олы урамда яши иде. Үзләренең шул урамнарында көннәр буе “юл төзү” уенын уйный: урам уртасыннан үткән ат юлындагы (әле машиналар юк иде) арба көпчәкләре ясаган тирән уентыкларны әтисе ясап биргән кечкенә тачка белән балчык ташып, күмеп йөри иде.

Буйга җиткәч, Юлтөзәр шофёр булды, колхозга беренче машинаны ул алып кайтты. Олы урамда, ат юлы өстеннән киңәеп, машина юлы хасил булды. Пычрак көннәрдә машина көпчәкләре, батып, бер урында кара төтен чыгарып зырылдаганда, Юлтөзәрнең баш миен тик бер уй - юл төзергә кирәк дигән уй бораулады. Бу уен тормышка ашыру өчен, ул көннәрдән бер көнне Норлат өстендәге таудан бер машина таш алып кайтып бушатты. Ләкин аны көне белән идарәгә чакырттылар. “Юл –

синең шәхси хуҗалыгың түгел, юл – халыкныкы, Юл – дәүләтнеке. Юл төзү ул – безнең эш”, - диделәр. Аннары Юлтөзәр юл төзү мәсьәләсен гомуми җыелышта кузгатты, ләкин аны сукырлыкта гаепләделәр: “Күрмисеңмени, пар белән эшли торган электр станциясе төзеп ятабыз. Ә син кысыр хәсрәт белән йөрисең”. Күрмәгән кая, күрә иде Юлтөзәр: түбән баштагы күл буенда парга көйләнгән электр станиясе төзелешенә Олы урамнан көн саен таш төялгән атлы йөкләр агыла да агыла иде. Ләкин көтмәгәндә, сугыш башланып китте. Юлтөзәрне беренче атнада ук фронтка җибәрделәр. Кырык үлем аша үтеп, җәһәннәм юлларын гизеп, авылга исән-сау кайтты Юлтөзәр.

Теге станция төзелешен тагын дәвам иттеләр. Ләкин көннәрдән беркөнне өстән әмер килеп төште: электр пар белән эффектлы түгел икән, елга суы агымы белән отышлы була икән. Һәм авылдан ерак түгел генә җирдә - Зөя елгасы янында гидроэлектростанция төзи башладылар. Олы урамны изеп, исәсез-хисапсыз чокырлар ясап, таш төялгән йөкләр агылды. Шул вакытларда Юлтөзәр депутат булып сайланган иде. Депутат буларак, ул юл төзү мәсьәләсен сессиядә күтәрде. Ләкин аны кырт кистеләр: ”Син нинди депутат?! Депутат ил турында уйларга тиеш. Бу сиңа вак мәсьәләләр белән уйнап утыру урыны түгел”.

Ләкин, станция төзелеп бетеп килгәндә, югарыдан әмер килде: гидростанциягә караганда җылылык станциясе күпкә яхшырак икән. Һәм авылдан ерак түгел җирдә - Торна сазында торфка нигезләнгән электр станциясе төзи башладылыр. Олы урамнан таш төялгән йөкләр агылды. Инде менә төзелеп бетә дигәндә, югарыдан фәрман: башка төзеп тормаска, туктатырга, чөнки Куйбышев ГЭСы өлгереп җитә икән.

Юлтөзәр, районга барып, түрәләр белән киңәште: шул станцияне сүтеп, ташларын Олы урамга җәйик, иптәшләр, дип караган иде, тегеләр бер авыздан:

- Син нәрсә сөйлисең?! Куйбышев ГЭСы киткәч, авылыгызны су басмасын өчен, без сезне дамба белән урап алабыз. Таш шунда кирәк, - диделәр.

Олы урамнан тагын таш төялгән йөкләр агылды. Кешеләр инде урамның бер ягыннан икенче ягына резин итекләр белән дә чыга алмас булды.

Авыл читендә ике мең баш мөгезле эре терлеккә исәпләнгән, шәһәр зурлыгындагы комплекс-ферма төзелә башлагач, Олы урамның хәле бөйтенләй мөшкелләнде: инде канауларга кереп баткан йөк төягән тракторларны әзмәвер-әзмәвер тягачлар белән өстерәтеп чыгара тордылар.

Юлтөзәр бу хәлне халык контроле комитетында күтәрде. «Башта, - диде ул, - Олы урамга начар гына булса да, бер юл төзеп куйыйк. Күпме файда киләчәк бит үзебезгә, техника ватылмый, ягулык әрәм булмый». Аңа бик культуралы итеп аңлатып күрсәттеләр: «Дәүләткә сөт, ит кирәк. Синең урамың дәүләт масштабындагы нәрсә түгел», - диделәр.

Ләкин Олы урамның күрәселәре алда иде әле. Культуралы көтүлекләр ясыйбыз дип, бөтен җәйләүләрне меңәрләгән бетон баганалар белән йөзләгән аерым-аерым бүлемтекләргә бүлеп бетерделәр, кат-кат итеп тимерчыбыклар тарттырдылар. Бүлеп бетерүгә, өстән фәрман килде:

ялгыш булган икән, җәйләүләрне бушатырга. Барысын да кире сүтеп, Олы урамны елатып, кирегә ташыдылар.

Аннары сугару эпопеясе башланды. Олы урамнан озын-озын торбалар төялгән машиналар агылды. Бөтен җирне ике метрга казып, җир астына торба тутырдылар, җир өстендә зур-зур көпчәкле торбалар пәйда булды. (Үзгәртеп кору җилләренә ышыкланып, ул хикмәтле сугару тимерләрен әллә кемнәр «цветмет»ка ташып бетерде, ләкин Олы урам аларны күрмәде – каян алып киткәннәрен берәү дә белмәде).

Бөтен зур төзелешләр Олы урам аша узды. Барысын сөйләп чыгу мөмкин түгел. Шулай да тагын берсен әйтеп үтмичә булмыйдыр: берзаман югарыдын өр-яңа фәрман килде: кыр станы төзергә. Я, Раббым, һәр механизаторның үз йорты булса да, ул өендә түгел, кырга барып йокларга тиеш икән, ләбаса.Нишлисең, дәүләт эше. Авылдан чакрым ярым ераклыкта шәһәр кадәр кыр станы төзеп куйдылар. Аннары яңа фәрман килде: ул нәмәрсәнең файдасы юк икән, бик тиз сүтәргә, ди. Китергәндә ул «шәһәр»не Олы урам аша алып килгәннәр иде, алып китүчеләрне берәү дә күрмәде.

Еллар үтте дә үтте. Демократия килде. Альтернативалы сайлаулар заманасы китте.

Хәзер инде Юлтөзәр бабай трибунадан рәхәтләнеп сөйли башлады.

- Олы урамга юл кирәк.

Авылда шәхси хуҗалыкларда терлек бик ишәйде. Көтү куып булмый. Терлек урамда корсагыннан бата.Теге як күршегә кереп булмый.

- Аңлыйм , - диде кандидат. – Нәкъ менә мин төзим юлны. Нәкъ менә миңа бирегез тавышыгызны.

Ләкин дүрт ел бик тиз узып китте, Олы урамга бер әрҗә ком да килмәде. Алдагы сайлаулар алдыннан , икенче кандидат катгый төстә әйтте:

- Мин вәгъдә итүче түгел, мин фәкать эш кешесе.

Ләкин аннан бирле тагын дүрт ел узып бара. Авылга менә өр-яңа кандидат килде.Юлтөзәр бабай тагын трибунага чыкты. Рәхәтләнеп сөйләде. Һаман да шул Олы урамын сөйләде. Берәү дә тыймый, демократия бит.

...Зур өметләр белән кышкы юлдан siксән яшьлек Юлтөзәр бабай, озын таягына таянып, өенә атлый. Үзе һаман кабатлый: кышкы юл әйбәт! Ходай салган юл. Яз килгәч, йөреп булмас. Хәер, кандидат үзен сайларга кушты ич. Шуның өчен юл төзим, диде.

2004

**Метаморфозалар яки күңелле үзгәрешләр**

Авылларның киләчәге – инвесторлар кулында, дип бик дөрес әйтәләр икән. Безнең авылга гаять куәтле инвестор килде дә колхозыбызны бер селтәнүдә бетереп ташлады, халыкның тормышын үзгәртте дә куйды (Инвестор ул, икенче төрле әйткәндә, без сүгеп яшәгән алпавыт була инде). Инвестор килүгә, колхоздан калган барлык техниканы, фермадагы барлык терлекне үзәккә алып киттеләр. Авыл әйләнәсен уратып алган барлык корылмалар: суган хуҗалыгы складлары, борынгы һәм яңа тегермәннәр, сугару системасының хикмәтле торбалары, трактор-машина ангарлары –

барысы да, бер дә булмагандай, әкияттәге кебек юкка чыкты. Авылның һәр ягы яңа төс алды, чистарып, яктырып, җыйнакланып китте. Хәтта әле күптән түгел генә салынган ат кәнүшниләре дә, әллә каян мәһабәт булып күренеп торган силос башнялары да парга әйләнгәндәй күздән югалды. Мишәйт итмәсеннәр. Авылда капитализм чәчәк атты. Шәхси хуҗалыкка тулы ирек бирелде, кешеләр йорт-җирләрен хосусыйлаштырды, һәр хуҗалыкның абзарларында – ике-өч сыер, бер дистә сарык, күпләрнең гаражында – трактор, машина. Терлек асрау бик рәхәткә әйләнде. Колхоз чорында бер центнер фураж сатып алуны үтенеп, рәиснең бусагасын атналар буе таптап йөргән булсак, хәзер фуражны, печәнне, саламны инвестор үз техникасы белән өйгә алып килеп бирә. Тукай әйтмешли, барысы да бесплатный – беркем бер тиен акча түләтми. Әкияттәге кебек инде. Янәсе без инвесторга пай җирләребезне биргәнбез һәм шул мифик җирләребез өчен инвестор безне гомер буена фураж-печән белән тәэмин тиеп торачак. Дивидент – авыл халкының иң яраткан сүзенә әйләнде.

Әле кайчан гына авыл урамнары тоташ сазлык, баткаклык булып, көз-яз айларында чылбырлы тракторлар гына сөйрәлеп йөри ала иде. Кешеләр, көтү куганда сыерлары белән бергә билдән батып, чыга алмыйча тыпырчынып яталар иде. Авылдагы бердәнбер үр башына туктаган сөт җыю машинасына кадәр килеп җиткәнче, ава-түнә барган хатын-кызларның көянтәләрендәге чиләкләрдә сөт яртылаш кына кала иде. Мәхшәр дөньясы купкан кебек шаулый иде авыл.

Ә хәзер – рәхәт.Куәтле инвестор барлык урамнарның уртасыннан тип-тигез юллар салды. Юллар авылда гына түгел, ерымнар, сазлыклар, баткаклыклар аша үтеп, иң ерактагы җәйләүләргә дә барып чыга. Хәзер көтү куасы да юк, матур юлдан терлек җәйләүгә үзеннән-үзе бара. Иң мөһиме – сөт тапшыру өчен һич тә әллә кая барасы түгел – сөт тулы чиләкләреңне капка төбенә генә чыгарып куясың да сөт җыючы шуннан, машинасы белән килеп, үзе алып китә. Акчасы өчен дә барып йөрисе юк – синең саклык кенәгәңә күчереп баралар.

Ләкин... Сүзем менә шул ләкин турында. Халык өйгә бикләнде. Бездә барлыгы 851 кеше булып, шулардан эшләүчеләр – 230 кеше эшкә китеп бетәләр, күбесе, автобусларга төялеп, еракка – үзәктәге фермага, сельхозтехникага китеп бара, укучылар – 110 кеше – мәктәпкә, нәниләр – 60 кеше – бакчага. Без, пенсионерлар, өйдә кече фермада хезмәт итәбез. Без дигәнем, 451 кеше – авылның алтын фондын тәшкил итәбез. Пенсионер абзар белән өй арасын таптый, аннары телевизорына кереп чума. Күршегә керү беткән. Кәрәзле телефоннан гына әйтә сүзен. Көн буена урамнар буп-буш. Бер урамда бер кешене күрмисең. 453 йорт тын гына буш урамнарга карап тора. Йортларның алтмышы “пуста” – сатуга куелган, алучы гына юк.

Шулай, аралашмау авылда бер чиргә әйләнгән. Хәзер халык клубка түгел, туган-тумачага да бармый, хәтта элеккеге кебек мәҗлесләр дә үткәрми.

И, бар иде өмә белән, бергә-бергә әнә шул йортларны корган чаклар. Инде ун елдан бирле балта тавышы ишетелми. Нибер йорт, нибер абзар төзелми. И, бар иде җәйләр буе болыннарда бергәләшеп печән чабулар! Хәзер печәнне инвестор үзе ишек алдына китереп куя. И, бар иде

кырлар түрендә бергә-бергә суган, чөгендер, кишер чүпләрен утап йөргән чаклар! Әле көтү куганда да , сөт тапшырганда да халык бергә-бергә гөж килә иде.

Шундый уйларга батып утыра торгач, аралашмау чиреннән котылу юлын таптым мин, җәмәгать. Уйладым-уйладым да авылда пенсионерлар оешмасы төзергә дигән карарга килдем. Ниятемне өстәгедәгеләр дә бик хуплады. Йорт саен йөреп, бу турыда аңлатып чыктым. Барысы да ике куллап риза булды. Оештыру җыелышы үткәрдек. 451 кешедән 21е генә килә алмады. Оешмабызга бик матур исем дә куйдык.: “Яшәгән саен яшисе килә”. Гимныбызны да раcладык һәм барыбыз бергә басып җырладык:

Гомер үткән саен яшәрә күңел,
Ул шулай мәңгегә шиңми торган гөл.
Яшәгән саен яшисе килә,
Яшәреп яшисе сез дуслар белән.

Кыска гына вакыт эчендә пенсионерлар аралашу шатлыгыннан күзгә күренеп яшәреп киттеләр. Оешма демократик булсын өчен, ике палаталы итеп ясадык: аксакаллар палатасы һәм акәбиләр палатасы. Яшьлегендә вальс әйләнергә өйрәнә алмый калган бабайлар һәм әбиләр хәзер биюне менә дигән итеп үзләштерделәр.

Менә 1апрельдә мәдәният йортына көлке кичәсенә җыелдык. 451 әгъзаның 422се килде. Авыр йөрүчеләрне элгәреге колхоз рәисе, хәзерге 75 яшлек Хуҗиев бабай үз машинасы белән ташыды. Гаять зур дулкынлану белән җырлагач, “Көлү – сәламәтлек юлдашы” дигән докладны 79 яшьлек акъәби Гайшә абыстай укыды.(гомер буе медпункт мөдире булып эшләгән иде). Аннары авылыбызның карт шагыйре Шәйхи бабай өр-яңа әсәрен укыды(ул безнең оешмада аксакаллар шурасы рәисе булып тора):

Аксакал

Сакал үстерсәм мин хәзер,
Булыр идем аксакал.
Сакал шөһрәт саклау өчен
Булыр иде ак калкан.
Нәкъ борынгы аксакалдай,
Кулга тотып зур таяк,
Аксакаллар шурасында
Торсам мин сакал тарап,
Мин аксакал булган өчен
Шатланыр иде халык:
Акыл өләшер идем мин,
Үзем акылсыз калып.
Уйнар иде укучылар

Ап-ак сакалым белән,

Балкып торыр иде авыл

Сакалым нуры белән.

Бик дәрәҗәле булса да,

Үстермим шул ак сакал:

Кешеләргә күренмәс дим

Галстуклы ак якам.

Тик хыялда гына калам

Ап-ак сакалым белән.

Ярый әле сакалсыз да

Шигырь сукалый беләм.

Аннары мәзәк сөйләү ярышы китте. Сырхаулар көлә-көлә сихәт алды. 422 авыз бертуктаусыз елмаеп торды.

Әйтергә онытканмын икән: барлык әгъзалар да кичәгә ашкынып килсен өчен, без белдерүне 10көн алдан язып элеп куйган идек һәм зур-зур хәрефләр белән Алмаз Хәмзин үзек катнаша дип тә өстәгән идек. Әлбәттә, халык моны бер шаярту, 1нче апрель алдавы итеп кенә кабул итте.

Ә без үзебезчә кызыклы “сюрприз” әзерләгән идек: Сөләйманыбыз(иң яшь пенсионер) ай буе Алмаз Хәмзин булып сөйләргә өйрәнде. Менә хәзер ул сәхнәдә коеп куйган Хәмзин. Ул тавыш, ул авызның сәхнә киңлеге ерылып китүләре... халык мондый тамашадан егыла-егыла көлде. Шул вакытта клубның арткы ишегеннән берәү килеп керде дә, халык арасыннан узып, егетләрчә сикереп, сәхнәгә менде. Халык гаҗәпләнүдән тып-тын калды. Бер-берсенә караштылар. Һичкем бернәрсә аңламады. Сәхнәдә, чын могҗиза булып, Алмаз Хәмзин үзе басып тора. Таныш күзләр, таныш елмаю, таныш тавыш:

- Яшибез, җәмәгать, болай булгач, яшибез! Бөтен Татарстан авыллары буйлап кешеле авыл эзләп йөрдем – ниһаять, таптым! Миңа акча кирәкми, Миңа кеше кирәк! Кеше!

Шуннан китте Алмаз Хәмзин мәзәк сөйләп, шуннан китте... Бергә көлү рәхәт. Бергә көлү күңелле. Бергә яшәүләргә ни җитә.

Аннары соңыннан гына атаклы артист серне чиште:

Җәмәгать, сезнең авылдан Казанга жалоба килгән иде. Белдерүдә Алмаз Хәмзинне килә дип язып кую ул мыскыл итүгә керә, дигәннәр. Килегез, тикшерегез, чара күрегез, дигәннәр. Барысы өчен дә рәхмәт. Бу жалоба миңа чакырудан да артык. Рөхсәт итегез көлү комитеты комиссиясе карары нигезендә Хуҗа Насретдин исемендәге быелгы премияне сезгә тапшырырга. Бергә көлик! Бергә яшик!

**Мине игелекле мөселман дип санавыгызны үтенәм**

*Хикәя*

*"Күрәсезме, сизәсезме,*

*без Колшәриф, Батырша,*

*Гайнан Вәисов кебек*

*корбаннарыбыз хакына*

*мәчетләр төзеп, җай гына*

*булса да алга барабыз."*

Айдар Хәлим

1909 елның 15 гыйнварында, тышта буран улаган бер көндә, Толстой Гайнан Вәисовтан хат алды һәм шул көнне үк сиксән бер яшьлек бу карт аңа җавап та язып җибәрде: "Хөрмәтле туганым Гайнетдин Вәисов! Сезнең миңа килергә теләвегез турында хәбәр алып, мин бик шатландым. Сезнең турыда ишеткәннәремә караганда, безнең карашлар бертөрле булыр дип ышанам. Сезнең Аллаһыны һәм җирдәге кешене ничек аңлавыгыз турында фикерләрегезне төгәл беләсем килә. Сезне күрсәм, бик шат булырмын. Кайчан телисез, шунда килегез, мин беркая да китмим".

Гайнан Вәисов Ясная Полянага 1909 елның 11 февралендә — кояшлы, җылы бер көндә килде. Утыз сигез яшьлек бу мөлаем Казан татарын Толстой беренче күрүдә үк яратты. Пөхтә кыркылган кара сакаллы, озын мыеклы бу татарның ак йөзе шундый матур һәм тыныч иде. Алтын кысалы күзлек аша карап торган зур күзләрдә аның эчке тирән фикерләре чагыла.

Вәисов Толстой янында өч көн булды. Өч көн буе бөек язучы әлеге сөйкемле һәм акыллы мөселман кешесе белән дөньясын онытып фикер алышты. Гайнан үзе тыйнак кына, гади генә күренсә дә, оялчан түгел. Утырып сөйләшкәндә, бераз як-якка чайкала. Русча иркен, җиңел сөйләшә.

- Кадерле туганым, — диде Толстой елмаеп, — мин Сезне күрүемә бик шат, мин Сезне көттем. Мин Казанны, татарларны өзелеп яратам. Бабам да Казанда үз вакытында губернатор булып торган. Әтиемнең сеңлесе гомер буе Казанда яшәде. Яшь чагымда Казанда алты ел тордым. Казан университетында укыдым. Гарәп телен укырга да туры килде. Болгарга да бардым. Анда манарага да менеп карадым.

Гайнан Толстойны үзенең тормыш юлы белән таныштырды. Күренеп-күренеп киткән ап-ак тигез тешләре сөйләменә аерым бер ямь бирәләр иде. Мулла Иле авылы турында да, әтисе Баһаветдин шагыйрь турында да сөйләде ул. Ә Толстойга барысы да кызык иде, таралып торган озын сакал-мыегын сыйпаштырып, йотылып тыңлады, аннары кисәк кенә әйтеп куйды: "Минем дә, Сезнең шикелле, Зөя елгасында көймәдә йөзгәнем булды. Көймәдән төшеп, Зөя каласын карап йөрүләрем әле дә истән чыкмый", — дип, бер тын уйланып торды, аннары сүзне кинәт дин мәсьәләләренә борды:

- Дин - кешелек мәдәниятенең иң югарысында һәм иң өстендә булган каймактыр. Мин бөтен гомеремне вә гакылымны Аллаһы юлында фида иттем. Мөселман өчен дә, христиан өчен дә Аллаһы бер. Мөселман белән христиан бер-берсен кыерсытмыйча, бер-берсенә изгелек кылып яшәргә тиешләр. Иманлы кеше үзен сөймәгән, үзен рәнҗеткән кешене яратырга тырышырга тиеш.

Әгәр дә моны булдыра алса, аның шунда ук күңеле күтәрелеп, яктырып китәчәк. Үз-үзеңне төзәтә барып, һәр көн һәм һәр сәгать саен аз гына булса да яхшыра барырга тырышырга кирәк. Дөньядагы иң зур бәхет - кешеләргә изгелек кылу. Бүген эшли алырлык изге гамәлләрне иртәгә калдырма. Кеше үзенең кылырга теләгән изгелеген эшләп бетерәме-юкмы, үлем аны көтеп тормый. Үлем беркемнең дә эшләп бетергәнен көтеп тормый. Кешенең эшләргә өлгергән гамәлләре аның язмышы була. Язмыш яхшы да, начар да була ала. Шуңа күрә дә кеше өчен дөньяда иң мөһиме – аның бүген кылган гамәле.

Толстой шкафының иң өске киштәсеннән яшел тышлы Коръәнне алды һәм, тиз генә кирәкле битен ачып, алда әйткән сүзләренә туры килә торган аятьләрне укырга тотынды, аннары тагын бер үк фикерне кат-кат тәкърарлады:

- Явызлыкка-усаллыкка бары миһербанлык, изгелек белән җавап бирергә кирәк. Берәү кемне дә булса рәнҗетсә, ул шуның белән бөтен явызлыкның тамыры булган нәфрәт хисен кабыза. Явызлыкка каршы явызлык эшләү нәфрәт хисен көчәйтә генә.

Бераздан сүз дин галимнәре, муллалар һәм поплар турында китте.

- Ислам мине көннән-көн үзенә тарта бара. Мин чиркәүгә йөрмим, чөнки поплар саф динне боза. Сафлыкны мин Коръәннән табам.

Гайнан шунда йөрәгендә йөрткән иң олы максатын ачып салды:

—Кызганычка каршы, безнең бик күп муллалар Коръән кушканча яшәми. Без Исламны сафландыру, аны һәртөрле бозулардан саклап калу өчен көрәшәбез. Коръәнне төрлечә аңлатуларга юл куелмаска тиеш. Максатыбыз - гадел һәм гүзәл җәмгыять төзү.

Толстойның бөтен йөзе яктырып китте, ул, иң кирәкле нәрсәсен тапкан кешедәй сөенеп, шкафыннан хәдисләр китабын алды һәм һәр сүзенә басым ясый-ясый укып күрсәтте: "Икейөзле галимнәр ислам нигезен какшаталар, хакыйкать юлын югалталар, алдашалар".

- Нинди әйбәт әйтелгән! — диде Толстой, балаларча шатланып. Аның соры күзләре эчкерсез елмая иде.

Толстойның бу халәте Гайнанны чиксез сөендерде.

—Коръән ул - кешеләр өчен юл күрсәткеч,— диде Гайнан.

—Дөрес әйтәсез, — дип куәтләде Толстой, — мин Мөхәммәт пәйгамбәрнең сүзләреннән үземә файдалы байтак фикер таптым. Аллаһы Тәгалә барлык милләтләргә дә бертөрле карый, бар милләтләргә дә аның кануны бер. Бар милләтләр дә үзара туганнардай яшәргә тиеш. Мин ышанам: киләчәктә шулай булыр да. Аллаһыга мәхәббәт, аермыйча бөтен кешегә мәхәббәт - менә төп кануны шушы.

Өч көн сизелмичә дә үтеп китте. Сардарның (Сардар - Вәисовның псевдонимы, гарәп телендә юлбашчы дигән мәгънәне бирә) Казанга китәр вакыты килеп җитте. Толстой аны: "Колач җәегез, үсегез, чәчәк атыгыз, чын күңелдән шуны телим", — дип озатып калды.

Сардар Казанга кайткач, карагруһчылар аңа этләрдәй ташландылар, ул төзегән Татар Академиясен туздырырга керештеләр. Бик авыр көннәрдә шәфкать иясе Толстойдан хат килеп төште: "Кадерле туганым Вәисов! Сезнең нинди авыр халәттә яшәвегез мине борчуга салды. Аллаһы Тәгалә һәм Сезнең динегез авыр хәлегезне җиңеп чыгарга ярдәм итсен. Миңа хат языгыз. Сезгә бирәр ярдәм күрсәтә алмаммы, күрсәтә алсам, шат булыр идем. Сезне яратучы туганыгыз".

Вәисов Толстойга ярдәм сорап хат язды. Озак көттермичә, бөек язучыдан өч мең сум акча, бераздан хаты килеп төште.

Ләкин Гайнан Толстойга чиксез рәхмәтләрен әйтә алмады: 1910 елның ноябрендә бөтен Россияне "Толстой вафат" дигән хәбәр тетрәтте. Мөбарәк тәсбих өзелде...

...Күп тә үтмәде, бөек шәфкать иясеннән мәхрүм калган Сәрдарны Себергә сөргенгә алып киттеләр. *Толстойның архивыннан мондый юлны да таптылар: "Мине игелекле мөселман итеп санавыгызны үтенәм".*

2005

## Бу кырлар, үзәннәрдә минем...

*Бу кырларда, бу үзәннәрдә минем*

*Сукмакларым иртә салынган.*

*С.Хәким.*

Безнең авыл тирәсендә дә тарихи һәм истәлекле урыннар байтак ул. Шуларның икесе турында хәзер сезгә дә сөйләп үтәргә телим. Беренчесе—Кыр коесы. Безнең авылның көньяк кырлары диңгез кебек әллә кайларга кадәр җәйрәп ята. Тип-тигез, ни бер ерым, ни бер калкулык, ни бер куаклык юк. Бу кырларда ни чәчсәң дә каерылып үсә. Менә шул кырлар уртасында урнашкан ул безнең Кыр коесы. Әйләнәсе илле адымнар булган бу галәмәт зур чокыр шундый тирән, беренче кат күргән кеше шүрләп, куркып карап тора. Бу әкияти зур "казанның яртысында су җәй уртасында да мөлдерәп тора. Суга төшәр өчен, баскычлар да бар. Бу Кыр коесын моннан өч йөз ел элек казыганнар, диләр. Урак өстендә авылга кайтып тормаганнар: шул судан чәй кайнатканнар, ашарга пешергәннәр, юынганнар, атларын эчергәннәр; әйләнәдәге чирәмлектә ятып ял иткәннәр, чатырлар корганнар. Әйе, минем бик ерактагы бабамны да хәтерли бу кое. Әле хәзер дә ул бик яхшы сакланган. Без, 41нче ел балалары, аның тирәсеннән, "уфалла" (арба) белән барып, үлән җыя идек, арыгач, аның төбенә төшеп, кәпәчкә чумырып алып, салкын суын эчә идек. Бу кое белән бәйләнешле истәлекләрем күп минем.

1946 елның июль ахыры иде. Илдә коточкыч ачлык. Без дә кычыткан ашыйбыз, әни Кәвәлдән "трахмал" (крахмал) ташып тора. Ул колхозда Торна сазында торф чыгаручы булып эшли. Беркөнне әби мине әнигә ашарга илтергә җибәрде. Кайтканда, юлым арыш кырына барып керде. Арыш өлгергән! Шундый тәмле башак исе борынны кытыклый. Учка алып уа-уа туйганчы ашадым. Аннары чалбарымның ике

кесәсен дә тутырдым. Кинәт юлда тарантас күренде. Мин юлдан бар кочемә кирегә йөгердем. Ат та минем арттан чаба. Әле уңга, әле сулга буйлыйм. Ат дугасы күмелерлек куе арышлар эченә кереп киттем. Әллә ничә кат сөрлегеп егылдым, һәм... Кыр коесына килеп чыктым. Тиз генә аска тәгәрәдем дә су читендәге таллыкка постым. Йөрәк сикереп чыгарлык булып дөп-дөп тибә. Килүче булмады. Кичкә таба кайтырга чыктым. Ләкин авылга җитәрәк, мине тарантас каптырды. Ике кеше, урталарына утыртып, миннән "допрос" алдылар. Колхоз келәтенә кереп, бер хатынның яулыгына ике кесәмне дә бушаттырып үлчәделәр: 200 грамм килде. Мин елый-елый шешенеп беттем. Мине өйгә алып кайттылар. Әни әле эштә иде. Өйдә әби генә. Әби мине коткарды, ул тегеләргә хак сүзне күзләренә бәреп әйтте:

-Сабый бала белән шулай йөргән өчен, Ходай тотар үзегезне! Өч улым сугышта үлде минем. Әйдә, хөкем итегез. Минем яклаучы беркемем дә юк.

Алар киттеләр. Миңа бик кыен иде. Җитмәсә, шул ике кешенең берсе — мәктәп директоры икән. Беренче сентябрь иртәсендә мин беренче класска укырга шулкадәр куркып бардым. Бәхеткә каршы, минем караклык турында беркем дә бернәрсә дә әйтмәде.

Хәзер инде алда телгә алынган Торна сазы турында. Әнигә ияреп, мин анда бик кечкенәдән үк барып йөри башладым. Озынлыгы бер чакрымга сузылган, киңлеге 200 метрдан артык булган бу зур сазлык киртләчләнеп әллә кая аска - түбәнгә төшеп китә. Әнә шул җәһәннәм чокырында иллеләп хатын-кыз иртәдән кичкә кадәр каторга хезмәтендә газап чигә. Бер тиенсезгә, ягъни "труддин"га (хезмәт көненә). Лычкылдап торган торфны, көрәккә аяклары белән басып, зур дүртпочмаклык итеп кисәләр, бер катлы чеп-чи кәсне носилкага күтәреп салып, такталар өстенә саркытырга китереп салалар. Саркыганнарын тачкаларга салып югарыга — сазның ике ягындагы үрләргә этеп менгезәләр. Аннары кибәр өчен пирамидалар итеп өяләр. Җәй буена йөзләп пирамида тезелеп китә. Хатын-кызлар авыр хезмәтләрен мәзәк белән җиңеләйтергә тырышалар иде. Ялга туктагач, миннән шигырь сөйләтәләр һәм тып-тын калып тыңлыйлар. Мин: "Коммунизм. Әхмәт Исхак сүзләре" дим дә сөйләп китәм:

Без җитәрбез шундый елларга,

Ерак түгел инде моңарга,

Кешелекнең бәхете кояшы -

Коммунизм - җәеп колачын

Нурын сибәр бөтен дөньяга.

Фатыйма апа бик җитди генә әйтә шунда:

- Хатыннар, әнә теге тау башына менеп карагыз әле: ул коммунизм килеп җитмиме икән.

Зәйнәп апа да оста:

-Кайсы яктан килә икән ул?

Бу Торна сазы үзендә әллә нинди серләр яшергән. Калын торф катламы эченнән әледән-әле юан-юан имәннәр килеп чыга. Шул имәннәр янында туңмай салынган кувшиннар да табыла. Шунысы гаҗәп: май бер дә бозылмаган. Торфка күмелеп ятканга күрә. Хатыннарның бригадиры Сафиулла абзый сөйли торган иде: борынгы заманнарда безнең авылның бөтен ягында имән урманы үскән. Петр патша заманында аларны кисәннәр, атлар белән тарттырып, Зөягә ташыганнар, Зөядән Иделгә агызганнар. Аннары алардан Казан янында кораблар ясаганнар. Теге майлар урман кисүчеләрдән калган икән, имәннәр шул заманнарда бу сазлыкка төшеп күмелеп калганнар.

1954нче елда Торна сазында торф белән эшли торган электр станциясе корылды. Ләкин аңа озак эшләргә насыйп булмады: 1957нче елның язында Куйбышев ГЭСы сафка басты һәм безнекенең кирәге калмады. Торф чыгару да бетте, колхозлар торфны ашлама урынына кырларга ташыдылар, бик тирәнәйде Торна сазы. Торна сазының суы бер ягыннан ерылган канау буенча Зөягә таба ага торган иде. Аннары ул канауны буып куйдылар да Торна сазын мөлдерәмә күл иттеләр. Шул күлгә юан-юан торбалар куеп, иксез-чиксез кырларны сугардылар. Электр станциясе биналары да әрәмгә китмәде: нәкъ саз янындагы үрдә бетмәс-төкәнмәс кызыл балчык катламы ята икән — кирпеч заводы ачып җибәрделәр. Мелиорация чоры тәмамлангач, күлдә балык үрчетә башладылар.

Торна сазы белән бәйләнешле истәлекләрем күп минем. Берсен сөйләп тә бирим.

Дүртенче сыйныфта укыганда (1950нче елда), класс җитәкчебез Фәимә апа «Торф барлыкка килү» дигән темага табигатьтән ачык дәрес үткәрде. Минем бөтен гомерем ачык дәресләр күреп узды, үзем дә бик күп күрсәттем. Ләкин менә бу ачык дәресне мәңге онытасым юк. Ул дәрескә без әллә ничә атна әзерләндек. Апабыз Торна сазына экскурсиягә дә алып барды. Экскурсиядә күргәннәрне ачык дәрестә Тәлгатькә сөйләргә кушты. Без Тәлгать белән икебез дә бер партада утырабыз. Аның әтисе дә, минем әти дә сугышта һәлак булган. Икебезнең дә әниләр Торна сазында эшли. Менә килеп тә җитте ул ачык дәрес көне. Тәлгатьне әнисе ачык ачык дәрескә әзерләп җибәргән: атасы күлмәген кечерәйтеп тегеп биргән, кайчы белән чәчен дә кыркыган. Менә шул чәчтән китте барысы да: малайлар көләргә тотынды аның чәченнән: "Кыркыган сарык башы" дип, күзен ачырмыйлар. Тәлгать бүреген киеп куйды, аннары, бөтенләй басып, колакчаларын да бәйләде. Апабыз күпме генә ялынса да, башыннан салмады. Мин шунда әйттем апага: "Апа, хәзер безгә кайтып, чәчен матурлатып алабыз, бездә әтинең безопасные бар". Өйдә әни дә, әби дә юк иде. Әйбәтләп сабын күбеге ышкыдым да тотындым Тәлгатьнең башын кырырга. Ләкин әтидән калган лезвие бик искергән иде шул, алак-йолак итеп кенә ала. Җитмәсә, тегеннән дә, моннан да канап-канап чыга. Мескен Тәлгать елап-елап та җибәрә. Шулай да башны кырып бетердем, ләкин кеше карарлык кына булмады. Без барып кергәндә, биш минуттан ачык дәрес башланып та китте. Без, 35 укучы, аягүрә басып, 35 укытучыны каршыладык. Ләкин утырырга кушучы булмады, гел баскан хәлдә торабыз. Тәлгать бүреген басып

кигән килеш тора иде (әтисе бүреге булганга, кашына ук төшкән ). Апабыз аңа, ягымлы гына итеп: “Тәлгать, акыллым, сал бүрегеңне”, - дисә дә, дустым тыңламады. Шуннан соң директор эшкә тотынды. Ул, гаять зур корсагын Тәлгать партасына терәп, котчыкмалы катгый итеп үкереп җибәрде:

- Сал, диләр сиңа карга оясын, дуңгыз.

Тәлгать башын бөкте, ләкин салмады. Директор бүрегенә үрелүгә, ике кулы белән колакчаларын тотып өлгерде.

- Әле син шулаймы?! Хәзер мин сине...

Тәлгать, кинәт кенә директордан ычкынып, класс алдына ыргылды, аннары күз иярмәс тизлек белән ишеккә томырылды.

- Тотыгыз, Сабитов! – дип боерды директор фронтовик укытучыга.

Без мәктәп яныннан карап тордык: Сабитов абый кырга таба йөгереп киткән Тәлгать артыннан озак чабып барды, ләкин тота алмыйча кире килде.

Ачык дәрес Тәлгатьтән башка гына үтте. Торна сазына ясаган экскурсия турында Тәлгать урынына миңа сөйләргә туры килде. Апабыз алга "торф ясалу" дигән рәсем-схема элеп куйган иде. Ул аны бик матур итеп үзе ясаган иде. Менә шул күрсәтмәлек әле дә минем күз алдымда тора. Дәресләр беткәч, мин Тәлгатьләргә киттем. Тәлгать өенә кайтмаган. Өйгә класс җитәкчебез дә килгән. Әнисе дә, апабыз да кара кайгыга батып утыралар иде.

Мин тизрәк Тәлгатьне эзләргә киттем. Туп-туры Кыр коесына бардым. Әлбәттә, мин Тәлгатьне шунда таптым, кеше килгәнлекне ишетеп, ул да минем шикелле шул ук таллыкка поскан иде.

Без исән-сау кайтып кергәч, әнисе дә, апабыз да бик сөенделәр, мин гаепне үз өстемә алдым, гафу үтендем.

Иенче көнне Тәлгатьне мәктәпкә “конвой” белән алып килделәр.

2006

## Гомерлек юксыну

Мин әтиемне күреп хәтерләмим: мин туып тугыз ай үткәч тә, ул 1939нчы елның июлендә армиягә алынган. Менә рәсеме: 12нче октябрь, 1939нчы ел. Чиләбе шәһәре. Әти озынча шинель кигән, билен каеш белән кысып буган. Башында хәрби фуражка. Прохоров дигән рус егете белән басып төшкәннәр.

Тагын бер рәсем: 25нче июнь, 1940нчы ел. Чиләбе шәһәре. Әти ялгызы гына утырып төшкән. Сержант.

Менә монысын Белоруссиягә күчерелгәч төшеп җибәргән: 10нчы март, 1941нче ел. "Истәлек өчен туган илгә Белоруссиядән җибәрәм. Дүртебез дә командирлар булып эшлибез, 1) уңда басып тора Тәтеш районы егете Закиров Исмәгыйль, 2) Оленов – рус егете, 3) сулда аста утыра Алабуга районы егете укытучы Сәлимҗанов Габдулла. Сагынганда алып карарсыз. Арада мине аеруча матур төшкән дип әйтәләр." әти гимнастёркадан, каешында йолдыз, иңбашы аркылы кыр сумкасы ремене. Якасында лейтенант билгеләре. Взвод командиры, Гродно шәһәрендә.

Менә әтинең соңгы рәсеме: 6нчы апрель, 1941нче ел. Әти үзе генә басып төшкән. Күкрәгендә кызыл йолдызлы значоклар.

Бусы соңгы хаты. "...Безнең честьны Гродно шәһәреннән Польша чигенә күчерделәр. Үзегез беләсез, Польша фашистлар кулында. Бу – күңелдә җитди борчылу тудыра. Чикнең теге ягында барысы да күренеп тора.Күзләр җиткәч, кайтам инде... Взвод командиры булып хезмәт итәм... Равилне бик сагындым. 20нче июнь, 1941нче ел". Шул көннән бирле – билгесезлек, шул көннән бирле - гомерлек көтү, гомерлек юксыну, гомерлек күрешергә өмет, берәр хәбәр белергә теләү.

Әтинең бертуган абыйсы Җамалетдин Сәйфетдинов – катлаулы язмышлар кешесе. 1930нчы елда 18 яшендә авыл советы рәисе, колхозлаштыру елларының барлык авырлыкларын күкрәге белән алдан ерып бара. Бер генә хуҗалыкны да Себергә җибәрмәгән өчен, үзе утырып чыга. Авылда атаклы җырчы була. 1934нче елда Кара диңгез флотында су асты көймәсендә хезмәт итә. Армиядән кайткач, Казан университетында укый һәм Тәтеш районына судья итеп җибәрелә. Сугыш елларында үзе теләп фронтка китә. Капитан, рота командиры була. Менә аның 1944нче елның 3нче гыйнварында фронттан язган хаты. "...Энем Гарәфетдинне озак эзләттердем. Бернинди хәбәр таба алмадым. Әгәр мин дә һәлак булсам, безнең нәсел һәм нигез иясе булып Равил кала. Аны лаеклы итеп тәрбияләргә тырышыгыз..." Җамалетдин абыйның  соңгы хаты. Хат-открытка. Тышкы ягында кара фашистка штык кадаган кызыл сугышчы рәсеме. Хат кыска, Һәр хәреф газап белән теркәлгән:"...Носилкада яткан килеш язам. Күкрәгем авыр яраланды. Авыр, авыр, авыр. Хуш булыгыз. 1944нче ел, 3нче сентябрь".

Менә бусы – коточкыч документ - әбиемә килгән хәбәр(извещение): "Сезнең улыгыз рота командиры Сәйфетдинов Җамалетдин Сәйфетдинович Ватан өчен сугышта батырлык һәм ирлек күрсәтеп, хәрби антына турылыклы булып, 1944нче елның 3нче сентябрендә авыр яраланды һәм үлде. Псков өлкәсе, Кунин районы, Пески авылы зиратында күмелде.".

Безнең гаилә альбомында тагын бер матур егет рәсеме бар: ул – Җамалетдин белән Гарәфетдиннең өлкән бертуган абыйлары – Хәйретдин Сәйфетдинов. 1898нче елда туган. 1916нчы елда герман сугышына алынган. Фронттан хатларын шигырь белән язган:

Германия атлары,

Маңгаенда чуклары.

Сагынганда килеп торсын

Безгә сәлам хатлары.

Ниләр күрми баш монда,

Атлар үлә ташкында.

Яшь гомерләр зая үтә

Карпат тавы астында.

Хәйретдин абый, герман фронтыннан әйләнеп кайткач, 1918нче елның җәендә Казанга аклар һөҗүме вакытында тагын фронтка – кызыллар гаскәренә алына. Зөя каласында каты бәрелешләр вакытында һәлак була һәм авылыбыз зиратына алып кайтып күмелә.

Бер улын гражданнар сугышында, икесен Бөек Ватан сугышында югалткан сөекеле әбием туксан яшенә чаклы алар өчен кайнар яшь түкте, әтине көн саен кайта-кайта дип көтә-көтә, гомерлек ышанычын мәңгелеккә үзе белән бергә каберенә алып китте.

Минем әни, авылдагы барлык хатын-кызлар кебек үк, бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр колхозда эшләде, мин, дәһшәтле еллардагы 3-6 яшьлек малай, ул чакларда әнине өйдә сирәк күрә идем. Әни әтинең кайчан да бер кайтырына ышана иде. Бик яшьләй чәчләренә чал иңде.Үзе дә, сугышта һәлак булган солдат кебек, һич көтмәгәндә, майның бик матур көләч көнендә йорт алдындагы чирәмлектә казлар караганда, кинәт йөрәген тотып, минутлар эчендә бу дөньядан китеп барды.

Бәйрәмнәрнең иллесе дә истә,

Иллесе дә яна бәгырьдә.

Мәңгелек ут урамнарда түгел,

Бәгырьләрдә яна, бәгырьдә.

Бу сагышны һаман җиңеп булмый,

Үзем белән бара кабергә.

Бик еш кайтып киләм кырык бишкә:

Клуб яны, майның тугызы.

Мин бер алты яшьлек кара малай

Тыңлап торам колак торгызып.

Җиңдек! – диләр, ура кычкыралар.

Кемдер мине чөя һавага,

Җиргә төшкәч, һавадагы шатлык

Кара сагыш булды яңадан.

Сугышларның кара сагышыннан

Телгәләнгән минем йөрәгем.

Ул әтине миңа күрсәтмәде

Һәм әнинең йотты терәген.

Әтиләрне саклап йөрәкләрдә,

Мәңге сагынып, мәңге юксынып,

Без, малайлар, бик тиз ирләр булдык,

Кечкенәдән зурлар күк янып.

Без, малайлар, һич тә зарланмадык

Икмәк-бәрәңгесез калганда,

Үгез җигеп җирне сукаладык

Унөч яшьтән кырда сабанда.

Авыр булды, ләкин кайгыларны

Йөрәкләргә яшереп елмайдык.

Чәчләр юкка иртә агармады,

Юкка иртә олыгаймадык.

Йөрәкләрне меңгә телгәләде,

Бигрәк авыр килде замана.

Без, малайлар, бәгырендә менә

Ярты гасыр сәер ут яна.

Яна, дөрли, әрни, өзгәләнә,

Күмер кебек көйри бу йөрәк.

Һәйкәлләргә карап кына тынмый,

Торган саен яна көчлерәк.

Сугыш китергән мәхрүмлекләр ягыннан без хатыным белән икебез дә пар килгәнбез: аның да әтисе 1942нче елның 9нчы декабрендә Сталинградта һәлак булган. Безнең өч улыбыз, өч оныгыбыз бар. Алар үзләренең бабаларын яхшы белергә тиеш. Тамырлар нык булсын. Җиңүнең 50 еллыгын зурлап үткәрүнең асыл мәгънәсе дә шунда. Безнең авыл уртасында һәйкәл бар. Анда яу кырыннан кайтмый калган 286 авылдашыбызның исемнәре чокып язылган.

Сез, Гитлерны җирдән дөмектергән

Батыр солдатларның оныклары,

Әй карагыз, ничек нурлы балкый

Ямьле Татарстан офыклары!

Бик еракта калган зур Җиңүнең

Яшәгез сез белеп кадерләрен.

Онытмагыз, бөтен Европада

Сезнең бабаларның каберләре.

Каберләрсез Җиңү була алмый,

Сез бит – шул Җиңүнең чәчәкләре.

Сезнең күкрәкләрдә дөрләп типсен

Җәлил, Газинурлар йөрәкләре.

Фашист юк итәргә булган җирдән

Арысландай безнең татарларны.

Ә татарлар, яуда ирек даулап,

Баскыннарны ничек ботарлады.

Җиңү үлми, бара гасырларга,

Хак эшебез тантанасы булып.

Фашизм баш калкытмасмы тагын?

Сез яшәгез шуннан сабак алып.

Сез, Гитлерны җирдән дөмектергән

Батыр солдатларның оныклары,

Нык саклагыз туган җиребезне

Балкып торсын тыныч офыклары.

1995

## Олуг шагыйрь турында истәлекләрем

1956 елның октябрендә Казанның Тукай клубында сөекле шагыйребез Хәсән Туфан белән очрашу кичәсе булды. Мин дә, университетның беренче курсында укучы 18 яшьлек егет, шыгрым тулы залга керә алдым. Сәхнәгә ап-ак озын куе чәчле, гаять мөлаем какча йөзле, мәһабәт гәүдәле шагыйрь чыгып баскач, алкышлар башланып, тиз генә тынмады. Күзләрдә яшь иде. Унтугыз ел буе тоткынлыкта интеккән шагыйрь, ниһаять, азат ителеп, әле күптән түгел генә Казанга кайтып төшкән. Дуслары аны матур итеп киендергәннәр. Сәхнәдә Туфан чәчәк бәйләмнәре арасында калды. Йөзе генә күренеп тора. Шагыйрь үзенә генә хас сузынкы, моңлы бер көй белән бик күп шигырьләрен укыды. Бу төнне мин йокысыз үткәрдем. Нинди илаһи кешебез бар икән безнең!

1960 елның мартында, Казандагы 89 нчы татар мәктәбендә педпрактика үткәндә, Хәсән Туфан белән очрашу кичәсе үткәрдек. Әдәбият укытучысы Фатыйма апа Җәләлиева ( ул минем туган авылым Мулла Илендә сугыш елларында укытты ) бик тәэсирле итеп сөйләгәч, миннән Х.Туфанга багышланган шигыремне укыттырды. Туфан, миңа таба янтая төшеп, бик игътибар белән тыңлап утырды, аннары ягымлы гына елмаеп рәхмәт әйтте.

1964 елның декабрендә безнең Мулла Иленә бер төркем язучылар килде: Хәсән Туфан, Идрис Туктар, Габдрахман Минский, Нәби Дәүли, Мәрзыя Фәйзуллина, Роберт Әхмәт-җанов. Аларны станциядән атлар белән барып алдык. Минем чанага Хәсән Туфан үзе туры килде. Ул бик килешле коңгырт пальтодан һәм затлы бүректән иде. Без юл буе сөйләшеп кайттык.

-Мин сезне, егет, кайдадыр бер күргән идем шикелле.

-Сезгә үзегезнең укучыларыгызны танып бетерү мөмкин түгел, Туфан абый. Шулай да берзаман мин сезнең алда бер шигырь укыган идем.

- Казандагы татар мәктәбендәме? Кытай яшьләре дә килгән иде. Истә ул шигырь. Мине боз каплаган елга белән чагыштырган идегез... Язасызмы соң хәзер дә?

-Язгалыйм. Кайчак басылып та чыккалый.

-Гафу итегез, фамилиягезне белмим.

Мин фамилиямне әйткәч, Туфан мине шаккаттырды:

-Сезне бит мин укып барам.

Шунда шагыйрь минем "Күл буенда" дигән шигыремнән ике строфаны яттан укып та биргәч, мин тәмам югалып калдым.

-Сезгә язарга кирәк, Равил.

Туфан, илһамланып һәм җилкенеп, колхоз фермасында эшләүчеләр арасында йөрде. Авылыбыз клубы сәхнәсендә мине үзе белән янәшә утыртты. Клубка халык сыймый иде. Салкын декабрь булса да, ишекләрне ачып куеп, урам ягыннан да тыңлап тордылар. Х.Туфан бик күп укыды. Сөенеп, рухланып. Үзе дә халыкны сихерләде, үзе дә сихерләнде.

1980 елның октябрендә, мин Казанда мәктәп директорлары курсларында укыган чагымда, Аксубай районы Иске Кармәт мәктәбе директоры белән очраштым. Япь-яшь кенә үзе. Туфан туып-үскән авылдан! Бер бүлмәдә яшәп ятабыз. Ул безнең Зеленодол горкомының беренче секретаре иптәш Габдуллинның кияве булып чыкты. Аның эш җайлы: Казанда әткәсе "Волга"сында гына җилдерә. Ул миннән Туфан янына алып баруымны үтенде. Телефон аша шалтыраткач, Туфан бик сөенеп риза булды. Төрле-төрле чәчәкләр ( Туфан чәчәкләргә гашыйк ), күчтәнәчләр алып, Туфан янына киттек. Шагыйрь Вишневский урамындагы бер матур йортта яши. Шагыйрь урамда йорт каршында басып тора. Өстендә җиңел ап-ак куртка. Көзге һавада ак йөзенә җиңелчә кызыллык йөгергән. Янында бик мөлаем бер апа да ( ул шагыйрьне карап, тәрбияләп торган туган тиешле кешесе ) бар. Алар безне шулхәтле җылы каршыладылар. Кердек. Туфан, чишенеп, ап-ак күлмәктән генә калды. Эш бүлмәсенә уздык. Өстәлдә яшел кара белән язылган битләр.

- Равил, сез нигә миңа бер дә шигырьләрегезне күрсәткәнегез юк. Язасыздыр әле? Күрсәтегез.

Апа тыңлап тора.

- Туфан абыегыз яшьләрдән туймады. Көне-төне яшьләрнең кулъязмаларын укый. Үзен кызганып та куям. Арыйсың бит дим. Юк, һаман үзенеке.

Туфан изге кешеләргә генә хас бер сафлык белән рәхәтләнеп елмаеп куя.

Хәсән Туфан әлеге авылдашы белән гаять тә мавыкты. Туган авылындагы әллә нәрсәләр турында сорашып бетерде. Өстәлдәге язулар автобиографик хикәяләр булып чыкты. Ул алар-ның ике битен укып та күрсәтте. Чын мишәрчәләп кенә туганнарча гапләштеләр. Шагыйрь чын күңеленнән, автограф язып, ике-томлыгын бүләк итте (алар күптән басылган һәм хәзер сирәк китаплар булса да). Бик тәмләп күчтәнәчләр белән чәй эчтек, озак итеп сөйләшеп утырдык.

-Сезгә, Равил, мөгаллимлек эшендә җиңеллекләр телим. Бик авыр хезмәт бит.

Яшь директор мәктәптә Туфанның музеен ачарга вәгъдә бирде. Чыннан да, ул сүзендә торды, шуннан соң ярты ел да узмады бугай, газетада Иске Кармәттә Туфан музее ачылды дигән хәбәр басылып чыкты. ( Ә быел музей республика күләмендә зурайтылып ачылды ).

Туфан үз музеен күрә алмады. 1981 елның чәчәкле җәендә, 10 июньдә, Туфан вафат дигән хәбәр бәгырьләрне чәнчеп үтте.

2000

## Тукай туган көндә

(Хикәя-истәлек)

Норлат урта мәктәбендә унынчы класста укыган чагым. Зурдан кубып, Тукайның алтмыш еллык юбилеена әзерләнәбез. Укытучыбыз Сания апа Яһудина инде ничә дәресләр буе гел Тукайны сөйли. Тукайның Зәйтүнәгә булган мәхәббәте турында сөйләгәндә, мин бөтенләй әсәрләнеп китәм, чөнки минем арттагы партада Ул утыра. Кирәк бит шулай булырга: аның да исеме нәкъ менә – Зәйтүнә. Әле кайчан гына барлыгы да сизелмәгән гадәти генә булган шул кызга мин үлеп гашыйк. Фәрештәгә ничек әйләнүен белми дә калдым. Хәзер бөтенләй бер әкияти серле дөньяда яшим.

Менә Сания апа Аны җавап бирергә чакыра. Менә Ул безнең алда. Барлык малайлар да аңа гашыйк, әлбәттә. Чөнки Аны сөймәү мөмкин түгел. Сибелеп киткән чем кара чәчләр белән каймаланып торган мәрмәр кебек шома ап-ак маңгай фәкать аңарда гына. Яктырып, нурланып торган мондый сөрмәле зур кара күзләр Аңарда гына. Кып-кызыл чияләр кебек тулышып торган иреннәр Аңарда гына. Мин аның һәр сулышын ишетәм бугай. Аның күкрәк турыннан чыккан һәр сүзенә мин мөкиббән. Нигә генә гашыйк иттең икән, язмыш, мине моның кадәр тиңсез матурга. Үзем кебекрәк кенә булса ни булыр иде. Юк. Мин аны яратырга лаек түгел. Чәчләрем дә кирәгеннән артык кап-кара сумала кебек. Кирәгеннән артык куе, дегет кебек. Битләрем дә юк кына нәрсәдән дә кызарып китә, аннары әллә каян бетчәләр пәйда булды. Ни йөзенә карый алмыйм, чөнки йөзе кояш кебек, ни әйтергә сүзләр таба алмыйм, чөнки оялам. Болай да кыюсыз малай идем, хәзер бөтенләй юашланып калдым. Кирәк бит шулай булырга: Ул сөйләп бетерүгә, апа миннән сорады (әллә сизә микән?), дөресрәге, минем белән викторина үткәрде. Барлык сорауларына да рәхәтләнеп җавап бирдем, чөнки бу гыйшыклык мине тамырдан үзгәртеп куйды. Моңа кадәр укуга әллә ни исем китмәгән булса, хәзер минем мәхәббәтем Патшабикәсе алдында һич тә начар буласым килми. Мин төннәр буе, Аны уйлый-уйлый, дәрес хәзерлим. Матур булмасам да, мин бишкә генә укырга булдырам. Хәзер инде әни укымаган өчен түгел, башымны черетеп утырганым өчен әрли. Бертуктаусыз дәресләргә әзерләнүем өстенә, кирәк бит шулай булырга, миңа шигырь җене кагылды. Алай гына түгел, мәктәптә шагыйрь дигән атым чыкты. Инде хәзер Сания апа һәр бәйрәмдә миннән үзем иҗат иткән шигырьне сөйләтә. Мин каршы килүнең ни икәнен дә белмим. Бу юлы да апа миңа Тукай кичәсендә сөйләү өчен шигырь язарга заказ бирде. Шигырем үзеннән-үзе мәхәббәт турында булып чыкты.

Кеше алдында моны ничек укырга? Хәлне җиңеләйтү өчен, шигырь азагына коммунизм турында сүзләр өстәдем.

1956 нчы елның 26 нчы апреле гадәттән тыш җылы, аяз, тын һәм кояшлы иде. Укулар беткәч, безне – меңнән артык укучыны – мәктәп янындагы амфитеатрга чыгарып утырттылар. Амфитеатр дигәнебез ул – безнең директор үзе уйлап чыгарган ярымтүгәрәк стадион шикеллерәк бер нәрсә. Озын-озын такталардан эшләнгән утыргычлардан гыйбарәт бик җайлы корылма иде. Яз-көз айларында бар нәрсә шунда үтә иде. Монда искиткеч рәхәт иде. Норлат мәктәбе ул үр башында бер ялгызы иркенлектә утыра. Бу амфитеатрдан әллә кайдагы, бик ерактагы җирләр аерымачык булып күренә. Нинди бушлык, нинди иркенлек! Әнә еракта-еракта зәңгәр таулар, таулар итәгендә яшел нарат урманнары, әнә аста, үзәнлектә, Мулла Илем. Күк биек-биек, тоташ зәңгәр. (Аның яулыгы да нәкъ шундый). Кояш баш очында гына һәм туп-туры безгә карый. Уннарча тургайлар безнең өстә бертуктаусыз җилпенеп сайрый. Куе булып чыккан ямь-яшел чирәмнән, мәйданны әйләндереп алган тупыллардан аңлатып булмый торган әллә нинди бик тансык исләр аңкып тора.

Тукай турындагы кереш сүзне легендар директорыбыз үзе сөйләде. (Мең укучының һәркайсын исем-фамилиясе белән белә торган мондый директор җир йөзендә башка юктыр ул) Тукай турында берничә җөмлә белән йөрәккә гомерлеккә кереп калырдай әйтте ул. Программа бик мавыктыргыч иде.

Кирәк бит шулай булырга: Аның белән минем урыннар янәшә туры килде. (Ул вакытта унынчыларны да апа үзе утырта иде). Йөрәгемнең дөп-дөп тибүеннән уңайсызланам. Ул гына түгел, бөтен кеше ишетәдер төсле. Аның кайнар беләкләре миңа тиеп-тиеп китә. Әле ярый Аны җырларга чакырдылар. Ул, кыяр-кыймас кына атлый-атлый, мәйдан уртасына чыгып басты, бертын җиргә карап торды да сөрмәле зур кара күзләрен әллә кая ерак офыкларга төбәде, аннары, бар дөньяны берьюлы кочып алырга җыенгандай, кулларын киң җәеп, күкрәк тавышы белән җырлап җибәрде:

Бар күңеллелек бөтен дөньяда, бар бер ямь бүген;
Нәрсәдән бу? Мин беләм: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Мәйдан тын да алмый Аны тыңлый. Ул күз алдында үскәннән-үсә бара, мин исә кечерәйгәннән-кечерәя барам. Ул моң булып күккә аша, бөтен дөнья Аның белән тула. Шул моңда тупылларның яфраклары ишәеп куералар. Бу җыр миндә әллә нинди өметләр уята, әллә кайларга чакыра, әйди, гел саф булырга, гел изгелек кенә кылырга ымсындыра иде.

Ул җырлап бетерүгә, кирәк бит шулай булырга, мәйданга мине чакырдылар. Беркемне дә, бернәрсәне дә күрерлек халәттә түгел идем, гүя мин иксез-чиксез бушлыкта бер ялгызым калдым, ә күңелдә бары Ул гына һәм шигырь генә. Шигырьнең исемен әйттем: ”Тукай мәхәббәте” һәм, бөтен батырлыгымны җыеп, яттан сөйләп киттем, шигырь озын иде.

Мәҗнүн ничек сөйгән булса үз Ләйләсен,
Шулай сөйгән Тукай да бит Зәйтүнәсен.
Зәйтүнәнең йөзе нурлы, алсу булган,
Аның өчен бөтен шагыйрь көн-төн янган.
Ул кыз якты йолдыз кебек балкып торган,
Матурларның матурыннан матур булган,
Шагыйрь аны шундый-шундый янып сөйгән
Һәм рухланып шигырьләрдән гөлләр үргән.
Белмәсен дип сөйгәнемне коты очкан,
Очрый калса шүрәледәй аннан качкан.
Әйтәлмәгән гыйшкын шагыйрь, яшерен сөйгән,
Ул – фәрештә, һич тә тиң-пар түгел дигән,
Туктамаган ләкин сөюеннән һич тә,
Киресенчә, арта гына барган ул хис эчтә.
Тукай өчен ул кыз гади түгел, илаһи зат,
Ул мәңгелек идеал, иң югары максат.

Табынган ул Зәйтүнәгә сәҗдә кылган,
Гарешләргә ашкан, чиксез илһам алган.
Яшерен сөю, яшерен газап. Яшерен яну
Тукай өчен булган ләззәт, илһамлану.
Тукай! Тукай! Бигрәк яшьли үлгәнсең син,
Күпме газап, күпме михнәт күргәнсең син,
Җитмәгәнсең килеп гүзәл заманага,
Яшәр идең лаек булып хәзер аңа.
Сиңа бүген әле бары алтмыш кына,
Яшьтәшләрең яши әле яхшы гына.
Исән булсаң, күрер идең азат илне,
Безне коммунизм таңы нурлый инде.

Юбилей тәмамлангач, кирәк бит шулай булырга, Ул әйтә миңа: “Мин бүген сезнең авылга әбиләргә барам. Әйдә безнең тулай торакка барып кына килик, мин җыенып чыгыйм (Ул егерме чакрымдагы авылдан килеп укый иде, шуңа күрә монда тора, ә без – биш кенә чакрымда булган Мулла Иленнән, көн дә кайтып йөрибез. Без дигәнем: алты кыз, алты малай. Менә хәзер мин Аны көтеп калдым, алар кайтып киттеләр)

Ниһаять, без дә кузгалдык. Мин алдан барам, Ул – минем арттан. Мәктәп тавын төшеп җиттек. Су төптә генә булса да, бик текә ярлы һәм гаять тирән чокыр – елга аша салынган күпергә керәбез. Күпернең такталары селкенеп тора.

– Әйдә, миңа тотынып чык!

– Юк, кирәкми, мин үзем.

Норлат капкасын чыктык. Юл тигезлектән туп-туры Мулла Иленә бара. Быелгы иртә язда җирләрне чәчеп тә бетергәннәр. Тып-тын. Ни алда, ни артта кеше дә, ат та, машина да күренми. Мин алдан барам, Ул – минем арттан. Мондый тынлыкта сүзнең кирәге юк. Тынлык үзе сөйлидер кебек. Һаман шулай барасы да барасы гына килә. Ләкин юл юл инде ул. Киртәләр очрамый калмый.

Албаба станциясенә җиттек, тимер юлда бик озын составлы поезд тора. Ничек теге якка аркылы чыгарга?

– Әйдә, әнә теге вагонда теге якка чыга торган баскыч бар. Мин сине күтәреп куям.

– Юк, кирәкми, мин үзем.

Ул минем арттан үзе менде. Мин тиз генә төштем.

– Әйдә, кил, төшерәм.

– Юк, кирәкми, мин үзем.

Аңа менү дә, төшү дә берни түгел иде, үзеннән-үзе очкалак, авырлыгы бөтенләй юк та кебек.

Барабыз. Мин алдан, Ул арттан. Мулла Иле биләмәләрен буеннан буена кисеп үткән тирән чокырга килеп җиттек. Монда күпер юк. Киртләчләргә баса-баса тирәнгә, чокыр төбенә төшәсең, аннары теге якка шулай күтәреләсең.

– Әйдә, кил, мин сине тотып төшәм.

– Юк, мин үзем.

Төптән караганда, өс әллә кайда югары.

– Әйдә, тотып менәм.

– Юк, мин үзем.

Аңа төшү дә, менү дә берни түгел иде.

Авылга кердек. Олы урамнан кайтабыз. Озын ул безнең авыл – ике чакрым. Урамның урта бер җирендәге безнең өйгә килеп җиттек.

– Әйдә, безгә кереп чыгабыз. Минем әнине дә күрерсең.

– Юк, хәзер түгел, икенче мәртәбә.

– Алайса мин хәзер әнигә әйтеп чыгам да сине илтеп куям.

– Юк, мин үзем генә. Иртәгә иртүк мин китәм (иртәгә якшәмбе иде).

– Ә мин сине озата барам.

– Юк, мин үзем генә. Син миңа ачуланма. Без һаман да дуслар булып калыйк. Синнән дә ышанычлы дустым юк дөньяда.

Апрель бетте, май да үтеп китте. Июньдә имтиханнарны да биреп бетердек. Мәктәп белән хушлаштык. Аның белән хушлашмадык. Миңа бик ямансу иде. Бу укулар нигә бетте икән? Мәктәп мине көн дә Аның белән бәйләп тора иде, көн дә мин аны күрә идем.

Башы һәм ахыры булмаган бер әкият булды бу. Ул гел мине үзенә тартып, мине яклап, мине саклап торды. Мин, җиде фәннән имтихан биреп, университетка кердем.

Еллар үтте. Гаилә кордым.

Кирәк бит шулай булырга: педагогик журналда бер төркем укытучыларның эш тәҗрибәләре язылган, шулар арасында Ул да бар, мин дә бар.

1986 нчы елның 26 нчы апрелендә әнә теге Ул безгә кермичә киткән капка төбендә миңа хат биреп киттеләр. Карыйм: я, Хода, хат аңардан! Тиз-тиз ишек алдына кереп укыйм. Кайбер юлларны язгалап китәм: "Сәлам Урал тауларыннан! Син ачулана күрмә хатны мин үзем башлап язган дип. Гомерлек дус булып калыйк. Безнең тәҗрибәләр бертөрлерәк икән. Мин бит күптән түгел генә туган якка кайткан идем. Албаба станиясендә сине күрдем. Син мине күрмәдең. Син бер тамчы да үзгәрмәгән. Үзең алда барасың. Хатының (күз тимәсен, тфү-тфү!) арттан килә, улыгыз да үзегез белән (күз тимәсен, нәкъ үзең инде!). без өчәү күләгәдә утырып тора идек (ирем, кызым белән). Син бик бәхетле күрендең. Мин бик шатландым. Мин дә бик бәхетле. Теге вакытта унны бетергәч, абыйлар мине Урал тауларына алып киттеләр. Ирем белән икебез бә укытабыз. Дусларча хат яз.

Мин җавап хатын язарга өлгермәдем, кирәк бит шулай булырга: мине бик ашыгыч рәвештә укытучылар курсына чакырып алдылар. Һәм шунда мин аның Үзе белән очраштым. Ике атна буе бергә йөрдек. Янәшә йөрдек. Чын дусларча. Бер-берләребезнең бәхетләренә сөенеп, бер-беребезгә уңышлар теләп. Йөрәкләрне сафлык, илаһи моң, мәхәббәтнең бөек көченә һич икеләнүсез ышану били иде. Патологик сөю дә кешене чиксез бәхетле итә, бөтен гомерен яктыртып бара.

Мин аны поездга озатып куйдым.

– Китер, әйберләреңне үзем күтәреп барам.

– Рәхмәт. ("Юк, кирәкми, мин үзем", – димәде.)

**Киндер**

(Юмореска)

Хәзер бабай төшенчәсе искерде бугай. Җитмеш биш яшьлек Искәндәр Гарифҗановка берәүнең дә "бабай" дип эндәшкәне юк. Хәтта биш яшьлек малай-шалайлар да "абый" дип кенә җибәрәләр. Зурларның күбесе кушаматы белән, яратып, "Сандр" диләр. Бу кушаматы аңа армиядән ияреп кайткан: анда Искәндәрне бик зурлап, урысча итеп, Александр дия торган булганнар. Авылдашлар Александрны матур итеп кыскартканнар: Сандрга калдырганнар. Кайчагында аңа әтисе кушаматы белән "Арипан" диючеләр дә бар. Әтисе мәрхүм Гарифҗанга бу кушамат шахтадан тагылып кайткан булган. Җитмеш биш яшькә җитсә дә, Искәндәр холкы, үз-үзен тотышы ягыннан малайлыктан чыгып җитмәде бугай. Малайларча беркатлылыгы аркасында әле авылда әллә нинди кыен хәлләргә дә тарыкты. Нәкъ малайлар кебек, кукуруз кырыннан үткәндә, кызыгып китеп, кесәсеннән зур гына пакет чыгарды да, бәләк-бәләк чәкәннәрне шунда тутырды. Хәзер колхоз түгел шул, ул чакта гына, күкрәк киереп, бу басуларны үзебез җир дип йөри идең. Хәзер бу җирләр алпавытныкы, ягъни "Кызыл Шәрык" ныкы. Теге чакта гына ул колхоз рәисе кыңгыр эшне күрсә дә күрмәмешкә салына иде. "Кызыл Шәрык" каравылчылары Искәндәрне тотып алдылар да конторага алып кайттылар, акт төзеделәр һәм өч айлык пенсиясе күләмендә штраф бөдәп куйдылар. Ул чәкәнне машинасы белән җыеп кайтучылар да бар бит, ләкин, нишлисең, тотылмаган карак түгел.

Инде бу юлы аннан да яманы булды. Иртә белән өйгә полиция вәкилләре килеп керде. Килеп керделәр дә Искәндәрне урамдагы бакча артларына алып киттеләр.

– Эләктеңме, наркоман?! – дип, йөрәкне ярды мыеклы әзмәвер. – Бу нәрсә? Син ничә еллардан бирле монда киндер үстереп ятасың?! Әллә безне күзсезләр дисеңме? Без күрмәгән, без тапмаган җир юк ул, наркоман калдыгы, адәм актыгы!

Менә сиңа кирәк булса гөнаһ шомлыгы! Чыннан да, Искәндәрнең бакча артында, таллар ышыгында, киртә эчендәге аулак кына бер тын җирдә шундый тулышып үскән өч киндер кукыраеп торалар иде. Нәкъ шушында, җинаять урынында, акт-беркетмә төзеделәр. Пүнәтәй итеп күршедәге Чәкән Шәмсиясен чакырдылар.

Искәндәр малайларча күз яшен коеп бертуктаусыз тәкърарлады:

– Бу киндерләрне минем күргәнем дә юк. Алар үзләре гаепле, алар үзләре үскәннәр бу җирдә. Мин киндер үстерүче кешеме инде?! Менә Шәмсия күршедән сорагыз.

Күршесе Шәмсия дә якламады Искәндәрне: беркетмәгә рәхәтләнеп кул куйды. Аһ-ваһына карамастан, Искәндәргә кул куйдырдылар, карчыгы Нәгыймә дә, таш астыннан чыккан бик тә бик үткен, башбирмәс хатын булса да, кул куярга мәҗбүр булды.

Искәндәрне, кулларына богаулар салып, машинага утыртып алып киттеләр.

Полициянең караңгы бүлмәсендә утырганда, Искәндәрнең малай чагы башыннан үтте.

Сугыштан соңгы еллар. Менә ул урман кебек шаулап үскән киндер басуы эчендә бишмәтен җәеп киндер суга. Өйгә кайткач, әнисе хуш исле киндерне төя дә, мичтә бик тәмле киндерле кабартмалар пешереп бирә. И рәхәт чаклар! Күпме ашап та, берәү дә наркоман булмады. Ләгънәт яусын киндердән наркотик нәрсә алучыларга.

Менә немец теле дәресе. Укытучы “Ди Киндер гейен ин ди Шуле” дигән җөмләне тәрҗемә итәргә бирә. Искәндәр “Мәктәптә киндер үсә” дип көлкегә кала. Аның каравы “киндер”нең немецчә “балалар” икәне гомергә исендә кала.

Татар теле дәресендә укытучы “Чабата киндерәсе”нең килеп чыгышы турында сораганда, Искәндәр: “Ул киндердән килеп чыккан, чөнки киндерәне киндердән үстергәннәр”, – дип әйтеп бишле ала.

... Судья соңгы хөкем карарын укыр алдыннан, суд залына Шәмсия килеп керде һәм елый-елый сөйли башлады:

– Җәмәгать, барысына да мин гаепле. Искәндәрнең бакча артына ул өч бөртек киндер орлыгын мин утырткан идем. Усаллыгым өчен чиксез үкенәм. Мине теләсә нәрсә эшләтегез. Мин сезнең хөкемдә.

Искәндәрне өенә кайтарып җибәрделәр. Шәмсиядән сорау алулар башланды.

03.02. 2013